# ШУРА

№ 25

2019




2000999941986

ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

ЭЧТӘЛЕК

ҖОМГА ХОТБӘСЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
ВӘГАЗЬЛӘР
Тәмәке мәкере . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Ятимнәрне кайгырту – Пәйгамбәребез сөннәте . . . . . . . . . 17
Мәчетләрне хөрмәт итү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Безне иң нык яратучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Корбан чалу Аллаһыга якынайта . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Корбан гаете хотбәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транскрипциясе . . . . . 44
Беренче хотбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Икенче хотбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45
Корбан гаете хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . 47
Беренче хотбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Икенче хотбә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Корбан гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Гошер садакасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Дини һәм дөньяви гыйлем алуның әһәмияте . . . . . . . . . . . 64
Яңа ел – нәтиҗәләр ясау вакыты . . . . . . . . . . . . . . . 70
Гашурә көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
«Хизбүт-тәхрир» – шәйтан партиясе! . . . . . . . . . . . . . . 81
Раббыбызның мәрхәмәтеннән читләшмик . . . . . . . . . . . . . 87
Исламда өлкәннәргә карата мөнәсәбәт . . . . . . . . . . . . . 92
Укытучылар – галимнәр дәвамчысы . . . . . . . . . . . . . . . 98
ФӘТВАЛАР
Мөмкинчелеге булганнарга хаҗны кичектерергә ярыймы? . . . . 106
Зәкятне тапшыру кагыйдәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 107
Тәһарәт алган вакытта аякларны дымлы салфеткалар белән сөртсәң ярыймы? Тәһарәтне кар белән алырга ярыймы? . . . . . . . . . . . . . 109

Мәрхүм исеменнән садака бирергә ярыймы? . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
ҮРНӘК ЗАТЛАР
Рамлә бинте Әбү Суфиян радыяллаһу ганһә . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
ФӘН
Шәригать хөкемнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Харамнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
ТАРИХ
Ислам яңарышы чорының маяклары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Әл-Әкъса мәчете тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
МИРАС
Әҗем мәчете тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Васыя нәбәвия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Мөхәммәд галәйһиссәлам васыяте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Риба бабындагы Расүлуллаһның (салләллаһу галәйһи вә сәлләм)
бәгъзе хәдис-шәрифләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
ТӘРБИЯ
Әдәп-әхлакка караган хәдисләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Мәчет һәм балалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
ХАҖ
Хаҗ кылуның фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Хаҗ әдәпләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185
КОРБАН
Корбан чалу кагыйдәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
НӘСЫЙХӘТ
Зур гөнаһлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Әдәпләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203

**«ШУРА» дини альманах, №25**

*июль – сентябрь 2019*
*зөлкагъдә 1440 – мөхәррам 1441*

Альманах Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең (Роскомнадзор) Татарстан Республикасы (Татарстан) идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ №ТУ16-01077 нче теркәлү таныклыгы алды.

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма –
Татарстан Республикасы
мөселманнары Диния нәзарәте
420021 Казан, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бәясе ирекле
2013 елның июленнән чыга
Басма кварталга бер тапкыр чыга
**12+**

**БАШ РЕДАКТОР:**
Камил Искәндәр улы Сәмигуллин
Телефон: +7 (843) 237-94-53 (кабул итү бүлмәсе)

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Ришат Хәмидуллин
Булат Мөбарәков
Илдус Фәиз

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**ДИЗАЙНЕРЛАР:**
Рөстәм Даутов
Илшат Хәйретдинов

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Раушан Сәйфетдияров

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
Эдуард Димасов

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нчы йорт
Тел./факс: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: shura@huzur.ru
Сайт: www. huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«ОТ Принт» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420030, Казан шәһ., Жуковка ур., 2.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 03.07.2019
Чыгу көне: 13.07.2019

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аять-сүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, басып, кычкырып түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ۞ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللهُ۞ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ۞ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللهِ۞ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ۞ دَاعِينَا إِلَى اللهِ۞ صَلَّى اللهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ۞ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ۞ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ۞ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ۞ رِضْوَانُ اللهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللهِ!۞ اِتَّقُوا اللهَ وَ أَطِيعُوهُ۞ إِنَّ اللهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ۞

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

۞______________________________

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

۞

Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, кычкырып түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган выкытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак киләсе сүзләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِينَ وَالصَّلَوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِينَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَاهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ

عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞
اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ۞ سَيِّدِنَا أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّهُ عَنْهُمْ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّهُ عَنْهُما۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّهُ عَنْهُما۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاتِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне кычкырып укый һәм хотбә тамам була:

إِنَّ اللهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ۞ وَلَذِكْرُ اللهِ أَكْبَرُ وَاللهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, басып, кычкырып түбәндәге доганы укый:**

Әлхәмдүлилләәһил-ләҙии һәдәәнә лиһәәҙәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләәән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәуфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләҙии каалә фии китәәбиһил- кәриими әстәгыйҙү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин гаҙәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәйийидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мү'миниинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гуҫмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъдү: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләҙиинәт-тәкау, вәл-ләҙиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыыйҙү билләһи: ____________________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ____________________

____________________________________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, кычкырып түбәндәге сүзләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалләллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә иҙәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әңсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйҙү билләһи: «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил Исләәм».

**Соңыннан кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган выкытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләҙиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибраһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ҙәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә

вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мукәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Вәхҙүл мән хәҙәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мукыйммиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгузү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне кычкырып укый һәм хотбә тамам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ҙил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәҙәккәруун. Вәләҙикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

# Вәгазьләр

*12 июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Тәмәке мәкере

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм Хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Ислам дине «س، ل، م» – «син, ләм, мим» тамырыннан чыккан һәм сәламәт, имин булуны аңлата дип бик күп тапкыр ишеткәнегез бардыр. Шулай ук бүгенге көндә «Пәйгамбәребез медецинасы» дигән төшенчә дә киң тарала башлады. Ислам галимнәре искәртүенчә, кеше тәһарәт алганда тәнендә булган һәрбер кирәкле ноктaларга кагылып, тәнне ял иттерә. Ә су, пакьләү белән беррәттән, тәнне дә тынычландыра икән.

Ислам динендәге нинди генә гыйбадәткә, яки аның кешенең рухи ягы, әдәп-әхлагына биргән игътибарына мөрәҗәгать итеп карасак та, аларның кеше сәламәтлегенә уңай тәэсир иткәнлегенә инанырбыз.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәрим китабында кешене камил, матур кыяфәттә барлыкка китергәнен әйтә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ ﴿٤﴾

**«Тәхкыйк, Без адәм баласын күркәм сурәттә халык кылдык».**

«Тин / Инҗир», 95:4

Ә димәк, без шул тәнебез өчен җавап тотачагыбызны да онытмасак иде, чөнки ул – әманәт. Без тәнебезне төрле рәсемнәр төшереп, кирәкмәгән җиргә алкалар асып, нинди дә булса авырулар пәйда булырлык сәбәпләр кылып та бозарга тиеш түгелбез. Бу сәбәпләрнең берсе булып безнең бүгенге вәгазебездә күтәреләчәк тема тора – тәмәке тарту зыяны.

Тәмәке тарту кеше сәламәтлегенә зур зыян салганлыгы барлык кешелек дөньясына да мәгълүм. Ул озак вакыт дәвамында организмга төрле начар матдәләр сеңдереп бара, шуңа күрә тәмәке тарту бик авыр нәтиҗәләргә китерә ала, шулар арасында, әлбәттә, яман шеш тә бар. Озак еллар дәвамында тәмәке тартучы бер генә кеше дә бу гамәлнең файдалы икәнен әйтмәс; тартырга да киңәш бирмәс. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең: «Кулыннан да, теленнән дә башка кешеләр зыян күрмәгән кеше генә мөселман була», – дигән хәдисен ишеткәнегез бардыр. Тәмәке – аны тарткан кешегә генә зыян салып калмый, ә тирә-юньдәгеләргә дә «өлеш» чыгара: тәмәкенең составында да бик күп зарарлы матдәләр бар: углерод оксиды, никотин, төрле сумалалар, бензол парлары һ.б. Шуңа күрә, бу төтен тартучының үзенә генә түгел, ә тирәяктагыларга да зыян сала.

Тәмәке һәм аның зыяны турында бик күп китаплар басылган, күп хезмәтләр якланган. Каһирәдә эшләп килүче бер нейрохирург тәмәкенең зыяны турында: «Кеше тәмәке тартырга гадәтләнеп, шул гадәтнең колына әверелгәч, аның сәламәтлеге начарая, ә ул йөрәккә тәэсир итә. Аның йөрәк тибеше дә, кан әйләнеше дә бозыла; кан тамырлары кысылу аркасында, кеше йокымсырап йөри башлый. Еш кына, бигрәк тә олы яшьтәге

тәмәке тартучылар югары кан басымы белән йөриләр, шулай ук йөрәк авыруы белән газапланалар. Шулай ук аларның ашкайнату системасы да какшый башлый, сулыш бозыла, ә болар аппетитның кимүенә китерә ала.

Моңа өстәп, ул тәмәке тартучыларга хас бертөрле ютәл белән газаплана, аны шулай атыйлар да – «тәмәке тартучы ютәле». Ә нерв системасы зарарланса, кулларда, аякларда чәнчеп алулар булырга, шулай ук баш һәм төрле нерв авыртулары башланырга мөмкин», – дигән фикер әйтә.

Тәмәке аркасында барлыкка килгән авыруларның берсе – яман шеш дип әйттек. Әмма бу авыру – ул нәтиҗә генә. Димәк, тәмәке акрынлап организмга зыян сала, эчке органнар зәгыйфьләнә башлый. Ягъни монда үпкәләр турында гына сүз бармый. Һәр кешенең организмы төрле, кемнең кайсы органы зәгыйфьрәк, иң беренче шул җиргә бәрәчәк. Шул авырулар үз чиратында төрледән-төрле көчлерәк авыруларга сәбәп булалар һәм иң ахыргы баскыч булып яман шеш торачак.

Элек тагун, ягъни чума кебек авырулар бик куркыныч булса, бүгенге көндә яман шешләр бик күп үлемнәргә илтә дә инде. Аллаһы Тәгалә Үзе сакласын.

Ислам динендәге хөкеме нинди соң? Тәмәкегә карата бердәм фикер булмаса да, ислам галимнәре аңа киткән акчаны да исраф, ягъни әрәмгә киткән акча дип әйтәләр. Гомумән, әгәр дә тәмәке тартуны яхшы эш дип санап булса (ә аны алай дип бер генә кеше дә әйтә алмас иде), тәмәке тарта башлаганчы «бисмилләһ»не әйтер иделәр. Чөнки һәрбер изге гамәлне Аллаһы исеме белән башларга гадәтләнгәнбез, ә бу очракта аны әйтеп булмый.

Исламда мондый сорауларны фикеһ фәне өйрәнә. Бүгенге көндә фикеһ галимнәре бу мәсьәләдә түбәндәге фикерләрдә:

Бер төркем галимнәр тәмәке тартуны мәкруһ дип әйттеләр. Харам дип әйтер өчен, Коръән һәм сөннәттән дәлил булмаганга, алар аны шелтәләнелә торган гамәл диделәр.

Тагын бер төркем – тәмәке тарту турыдан-туры сәламәтлеккә зыян сала һәм аңа киткән акча (гаиләгә сарыф ителми, киресенчә күрә торып начар әйбергә тотыла) исраф булганга, тәмәкене харам дәрәҗәсенә кертеп караучы галимнәр.

Урталыкны сайлап, тәмәке тартуны мәкруһ тәхримән дигән караш яши. Ул харамга якын гамәл дип тәрҗемә кылына.

Тәмәкегә карата Исламда хөкем булмаган дидек, әмма чагыштырып карау юллары белән галимнәребез бу гамәлне дә тыелган гамәлләр рәтенә кертеп карыйлар. Чыннан да, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам вакытында тәмәке тарту булмаган. Әмма ул Аллаһы Тәгалә тыйган әйберне әйткәндә, ни өчен тыелганын да аңлатып калдырган. Мәсәлән, «Хәмер – бозыклыкның анасы», – дигән хәдискә шәрех ясаганда, акылы капланган кеше теләсә нинди бозыклык кыла ала, дип әйтәбез. Зина кылу – гаилә кыйммәтләрен юкка чыгара һ.б. Урлау – кешенең үзенеке булмаганга кул сузу, ягъни кемнеңдер эшләп тапкан әйберен җиңел юл белән генә үзеңнеке итү. Шуның кебек тартудан кешенең үз тәненә турыдан-туры зыян булганга күрә, галимнәр тарафыннан тәмәке дә тыела.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَأَنفِقُوا فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَلَا تُلْقُوا بِأَيْدِيكُمْ إِلَى التَّهْلُكَةِ وَأَحْسِنُوا إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ ﴿١٩٥﴾

**«Аллаһы юлында (малларыгызны мул итеп) сарыф итегез, үз кулларыгыз белән (үзегезне) һәлакәткә ташламагыз һәм (бөтен гамәлләрегезне, шул исәптән, мохтаҗларны каравыгызны да) ихсан кылыгыз! Һичшиксез, Аллаһы игелек кылучыларны сөя!**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:195

Шулай ук, тәмәкене агу дип алсак, бер генә кеше дә агу куллануны уңай күрмәс иде. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам дә: «Агу эчеп үз-үзегезне үтермәгез», – дип кисәткән.

Бу начар гадәттән ничек котылырга? Безнең күбебездә үзебез үк оялган һәм котылырга теләгән начар гадәтләр бар. Кемдер телевизор алдында озак утыра, кемдер күп ашарга гадәтләнгән һ.б. Ә кемдер, әлеге мәкаләбездә карап киткән тәмәкедән котыла алмый.

Ә болардан ничек котылып була соң? «Чир китә, гадәт кала», – дигәннәр, шуңа күрә иң беренче очракта сабырлык таләп ителәчәк. Начар гадәтләрдән котылыр өчен берничә киңәш бирәсе килә:

– тәмәке тартуның (яки башка бер начар гамәл булсын) чыннан да начар гадәт һәм аның зур проблема икәнен танырга кирәк;

– үз-үзеңдә ышаныч тудырырга тырышырга кирәк. Эчтән «Минем килеп чыкмый» кебек сүзләр артка чигенергә мәҗбүр итмәсеннәр, аларны җиңеп, булдыра алуыгызга инаныгыз;

– Аллаһы Тәгаләнең гөнаһлар кылганнан соң, тәүбәгә килгән колларны яратканын исегездән чыгармагыз. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Әгәр сез гөнаһ кылмасагыз, Аллаһы Тәгалә сезне юкка чыгарып, сезнең урыныгызга гөнаһ кылып, соңыннан тәүбә кылучы халыкка алыштырыр иде», – дип әйтә;

– физик күнегүләр ясый башлагыз, саф һавада йөрегез;

– максатлар куегыз һәм аларга таба барудан туктамагыз;

– Аллаһыдан ярдәм сорагыз.

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә дога кылучыларны ярата: моны исебездән чыгармасак иде. Үзебезне дә, якыннарыбызны да шушы начар гадәттән арындырып, Аллаһы Тәгалә каршында Аның яраткан коллары булып яшәргә насыйп булса иде.

*«Хозур» редакциясе*

*19 июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Ятимнәрне кайгырту – Пәйгамбәребез сөннәте

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы; безне нигъмәтләндереп торучы; мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Пәйгамбәребез зур гыйлемле, сабыр, түземле, оялчан булган. Ул Аллаһы Тәгаләгә бик күп гыйбадәт, калганнарга караганда күбрәк дога кылган. Кешеләрне гафу итә белгән, һәрдаим да яхшылыкка гына өнди торган булган. Ул һәрвакытта да гадел булырга, мохтаҗларга, ятимнәргә ярдәм итәргә, олыларны хөрмәт итәргә, туганнар арасындагы мөнәсәбәтне сакларга кушкан.

Әйе, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кылган изге гамәлләрнең саны юк. Бүгенге вәгазебездә, ин шә Аллаһ, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам бик яраткан, аны кылучыларга зур әҗерләр вәгъдә иткән гамәл турында сөйләшеп китәрбез, ул – ятимнәрне кайгырту.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтте:

فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ ۗ وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الْيَتَامَىٰ ۖ قُلْ إِصْلَاحٌ لَّهُمْ خَيْرٌ ۖ وَإِن
تُخَالِطُوهُمْ فَإِخْوَانُكُمْ ۚ ﴿٢٢٠﴾

**«Янә синнән ятимнәр хакында сорашалар. Аларның барча эшләрен ислах кылу, юлга салу алар өчен хәерле, дип әйт. Әгәр ятимнәрне үз гаиләгезгә кушсагыз, алар сезнең кардәшләрегездер».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:220

Ятимнәр сүзе Коръәни Кәримдә бик күп тапкыр очрый. Әгәр дә бу изге китапта берәр нәрсә күп тапкыр кабатланса, димәк, аңа зур игътибар итәргә кирәк. Аллаһы Тәгалә күп тапкырлар ятимнәрнең малын ашаучыларны кисәтә, аларга булышучыларны сөендереп, әҗер-савап вәгъдә итә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең урта һәм имән бармагына ишарәләп: «Өендәге ятим балага яхшы мөгамәләдә булган кеше белән мин җәннәттә болар кебек якын булырмын», – дип әйткән. Имән бармак белән урта бармакларның якынлыгы кебек, Пәйгамбәребез дә андый кешеләргә якын булыр, ин шә Аллаһ.

Исламгача кадәрге чорда ятимнәр бик күп булган. Аларны мыскыл иткәннәр, хакларын үтәмәгәннәр. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә ятим үскән һәм кабиләсенең ятимнәргә мөнәсәбәтен яхшы белгән. Аллаһы аңа мөрәҗәгать итеп:

أَلَمْ يَجِدْكَ يَتِيمًا فَآوَىٰ ﴿٦﴾

**«Раббың сине ятим хәлендә табып, тәрбия урынын насыйп итмәдеме?»** – дип әйтә.

«Духа / Иртән», 93:6

Һәм шуннан соң Ул аңа:

فَأَمَّا الْيَتِيمَ فَلَا تَقْهَرْ ﴿٩﴾

**«Шул сәбәпле, ятимнәрне җәберләмә»,** – дип боера.

«Духа / Иртән», 93:9

Аллаһы сөекле пәйгамбәрен Үзе тәрбияләгән, саклаган һәм шуңа күрә дә аңа башка ятимнәрне якларга, аларны кайгыртырга нәсыйхәтләгән. Әлбәттә, бу һәр мөэмингә дә кагыла торган боерык-нәсыйхәтләр булып тора.

Галәмнәр горурлыгы Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм ятимнәр мәсьәләсенә пәйгамбәрлегенең башлангыч чорында ук зур игътибар бирә башлый. Йәмәнгә беренче һиҗрәт кылучы мөселманнарның башлыгы Җәгъфар бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе илнең патшасы Нәҗашигә мөселманнар һәм Ислам дине турында сөйләгәндә, Пәйгамбәр галәйһиссәлам турында: «Ул һәрвакыт мохтаҗлар һәм көчсезләр янында, ул ятимнәрнең мөлкәтен кулланырга яки аны үзеңә алырга тыйды»[1], – дип әйтә.

Кадерле җәмәгать, вәгазебезнең мәүдугы, ягъни темасы – «Ятимнәрне кайгырту – Пәйгамбәребез сөннәте». Әгәр дә без ятимнәрне кайгыртуны Мөхәммәд галәйһиссәлам сөннәтен дә үтим дип башкарсак, Кыямәт көнендә шәфәгатькә ирешү өчен үзебезгә тагын бер мөмкинчелекне файдаланганбыз булып чыга. Ятим калган балалар проблемасы бүгенге көн өчен ят әйбер түгел. Ул бар, һәм көннән-көн арта гына да бара. Без яшәгән төбәктә балаларын бала тудыру йортларында ук калдырып чыгып киткән

1 Ибне Һишам, «Әс-Сиратүн-нәбәвия».

әниләр бар, яки тормыш авырлыкларына түзә алмыйча, ата-аналары интернатка илтеп биргән яки ата-анасы вафат булып, шулай ук интернатка эләккән балалар бик күп. Раббыбыз Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәрим китабында, расүлебез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең хәдисләрендә ятимнәрнең хакы турында бик күп тапкырлар әйтеп узалар. Ятимне тәэмин итү, аны карау һәм шул ятимне үзеңә алып тәрбияләү – ул бик саваплы, бик әҗерле. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә: «Иң күркәм йорт – ятимнәргә яхшы мөнәсәбәт күрсәтелгән йорт», – дип әйтә. Кем дә кем үзенең өенә ятимне алып кайтып тәрбияләсә, ул бик зур әҗергә ия кеше саналачак.

Әмма бүгенге көндә ятим балаларны алып, аларга тиешле акчаларны үзләштергән кешеләр дә бар. Пәйгамбәребез югарыдагы хәдисен дәвам итеп: «Иң начар йорт – ятимнәргә начар мөнәсәбәт күрсәтелгәне!» – дип әйткән. Коръәни Кәримдә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә ятимнәрнең малларын үзләштермәскә боера. Әгәр дә баланы начар ният белән, ягъни: «Хөкүмәт балага акча күчерәчәк, ул акчаны үземә тотачакмын», – дип алсак, яки баланың мирасы күп булып, аны да үзебезнеке итәргә тырышып кына баланы үзебезгә алсак, бу гөнаһлы эш булып санала. Аллаһы Тәгалә ятимнәргә начар мөнәсәбәттә булганнарны ялганчы да дип әйтә:

أَرَأَيْتَ الَّذِي يُكَذِّبُ بِالدِّينِ ﴿١﴾ فَذَٰلِكَ الَّذِي يَدُعُّ الْيَتِيمَ ﴿٢﴾ وَلَا يَحُضُّ عَلَىٰ طَعَامِ الْمِسْكِينِ ﴿٣﴾

**«Әллә син Кыяматне ялганга тоткан кешене күрмәдеңме? Ул ялганчы ятимне кагар. Үзен һәм башкаларны фәкыйрьләргә садака бирергә өндәмәс».**

«Магун», 107:1-3

Имансыз кешеләргә хас булган кайбер сыйфатлар: мохтаҗ булган, ятим кешеләргә, балаларга ярдәм итмәү. Әгәр кешенең йөрәге бик каты

икән, аңа хастаханәләрне, балалар йортларын зиярәт итәргә тәкъдим ителә.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә ятимнәрнең малларын ашаган кешеләрне болай дип кисәтә:

إِنَّ الَّذِينَ يَأْكُلُونَ أَمْوَالَ الْيَتَامَىٰ ظُلْمًا إِنَّمَا يَأْكُلُونَ فِي بُطُونِهِمْ نَارًا ۖ وَسَيَصْلَوْنَ سَعِيرًا ﴿١٠﴾

**«Ятимнәр малын ашаган кешеләр Ахирәттә, әлбәттә, җәһәннәм утына керерләр һәм карыннарын ут белән тутырырлар» .**

«Нисә / Хатыннар», 4:10

Гомумән алганда, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт фәрештәләре бар. Һәм алар берничә төрле йорттан кала, калган йортларга керергә мөмкиннәр. Нинди йортка рәхмәт фәрештәсе кермәс соң:

1. Әгәр бер йортта, нигездә ата-ана җәберләнсә, кыерсытылса, хаклары үтәлмәсә, бу йортка рәхмәт фәрештәләре кермәс;

2. Әгәр берәр йортта туганлык җепләре сакланмаса, шулай ук анда рәхмәт фәрештәләре кермәс;

3. Әгәр дә бер йортта ятимнәрнең малы ашалса һәм золым юл белән башка кешеләрнең малы тартып алынып, шул кулланылса, анда да Аллаһының рәхмәт фәрештәләре кермәс.

Әлбәттә, моның белән генә бетми, әмма әгәр берәр йортта ата-ана хакы үтәлмәсә, туганнар хакы онытылса һәм ятимнәргә тиешле игътибар бирелмичә, киресенчә начар карашка дучар булсалар, димәк, мондый йортларны фәрештәләр урап йөриләр. Золым ислам диненең һичбер шартына туры килмәгән һәм бер вакытта да хупланмаган, киресенчә, зур гөнаһлардан санала. Шул сәбәпле булса кирәк, хәдисләрдә мәзлум догасының кабул булуы хакында да күп сөйләнелә. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләреннән һәрвакыт: «Сез бүген ятимне башыннан

сыйпадыгызмы? Авыруның хәлен белдегезме? Берәрсенең кайгысын уртаклаштыгызмы?» – дип сорый торган була[1]. Ни өчен? Чөнки бер хәдистә: «Әгәр берәү Аллаһы ризалыгы өчен ятимне башыннан сыйпаса, Аллаһы аңа шушы ятимнең башындагы чәч бөртеге кадәр савап бирер», – дип әйтелгән[2].

Әгәр берәр кеше балалар йортыннан бала ала калса, аңа нәрсә эшләргә соң? Моңа «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт болай дип җавап кайтарды: «Баланы сабый чакта ук алсаң, ул әле бәләкәй була һәм шул вакытта тәрбиягә алган әни аны имезсә, ул сөт баласы дип аталыр. Шуңа да бу очракта мәхрәмлек мәсьәләсе, ягъни гаурәтне каплау кебек әйберләр җиңелрәк була. Бу турында Коръәндә дә әйтелеп китә. Әгәр дә без баланы алып кайтып, имезсәк, аңа калган балаларга караган кебек карарга, шулай ук киендерергә кирәк. Ул кыз бала икән, димәк, яулыксыз йөри ала. Ир бала икән, үги сеңелләрен яулыксыз күрә ала. Сөт балалардан бу гаурәт кебек мәсьәләләр төшеп кала. Әгәр дә без тәрбиягә бераз зуррак баланы алсак, бу вакытта гаурәт мәсьәләсенә җитди итеп карарга кирәк. Киенү, гаурәт мәсьәләләре саклаган булырга тиешләр. Шуңа күрә, дин ягыннан караганда гаурәт, киенү, мәхрәм мәсьәләләрендә проблема тумасын өчен, күкрәк баланы алсагыз яхшырактыр».

Кадерле җәмәгать, ятим балаларны кайгырту – бик зур эш икәнен күреп торабыз, һәм моның өчен әҗер савабы да күп булачак, ин шә Аллаһ. Шуңа өстәп, күз алдыгызга китерегез, сез шул баланы тәрбияләп, аңа яхшы тормыш бүләк итә аласыз. Аллаһы Тәгалә безгә мәрхәмәтле йөрәк, саф күңел һәм үткен фәһемлек бирсә иде. Әәмин!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Хәсәншәех авылы мәчете имам-хатыйбы*

---

1 Табәрани, Сахибүл-җәмигъ, 80.

2 Имам Әхмәд хәдисләр җыентыгыннан.

*26 июль вәгазе,*

*Зөлкагъдә аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Мәчетләрне хөрмәт итү

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмиин, әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлиһи Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмне юктан бар кылучы, Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмде-сәналәребез, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде һәм дә аның әһле бәйтенә сәләмнәребез ирешсә иде. Раббыбыз Аллаһының әмерен үтәп, Аның рәхмәтләренә ирешергә ният итеп, җомга намазына килгән мөэмин-мөселман кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ! Һәрберебезгә дә Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فِي بُيُوتٍ أَذِنَ اللَّهُ أَن تُرْفَعَ وَيُذْكَرَ فِيهَا اسْمُهُ يُسَبِّحُ لَهُ فِيهَا بِالْغُدُوِّ وَالْآصَالِ ﴿٣٦﴾

**«Ул яктылык бирә торган шәм мәчетләрдә булыр, Аллаһы ул мәчетләрне зурларга һәм Аллаһы исемен зекер итәргә боерды. Ул мәчетләрдә иртәләрдә һәм кичләрдә Аллаһыга тәсбих әйтерләр».**

«Нур», 24:36

Шул ук сүрәнең киләсе аятендә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

رِجَالٌ لَّا تُلْهِيهِمْ تِجَارَةٌ وَلَا بَيْعٌ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَإِقَامِ الصَّلَاةِ وَإِيتَاءِ الزَّكَاةِ ۙ يَخَافُونَ يَوْمًا تَتَقَلَّبُ فِيهِ الْقُلُوبُ وَالْأَبْصَارُ ﴿٣٧﴾

**«Алыш-биреш итеп сәүдә эшләренә алынмый торган ирләрне Аллаһы зекереннән, намаз укудан һәм зәкят бирүдән дөнья эше алдый алмады. Алар күңелләр һәм күзләр тетрәгән Кыямәт көненең катылыгыннан куркалар».**

«Нур», 24:37

Ошбу аятьләрдә Раббыбыз Аллаһы Тәгалә мәчетләрнең ни өчен кирәклеген аңлатып китә. Мәчетләр күңелләре һәм күзләре Кыямәт көненең катылыгыннан курыккан ирләр өчен дөнья эшләренә алданмыйча, сәүдә эшләрен калдырып торып, Аллаһыны зурлап зекер әйтү, намаз уку өчен кирәк.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кешеләр мәчетләр белән мактаныша башлаганчы Кыямәт купмас», – дип әйткән. Мәчетләрнең зурлыгы, матурлыгы, байлыгы, манараларының биеклеге һәм башка шуның кебек әйберләр белән мактанышу хәзерге вакытта мөселманнар арасында киң таралган һәм бу, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә, Кыямәт якынлашуның бер билгесе. Ягъни Пәйгамбәребез галәйһиссәлам безгә мәчетләрегез белән мактанмагыз һәм аларны бизәмәгез дигән. Мәчетләр белән мактанышулар Аллаһының хак дине булган Ислам диненә каршы килә, чөнки мәчетләр – Аллаһыга гыйбадәт кылу өчен генә билгеләнгән йортлар.

Башка бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мәчетләрегезне сабыйлардан, акылсызлардан, сату-алу эшләреннән, низаг-талашлардан, тавыш күтәрүдән саклагыз»,

– дип әйткән. Ягъни, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мәчетләрнең чисталыгын сакларга һәм анда Аллаһы Тәгаләне искә алуда комачаулый торган гамәлләрне кылмаска куша.

Язид Әл-Киндидән риваять ителә: «Гомәр радыяллаһу ганһе хәлифә булган вакытта, мәчеттә тавышларын күтәреп сөйләшүләрен ишеткәч, Гомәр бине Хаттаб миңа: «Теге икәүне китер әле» – диде һәм мин ул әйткән ике кешене чакырып китердем. Алардан «Сез кем?» – дип сорагач, үзләрен Таиф шәһәреннән булуларын әйттеләр. Гомәр: «Әгәр Мәдинә әһелләреннән булсагыз, сезгә җәза бирер идем. Аллаһының Илчесе мәчетендә нигә тавышыгызны күтәрәсез? Кайда икәнегезне белмисезме әллә?!» – дип әйтте. Ягъни, Гомәр радыяллаһу ганһе хәлифә булган вакытта, тавышланырга ярамый икәнен белеп тә, мәчеттә тавышланган кешегә суктырып җәза бирү каралган булган.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам мөселман кеше мәчеткә кергәндә: «Әй Аллаһы, миңа рәхмәт ишекләреңне ач», ә мәчеттән чыкканда: «Әй Аллаһы, миңа фазыйләт ишекләреңне ач», – дип дога кылырга өйрәтеп калдырган.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ ﴿٢٠٤﴾

**«Коръән укылганда яки Коръәннән вәгазь сөйләнгәндә ихлас тыңлагыз, сүз сөйләшмичә, эш эшләмичә тик торыгыз! Шулай итсәгез, шаять, рәхмәт кылынырсыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:204

Бу аятьтә аңлашылганча, Коръәнне намазда яки намаздан тыш уку, аны тыңлау һәм тыныч тору вәҗиб була. Мәчеттә гыйбадәттән тыш башка эшләр белән шөгыльләнү, сөйләшеп утыру, хәтта сөйләшми утырып та, Коръәнне тыңламау – Аллаһы Тәгаләнең әмеренә каршы килүне аңлата.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

قُلْ أَمَرَ رَبِّي بِالْقِسْطِ ۖ وَأَقِيمُوا وُجُوهَكُمْ عِندَ كُلِّ مَسْجِدٍ وَادْعُوهُ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ ۚ كَمَا بَدَأَكُمْ تَعُودُونَ ﴿٢٩﴾

**«Әйт: «Раббым һәр эштә гадел булырга өндәп әмер бирде, һәм мәчеттә йөзләрегезне кыйблага юнәлдерегез һәм динне Аллаһы ризалыгы өчен генә ихлас тотып, Аңа гына гыйбадәт кылыгыз, Ул сезне әүвәл ничек яраткан булса, шулай ук Аның хозурына кайтачаксыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:29

Шул ук сүрәнең 31 нче аятендә болай дип әйтелә:

يَا بَنِي آدَمَ خُذُوا زِينَتَكُمْ عِندَ كُلِّ مَسْجِدٍ وَكُلُوا وَاشْرَبُوا وَلَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ ﴿٣١﴾

**«Әй Адәм балалары, намаз укый торган урынга барганда һәрвакыт гаурәтләрегезне каплар өчен пакь киемнәр киегез, ашагыз, эчегез, ләкин исраф кылмагыз, Аллаһы исраф кылучыларны сөйми».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:31

Киемнәрне һәм башка нигъмәтләрне өйдә генә түгел, мәчеттә дә әйбәтләрен кулланырга кирәк. Шулай ук мәчтекә килгәч тә утны-суны исраф итмәү кирәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләренең берсендә болай дип әйткән: «Киемнәрегездән агын киегез, чөнки ул – киемнәрегезнең иң хәерлесе».

Хәдистә болай дип әйтелә: «Әгәр Аллаһы Тәгалә бер кавемгә чир җибәрергә теләсә, мәчет әһелләренә карар һәм ул бәлане кире кайтарыр».

Хәдистән аңлашылганча, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу өчен төзелгән мәчетләр булып һәм анда мәхәллә халкы даими намазга йөрсә, күп бәлаләр китергә мөмкин. Әгәр дә инде мәчетләр булып та, намазга йөрүчеләр булмаса, кайгы-хәсрәт китми, киресенчә, арта гына.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Сарыкларның бүресе булган кебек, шәйтан – кешенең бүресе, бүре көтүдән аерылган һәм читтә йөргән сарыкларны ала. Берүк, аерылудан сак булыгыз, җәмәгать белән, күпчелек белән һәм мәчетләр белән бергә булыгыз!»

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

وَأَنَّ الْمَسَاجِدَ لِلَّهِ فَلَا تَدْعُوا مَعَ اللَّهِ أَحَدًا ﴿١٨﴾

**«Барча мәчетләр дә бары тик Аллаһыга гыйбадәт кылу урыны, шулай булгач, Аллаһыдан башкага гыйбадәт кылмагыз һәм кяферләргә дога кылмагыз һәм бидгать гамәлләрне эшләмәгез».**

«Җиннун / Җен», 72:18

Сәхабәләр: «Мәчетләр – Аллаһының җирдәге йортлары. Мәчеткә Үзенә гыйбадәт кылырга килүчене Аллаһы, әлбәттә, хөрмәт кылыр», – дип әйткән. Ягъни, мәчеткә йөрүчеләргә Аллаһы Тәгалә Үзенең дөнья һәм Ахирәт нигъмәтләрен бирә. Мәчетләрдә золым кылу ярамаган кебек, башкаларга намаз кылырга, Коръән укырга, зикер әйтергә комачау итмәс өчен пышылдап сөйләшү дә тыела.

Без мөэмин-мөселманнар буларак, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтенә ияреп, Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәп, мәчетләргә җәмәгать намазына, кылган гыйбадәтләребезнең әҗер-саваплары күбрәк булсын дип киләбез. Мәчетләрне хөрмәт итү хакында Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Һәркайчан сезнең берегез икенде, яисә иртәнге намазын укыганнан соң мәчеткә керсә, намаз уку тиеш булмас, чөнки бу вакытта намаз уку тыелды. Ләкин бу

бәндә тәсбих әйтер, ягъни «Сөбеханәллаһ», янә тәһлил әйтер, ягъни «Ләә иләһә илләллаһ» һәм «Аллаһуммә салли галәә сәййидинәә Мухәммәдин вә галәә әәли сәййидинәә Мухәммәд», дип Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтер һәм ул намаз фазыйләтенә ирешер, янә мәчет хакын үтәде».

Мөселман кеше мәчеткә кергәч, беренче гамәл итеп нәфел тәхиййәтүл мәсҗид намазын укый. Мәчеткә бер карап чыгу өчен кергән кешегә мәчет намазы уку тиешле. Әмма ләкин икенде һәм иртәнге намазларын укыганнан соң, ошбу ике намазның вакыты чыкканчы мәчеткә керсә, тәхиййәтүл мәсҗид намазын укымый, чөнки бу вакытта шәригать буенча намаз уку тыелган. Бу вакытта мәчеткә кергән кеше тәсбих, тәһлил, Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә салават әйтсә, мәчет намазын укудан алган кадәр әҗер савабын ала. Әйткән зекерләре белән мәчет хакын да үти. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең иптәше Хәким бине Гомәйр әйтте: «Дөньяда кунак булыгыз. Мәчетләрне йортлар итегез. Күңелләрегезгә йомшаклыкны өйрәтегез, уйлау белән елауны күбәйтегез. Сезгә күңел теләкләре катнашмасын».

Бу сүзләрдән шул аңлашыла: дөньяда вакытта Аллаһы Тәгаләдә кунакта икәнебезне онытмыйча, тыйнак булырга кирәк. Мәчетләргә гаеттән гаеткә генә, шулай ук җомгадан җомгага гына да түгел, ә көн саен намазларга йөреп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен гыйбадәт кылырга кирәк.

Кеше йортына керсәк, үзебезне ничек яхшы итеп тотарга тырышабыз. Ә галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләнең йортларына керсәк, без үзебезне ничек тотарга тиеш соң?! Әлбәттә, күпкә әдәплерәк, тыйнаграк һәм Аллаһы Тәгалә каршында мескен бәндә һәм Аның колы икәнебезне тоеп керергә тиешбез.

Хәдистә: «Җир йөзендә Аллаһыга иң сөекле урыннар – мәчетләр, иң сөйкемсез урыннар – базарлар», – дип әйтелә.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә мәчетләрдә вакытыбызны күбрәк Үзенә гыйбадәт кылып үткәрергә насыйп әйләсен. Әәмин!

*Равил хәзрәт Нуруллин,*

*Яр Чаллы шәһәренең «Туфан» мәчете имам-хатыйбы,*

*Аксакаллар шурасы рәисе*

*2 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Безне иң нык яратучы

Галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә барча мактауларыбыз булса иде. Аның Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә дә йөрәк түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез булса иде.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әй, Аллаһының Илчесе! Мин Сине бик яратам!» – дип әйткән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аннан: «Балаларыңнан да артык яратасыңмы?» – дип сораган. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әйе», – дип җавап кайтарган. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аннан тагын сораган: «Гаиләң, малларыңнан да артык яратасыңмы?» Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әйе», – дип җавап кайтарган. «Үзеңнән дә артык яратасыңмы?» – дигән сорауга, Гомәр радыяллаһу ганһе: «Юк», – дип җавап биргән. Моңа Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җаным Аның кулында булган Аллаһы Тәгалә белән ант итәм, мине үзеңнән артык яратмасаң, иманың камил булмас!» Гомәр радыяллаһу ганһе бераздан әйләнеп килгән һәм әйткән: «Әй, Аллаһының Илчесе, мин сине үземнән артык күреп яратам!» Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шуннан соң аңа: «Әй Гомәр! Менә хәзер син мине чыннан да яратасың, менә хәзер синең иманың камиллеккә ирешште!» – дип җавап биргән.

Кадерле җәмәгать, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үз өммәтен, шул исәптән безне дә бик ярата һәм өммәте турында гел кайгырта. Без моның кадерен белергә һәм тиешенчә бәяләргә бурычлы. Бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән: «Нигә син ямансу, йөзең моңсу», – дип сорагач, ул: «Мин үземнең кардәшләремне сагындым», – дип җавап кайтарган. Сәхабәләр аңа: «Әй, Аллаһының Ил-

чесе галәйһиссәлам, без дә бит синең кардәшләрең», – дип әйткәннәр. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Сез минем сәхабәләрем. Мин үземнән соң киләчәк, мине күрмичә дә миңа инанган өммәтем кешеләрен сагынып көтәм, аларга сәлам җибәрәм», – дип җавап кайтарган.

Кадерле дин кардәшләрем, һәркайсыбыз да шундый көтеп алынган кеше булу өчен Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә чын-чынлап инанырга, аны барча кешеләрдән дә артык яратырга тиеш булабыз.

Шулай бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләре белән утырганда, аларга Ислам дине турында, Ахырзаман билгеләре турында сөйләгән: «Ахырзаман алдыннан минем өммәтемнән шундый кешеләр чыгар, аларның берсенең гамәле сезнең унысгызныкыннан артык булыр. Сез шундый заманда яшисез – дин боерганның уннан берен генә калдырсагыз да, сезгә һәлакәт килер. Шундый заман килер, үзенә боерылганның уннан берен генә үтәсә дә – котылыр». Шунда сәхабәләр Аллаһының Илчесеннән аларның нинди кешеләр булуын, аларның гамәлләре турында сораганнар. Аллаһының Илчесе болай дип җавап биргән: «Алар мине күрмичә, күргән кебек миңа инаныйрлар, фетнәгә каршы торырлар, алар ятимнәр кебек». Сәхабәләр гаҗәпсенеп: «Без дә бит сиңа инанабыз, исламны таратабыз, гыйбадәт кылабыз», – дип әйткәннәр. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларга: «Чынлыкта, мин сезнең белән, ә алар – миннән башка, ялгыз, үзләре генә», – дип әйткән һәм шунда галәмнең иң яхшы, иң кадерле җан иясенең күзләре яшьләнгән.

Бервакыт Гали радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өенә аның сөекле кызы Фатыйма радыяллаһу ганһәнең кулын сорарга килгән. Өйгә кергәч, оялуыннан, Пәйгамбәр галәйһиссәламнең кызының кулын ничек итеп сорарга белми торган. Әмма Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аның нигә килгәнен белә һәм аны тынычландырып, болай дип әйткән: «Мин синең кебек кешегә кызымны бирергә шат, әмма

Фатыйма радыяллаһу ганһәнең үз фикерен белергә рөхсәт ит». Фатыйма радыяллаһу ганһәдән Гали радыяллаһу ганһегә кияүгә чыгарга ризалыгын сорыйлар. Мәһәр буларак аңа 400 дирһәм тәкъдим ителә. Фатыйма радыяллаһу ганһә кияүгә чыгарга ризалыгын белдерә, әмма мәһәрдән ул канәгать булмый. Шунда ук алар янына Җәбраил галәйһиссәлам килеп җиткән һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә сезнең мәһәргә җәннәткә керүегезне дә өсти». Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам кызыннан: «Хәзер син ризамы инде? – дип сораган. Ә кызы һаман баш тарткан. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кызыксынып: «Син тагын нәрсә телисең?» – дип сораган. Кызы әтисенә: «Мин мәһәр буларак синең өммәтеңнең котылуын телим. Син өммәтең өчен бик борчыласың бит», – дип әйткән. Шулвакыт Җәбраил галәйһиссәлам күккә ашкан һәм берникадәр вакыттан соң Аллаһы Тәгаләдән кәгазьдә беркетелгән мәһәр белән кире кайткан. Фатыйма радыяллаһу ганһә: «Аллаһы Тәгалә шушы килешү буенча безнең өммәтне коткарырга рөхсәт бирсен өчен, мин аны Раббыбызга күрсәтәчәкмен», – дип әйткән.

Бу аңа ни өчен шулкадәр әһәмиятле иде соң? Без бит аның өчен бернинди дә яхшылык эшләмәдек һәм эшли алуыбыз да икеле. Ә сәбәп шунда ки, Фатыйма радыяллаһу ганһә әтисенең өммәте өчен кайгырып, ничек газапланганын, йокысыз төннәрен, түккән күз яшьләрен күреп үскән. Хәтта тормышының соңгы минутларында да Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе турында түгел, ә безнең турында уйлады. Кыямәт көнендә безнең хәлебез ничек булыр, без кайларда булырбыз – ул шуларны уйлап борчылды.

Үлем фәрештәсе Газраил галәйһиссәлам Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җанын алырга килгәч, аңа ихтирамсыз булудан куркып, өенең бусагасында туктап кала. Аңа сәлам бирә һәм керергә рөхсәт сорый. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны

керергә чакыра, Җәбраил галәйһиссәламнең кайдалыгын сорый. Газраил галәйһиссәлам аңа: «Барча фәрештәләр дә күкнең түбәнге катында сиңа тәгъзия (юату) белдерергә җыендылар», – дип җавап кайтара. Шунда Җәбраил галәйһиссәлам килеп керә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аннан: «Минем өчен сөенечле хәбәр бармы?» – дип сорый. «Җәннәт капкалары синең өчен ачык», – дип җавап кайтара Җәбраил галәйһиссәлам. Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Мин бу турыда сорамадым, мине шатландырырлык башка нәрсә юкмы?» – дип кабат сорый. «Җиде кат күкнең барча фәрештәләре сине каршы алырга әзер», – дип җавап бирә Җәбраил галәйһиссәлам. Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам соравын кабатлап, үлем алды мизгелендә дә өммәтенең киләчәге турында борчылуын белдерә. Ниһаять, Җәбраил галәйһиссәлам аңа Аллаһы Тәгаләдән шатлыклы хәбәр китерә: «Җәннәткә беренче булып син һәм синең өммәтең керәчәк. Өммәтең кереп бетмичә, башка халыклар өчен җәннәт ябык булачак».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тынычлана, чөнки аның хыялы тормышка аша һәм ул үлем фәрештәсенә җанын алырга рөхсәт бирә.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, күрәсезме, Аллаһының Илчесе безне ничек ярата, әле хәзер дә Аллаһы Тәгаләдән безнең гөнаһларыбызны кичерүен сорый. Пәйгамбәребез һәрвакыт, хәтта каберендә дә безнең өчен догада. Вафат булгач һәркайсыбызның да гамәл дәфтәрләребез аңа күрсәтеләчәк. Ул үзе шулай дип белдерә: «Минем вафат булуым да сезнең өчен хәерледер. Сезнең гамәлләрегез миңа күрсәтелеп тора. Берәр яхшы гамәл күрсәм, Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтәм. Берәр начар гамәл күрсәм, Аллаһымнан сезнең өчен ярлыкау үтенәмен». Инде уйлап карыйк: Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шундый ихлас яратуына без лаеклымы соң? Бу мәхәббәткә без бүген нәрсә белән җавап кайтарабыз?!

Безнең һәрбер яңа гөнаһыбыз Аллаһының Илчесе, сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күз яшьләренә сәбәп булып тора.

Газиз кардәшләрем, Аллаһы Тәгаләдән Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам өммәтенә рәхмәтен һәм ярлыкавын сорыйбыз. Аның белән Фирдәвес җәннәтләрендә бергә булсак иде. Әәмин.

*Мәүлетдин хәзрәт Галиев,*

*Арча районы Иске Кишет авылы имамы ярдәмчесе*

*9 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Корбан чалу Аллаһыга якынайта

Барча мактаулар, хәмде-сәналәр Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булса иде. Аның хак хәбибе, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә дә күңелләребезнең түрләреннән чыкан салават-шәрифләребез булса иде.

Улы Исмәгыйльне корбан итәргә алып барганда, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шәйтан анын янына килеп вәсвәсә кылып: «Сине әтиең үтерергә алып бара. Кач тизрәк», – дип әйтә. Сөекле әти-әнисенең һәм Раббысының сүзеннән чыгарга ияләшмәгән бала: «Мин Аллаһы әмеренә каршы килмим. Әтием барын да белеп эшли», – дип, мәльгунне ташлар атып куып җибәрә.

Ата белән ул Аллаһының боерыгына каршы килмиләр, итагать итәләр. Аллаһы Тәгалә Үзенең киң рәхмәте итеп Исмәгыйльне саклап кала. Ата кешенең кисәр өчен кулындагы пычагы үтми. Корбан итәргә дип Җәбраил фәрештә җәннәттән сарык китерә.

Бу тарихи вакыйга барыбыз өчен дә бик мөһим һәм гыйбрәтле. Шул ук вакытта без бу кыйссадан Аллаһының киң кодрәтен күрәбез.

Ошбу бәйрәмгә карата берничә мәсьәләне карап китәсе килә. Корбан чалу кайсы хөкемгә керә? Һәм кешегә бу гамәл мәҗбүри булсын өчен нинди шартлар үтәлергә тиеш соң? Байлыгы һәм мөмкинчелеге булган һәрбер мөселман кешесе өчен корбан чалу вәҗиб гамәл санала. Шулай ук бу эшкә тотынган кешенең акыллы, балигъ яшендә булуы, сәфәрдә булмавы шарт. Әгәр дә инде мөмкинчелеге булмаса, чалмаса да гөнаһ булмас. Шулай да бу изгелекле эшнең әҗере бик бөек икәнлеген онытырга ярамый, чөнки корбан чалганда хайванның беренче тамчы каны җиргә

тамганчы ук суючының гөнаһлары кичерелә. Бу гамәлдә, башкалардагы кебек үк, ният мөһим әһәмияткә ия. Аллаһы Тәгалә Хаҗ сүрәсенең 37 нче аятендә болай дип әйтеп үтә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ ﴿٣٧﴾

**«Сез чалган дөяләрнең итләре, каннары Аллаһыга ирешмәс, бәлки тәкъвалыгыгыз вә изге гамәлләрегез генә ирешер».**

«Хаҗ», 22:37

Корбан ите кемнәргә таратылырга тиеш? Корбан, нигездә, фәкыйрь, мохтаҗ, мескен, ятим, кимчелекле кешеләргә, тол хатыннарга, сәфәрдә булучыларга өләшенә. Корбанлык итен ике төрле юл белән корбан әһелләренә ирештерәләр. Берәүләр итне кисәкләргә бүлеп тарата; икенчеләр, табын ясап, мохтаҗ кешеләрне чакырып, Коръән мәҗлесе үткәрә. Икесе дә күркәм гамәл санала. Һәм ничек эшләсәң дә дөрес була.

Тагын бер мәсьәлә: корбан ителәсе хайванның кимчелекләре булырга тиеш түгел. Дөрестән дә, әгәр дә хайванның кайбер кимчелекләре булса, аны корбан итәргә була әле. Алар түбәндә:

1. Хайванның күзе начар күрсә;

2. Хайванның бер аягы чатанлап, ләкин бу аның йөрүенә комачау итмәсә;

3. Тумыштан мөгезләре яисә мөгезенең бер өлеше булмау;

4. Колаклары тишелгән булу;

5. Берничә теше булмау;

6. Койрыгының яки колагының зур булмаган бер өлеше булмау. Ләкин иң яхшысы хайванның бу кимчелекләрдән пакь булуы. Ә кайбер җитдирәк кимчелекләр аркасында хайваннар корбанга чалынырга лаек түгел. Алар түбәндә:

1. Бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булса;

2. Аксаклыгы берәр урынга барып җитәр өчен комачау итсә;

3. Бер яки ике колагы да тулысынча кисеп атылган булса;

4. Күпчелек тешләре булмаса;

5. Бер яки ике мөгезе төптән сынган булса;

6. Койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булса;

7. Имчәкләре булмаса;

8. Бик тә хәлсез хайван булса;

9. Тумыштан колаксыз яки койрыксыз булса;

10. Көтүдәге калган хайваннарга кушыла алмаслык дәрәҗәдә котырынган булса;

11. Нәҗес (чиста булмаган ризык) белән тукланса.

Ә корбанга чалынырга кайсы хайваннар лаеклы соң? Алар – сарык, кәҗә, сыер, үгез, дөя. Калган хайваннарны корбанга тотарга ярамый. Югарыда әйтелгән хайваннар ата җенесеннән дә, ана җенесеннән дә була ала. Нигездә, сарык яисә кәҗә сую хуплана. Алар бер еллык булырга тиеш. Әгәр дә сарык ярты еллык, әмма көр һәм таза, бер еллык кебек булса, аны да ярый. Ә эре мөгезле хайваннар ике яшьлек, дөя биш яшьлек булырга тиеш. Эре мөгезле хайван белән дөя бер кешедән дә, җиде кешедән дә чалына ала. Ләкин бергәләп эре хайванны чалырга теләгән кешеләрнең нияте Аллаһы ризалыгы өчен генә булырга тиеш. Әгәр дә инде араларыннан берсе ит алырга теләгәннән генә чалса, берсенең дә корбаны кабул ителми.

Корбан чалу рәвеше: башта тыныч кына итеп корбанны чалынасы урынга илтеп җиткерергә кирәк. Аннары газапламыйча, сул ягына яткырырга һәм башын кыйблага борып куярга кирәк. Вак мөгезле хайванның арткы уң аягыннан кала өч аягы да бәйләнә. Чаласы кеше ниятен әйтә, янәшәдәгеләр тәкбир әйтә. Шуннан «Әл-Әнгам» сүрәсенең бер өлеше укыла:

قُلْ إِنَّ صَلَاتِي وَنُسُكِي وَمَحْيَايَ وَمَمَاتِي لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ﴿١٦٢﴾
لَا شَرِيكَ لَهُ ﴿١٦٣﴾

**«Әйт: «Дөреслектә, минем намазым, гыйбадәтем Аллаһыга, яшәвем дә, үлемем дә Галәмнәрнең Раббысы ихтыярында, Аңа тиңдәшләр юк».**

«Әл-Әнгам / Терлек», 6:162-163

Моннан соң «бисмилләһи» дип хайван чалына һәм дога кылына.

Өстәмә рәвештә ике рәкәгать нәфел намазын укырга була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Корбан чалган кеше пычагын куйгач та, ике рәкәгать намаз укыса, Аллаһы аңа ни теләсә, шуны бирер», – дип әйткән.

Чалынган корбанның ите ничек таратыла? Итне өч өлешкә бүлү яхшы. Бер өлеше күршеләргә һәм туганнарга таратыла, икенчесе – ярлыларга һәм мескеннәргә, ә өченче өлеше чалучының гаиләсенә кала.

Корбан чалуның үз хикмәте һәм файдасы да бар икәнен онытмаска кирәк. Корбан чалу, беренчедән, Аллаһыга һәм Аның ризалыгына якынайта. Раббыбыз ул корбанга мохтаҗ түгел, тик Ул моның белән безнең Үзенә якынлык дәрәҗәсен тикшерә. Шулай ук корбан Исмәгыйль галәйһиссәлам кыйссасын искә төшерә, аның коткарылуы хакында фикерләвебезне яңарта. Мөселманнарның корбан чалуы – аларның Аллаһы юлында малларын кызганмавын күрсәтә. Бу канун мескеннәрне һәм ятимнәрне шатландыруга китерә.

Ә файдасына килгәндә, кешенең гөнаһлары ярлыкана, ул Аллаһыга шөкер итеп, Аның алдында булган бурычын үти; чалынган хайван Кыямәт көнендә чалучыны Сират күпере аша алып чыга һәм аның котылуында сәбәпче була. Мескен, ятимнәрне сөендереп, без аларның канәгатьләнүенә ирешәбез.

Күпләребез бу йоланы авылларына якыннары янына кайтып үти, ә менә андый мөмкинчелекләре булмаучыларга берәр урынга мөрәҗәгать итеп булмыймы диючеләр дә бар? Моның өчен Казаныбызның махсус кайбер җирләрендә корбан чалу урыннары әзерләнгән.

Кардәшләрем, шушы олуг бәйрәмебез белән тәбрик итәм. Аллаһы Тәгалә чалыначак корбаннарыбыздан риза булсын, барыбызга да һәрвакыт Аның рәхмәтен тоеп яшәүне насыйп итсен.

*Тимергали хәзрәт Юлдашев,*

*«Саләх» мәчете имам-хатыйбы*

# Корбан гаете хотбәләре

## خُطْبَةُ عِيدِ الاَضْحَى

## الْخُطْبَةُ الْاُولَى

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَقَدَّسَ ذَاتُهُ عَنِ الشِّرْكِ وَالزَّوَالِ وَنَطَقَتِ الْاَدِلَّةُ بِاَوْصَافِهِ الْجَلاَلِ وَالْجَمَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ تَحَيَّرَ فِي كُنْهِ ذَاتِهِ الْعُقُولُ وَالْاَفْهَامُ وَعَجَزَ عَنْ اِدْرَاكِ صِفَاتِهِ الرَّاسِخُونَ الْاَعْلاَمُ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. سُبْحَانَ مَنْ اَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِالشُّهُورِ وَالْاَيَّامِ فِصَالِ. وَاَوْجَبَ فِي هَذِهِ الْاَيَّامِ عَلَى الْاَغْنِيَآءِ الْحَجَّ وَالطَّوَافَ بِالْبَيْتِ الْمُكَرَّمِ عِنْدَ الْكَبِيرِ الْمُتَعَالِ.

اَللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ لاَ اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ اَكْبَرُ اَللَّهُ اَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ. نَحْمَدُ اللَّهَ الَّذِي لَمْ يَتَّخِذْ صَاحِبَةً وَلاَ وَلَدًا وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَلَمْ يَكُنْ لَّهُ وَلِيٌّ مِّنَ الذُّلِّ وَكَبِّرْهُ تَكْبِيرًا وَاَشْهَدُ اَنْ لَّا اِلَهَ اِلاَّ اللَّهُ

وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَفِيعُ الْعُصَاةِ فِي يَوْمِ الْجَزَاءِ بِاَمْرِ اللَّهِ الْكَرِيمِ الْمُتَعَالِ.

صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى وَسَلَّمَ عَلَيْهِ وَعَلَى ءَالِهِ وَاَصْحَابِهِ الْمَوْصُوفِينَ بِاَحْسَنِ الْاَخْلاَقِ وَاَطْيَبِ الْاَحْوَالِ.

يَا اَيُّهَ النَّاسُ. اِعْلَمُوا اَنَّ يَوْمَكُمْ هَذَا يَوْمٌ شَرِيفٌ وَعِيدٌ لَّطِيفٌ لِّلْخَوَاصِّ وَالْعَوَامِّ يَوْمٌ عَظِيمٌ قَدَرُهُ لِلْاَنَامِ، عَظِّمُوا هَذَا الْيَوْمَ بِالْاِنْعَامِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيْصَالِ الْاَرْحَامِ. اِنَّ اللَّهَ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا النَّحْرَ بِقَوْلِهِ وَانْحَرْ، وَاَمَرَ خَلِيلَهُ بِذَبْحِ وَلَدِهِ الْاَشْهَرِ وَاُفْدِيَ بِكَبَشٍ مِّنَ الْجَنَّةِ بِوَاسِطَةِ الْمَلَكِ الْمُقَرَّبِ وَلاَ يَجِبُ عَلَى الْفَقِيرِ عَلَى الْقَوْلِ الْمُعْتَبَرِ الْبُدْنَةُ عَنْ سَبْعَةٍ وَالضَّأْنُ وَالْمَعْزُ عَنْ وَاحِدٍ مُجْزِأَةٌ وَلاَ يَجُوزُ الْعَجْفَآءُ وَالْعَرْجَآءُ وَمَقْطُوعَةُ الْاُذُنِ وَالْاِلْيَةِ وَالَّذِي لاَ يَمْشِي عَلَى الْمَنْسَكِ عِنْدَ الْمَذْهَبِ الْمُعْتَبَرِ.

ضَحُّوا عَنْ اَطْيَبِ اَمْوَالِكُمْ وَعَظِّمُوهَا امْتِثَالاً لِّاَمْرِ رَسُولِ اللَّهِ الْمُقَرَّرِ كَمَا قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: عَظِّمُوا ضَحَايَاكُمْ فَاِنَّهَا عَلَى الصِّرَاطِ مَطَايَاكُمْ. وَاِنَّ اللَّهَ تَعَالَى اَوْجَبَ عَلَيْنَا تَكْبِيرَ التَّشْرِيقِ عَقِبَ الْفَرْضِ مِنْ فَجْرِ يَوْمِ عَرَفَةَ اِلَى اخِرِ اَيَّامِ التَّشْرِيقِ بِقَوْلِهِ تَعَالَى: وَاذْكُرُوا اللَّهَ فِي اَيَّامٍ مَّعْدُودَاتٍ. اَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَنِ

الرَّحِيم: يَآ اَيُّهَ الَّذِينَ ءَامَنُوا اتَّقُوا اللّٰهَ وَلْتَنْظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ وَاتَّقُوا اللّٰهَ اِنَّ اللّٰهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ.

بَارَكَ اللّٰهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرْءَانِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَاِيَّاكُمْ بِالْاَيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ وَاَسْتَغْفِرُ اللّٰهَ الْغَفَّارَ لِي وَلَكُمْ وَلِسَائِرِ جَمَاعَةِ الْمُسْلِمِينَ الْحَاضِرِينَ اَجْمَعِينَ اِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ.

## الْخُطْبَةُ الثَّانِيَةُ

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذُ بِاللّٰهِ مِنْ شُرُورِ اَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ اَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللّٰهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ. وَاَشْهَدُ اَنْ لَا اِلَهَ اِلاَّ اللّٰهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَاَشْهَدُ اَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ.

اِنَّ اللّٰهَ وَمَلاَئِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ. يَآ اَيُّهَا الَّذِينَ ءَامَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا.

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ صَلَّى وَصَامَ.

اَللّٰهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى ءَالِ مُحَمَّدٍ بِعَدَدِ مَنْ قَعَدَ وَقَامَ.

صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ وَعَلَى جَمِيعِ الْاَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى اَهْلِ طَاعَتِكَ اَجْمَعِينَ مِنْ اَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْاَرَضِينَ. وَارْحَمْنَا وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ الْاَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْاَمْوَاتِ اِنَّكَ اَنْتَ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ وَمُنْزِلُ الْبَرَكَاتِ وَرَافِعُ الدَّرَجَاتِ وَقَاضِيُ الْحَاجَاتِ بِرَحْمَتِكَ يَا اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ.

اَللّٰهُمَّ ارْحَمِ الْخُلَفَاءَ الرَّاشِدِينَ وَالْاُمَرَاءَ الْمَاضِينَ الَّذِينَ قَضَوْا بِالْحَقِّ وَكَانُوا يَعْدِلُونَ.

اَللّٰهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ وَاهْدِ مَنْ خَذَلَ الدِّينَ.

عِبَادَ اللّٰهِ، اِنَّ اللّٰهَ يَاْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْاِحْسَانِ وَاِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ.

اُذْكُرُوا اللّٰهَ الْعَلِيَّ الْعَظِيمَ الْحَيَّ الْقَيُّومَ يَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوهُ يَزِدْكُمْ وَاسْتَغْفِرُوهُ يَغْفِرْ لَكُمْ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ تَبَارَكَ وَتَعَالَى اَعْلَى وَاَوْلَى وَاَعَزُّ وَاَجَلُّ وَاَعْظَمُ وَاَتَمُّ وَاَكْبَرُ.

## Корбан гаете хотбәсенең кириллицага транскрипциясе

### Беренче хотбә

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллаһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән тәкаддәсә ҙәәтүһү ганиш-ширки вәззәүәәл. Вә нәтакатил-әдилләтү би әүсаафиһил-җәләәли вәлҗәмәәл.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр, вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мәң тәхәййәра фии күнһи ҙәәтиһил-гукуулү вәл-әфһәәм, вә гаҗәзә ган идрааки сыфәәтиһир-раасихуунәл-әгъләәм.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Сүбхәәнә мән әкрамә гыйбәәдәһүл-мүэминиинә бишшүһүүри вәл-әййәәмил-фисааль. Вә әүҗәбә фии һәәҙиһил-әййәәми галәл-әгънийәәил-хәҗҗә вәт-таүәәфә бил-бәйтил-мүкәррами гыйндәл-кәбиирил-мүтәгааль.

Аллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр. Ләә иләәһә илләллааһү, вәллааһү әкбәр, Аллааһү әкбәр вә лилләһил-хәмд. Нәхмәдүллааһәл-ләҙии ләм йәттәхыйҙ саахибәтәү-үә ләә вәләдә, вә ләм йәкүнләһү шәриикүң фил-мүлки, вә ләм йәкүнләһү вәлииййүн-минәҙ-ҙүлли вә кәббирһү тәкбиираа. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллааһү вәхдәһүү ләә шәриикә ләһ. Вә әшһәдү әннә сәййидәнәә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһү шәфиигуль-гусаати фии йәүмил-җәзәә’и би әмрилләәһил-кәриимил-мүтәгааль. Салләллааһү тәгааләә вә сәлләмә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсхәәбиһил-мәүсууфиинә би әхсәнил-әхъләәкый вә әтъйәбил-әхүәәл.

Йә әййүһән-нәәс! Игъләмүү әннә йәүмәкүм һәәҙәә йәүмүн шәриифүн вә гыйидүн ләтыйифүн лил-хаүәәссый вәл-гаүәәмм. Йәүмүн гаҙыймүң кадәруһү лил-әнәәм. Гаҙҙыймүү һәәҙәл йәүмә бил-ингаами вәл-ихсәәни вә

иисаалил-әрхәәм. Вә иннәллааһә тәбәәракә вә тәгәәлә әүҗәбә галәйнән-нәхра би каулиһи вәнхәр. Вә әмәра халииләһүү би ҙәбхи вәләдиһил-әшһәри вә үфдийә би кәбәшин минәл җәннәти би вәәситатил-мәләкил-мукарраб, вә ләә йәҗибү галәл-фәкыйри галәл-каулил-мүгьтәбәр. Әл-будһәтү ган сәбгәтин вәд-да'нү вәл-мәгзү гән вәәхидин муҗзиәтү вә ләә йәҗүүзүл-гәҗфәәә'ү вәл-гарҗәәә'ү вә мәкътуугәтүл-үҙүни вәл-илйьәти вәлләзии ләә йәмшии галәл-мәнсәки гиндәл-мәҙһәбил-мүгътәбәр.

Даххүү ган әтъйәби әмүәәликүн вә гаҙҙыймүүһәәмтиҫәәлән лиәмри расүүлилләәһил-мукаррар. Кәмәә каалә расүүлүллааһи салләллаһү галәйһи вә сәлләм: «Гәҙҙыймүү дахәәйәәкүм фәиннәһәә гәләс-сыйраати мәтаайәәкүм». Вә иннәллааһә тәгәәләә әүҗәбә галәйнәә тәкбиират-тәшриикый гәкыйбәл-фәръды мин фәҗри йәүми гарафәтә иләә әхыйри әййәәмит-тәшриикый би каулиһи тәгалә: «үәҙкүруллааһә фии әййәәмим-мәгъдүүдәәт». Әгүүҙү билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим: Йәә әййүһәлләҙиинә әәмәнүт-тәкуллааһә вәлтәңзур нәфсүм-мәә каддәмәт ли-гаад. Вәттакуллааһә иннәллааһә хабиирум бимәә тәгъмәлүн.

Бәракә Ллаһу ләнә вә ләкум фил-Куръәнил-гаҙыйм, вә нәфәганәә вә ийәкүм бил-әәйәәти вәҙ-ҙикрилхәкиими вә әстәгъфируллаһәл-гаффәәра лии вә ләкүм вә лисәә'ири җәмәәгәтил-мүслимиинәл-хәәдыйриинә әҗмәгыйн. Иннәһү һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүс-сәмиигуль-гәлиим.

## Икенче хотбә

Әлхәмдү лилләәһи нәхмәдүһү вә нәстәгинүһү вә нәстәгъфируһү вә нү'минү биһи үә нәтәүәккәлү гәләйһи вә нәгүүҙү билләәһи мин шүруури әңфүсинәә вә мин сәййиәәти әгмәәлинәә мән-йәһдиһил-Лләәһү фәләә мүдыйллә ләһү вә мән-йүдълилһү фәләә һәәдийә ләһ. Вә әшһәдү әлләә

иләәһә илләллааһү вәхдәһү ләә шәриикә ләһү вә эшһәду әннә Мүхәммәдән гәбдүһү вә расүүлүһ.

Иннәллаһә вә мәләәикәтәһүү йүсаллүүнә галән-нәбий. Йәә әййүһәлләẓиинә әәмәну саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән салләә вә саам. Аллаһүммә салли галәә Мүхәммәдин вә галәә әәли Мүхәммәдин бигадәди мән кагәдә вә каам.

Салли вә сәллим гәләйһи вә гәләә җәмиигиль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин. Вә галәә мәләәикәтикәл-мукаррабиинә вә галәә әһли таагәтикә әҗмәгиин мин әһлис-сәмәәүәәти вәл-әрадиин. Вәрхәмнәә вәхшүрнәә мәгәһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимин.

Аллаһүммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәә'и минһүм вәл-әмьүәәт, иннәкә әнтә мүҗиибүд-дәгәүәәт вә мүнзилүл-бәракәәт, вә раафигуд-дәраҗәәт, вә каадыйүл-хәәҗәәт, бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Аллаһүммәр-хәмил хуләфәә'әр-раашидиинә вәл-үмәрааа'әл-мәдыйнәл-ләẓиинә кадау билхәккы вә кәәнүү йәгъдилүүн. Аллаһүммән-сурмән нәсараддиинә вәһди мән хаẓәләддиин. Гибәәдәллааһ, иннәллааһә йәъ'мүрү бил-гадли вәл-ихсәәни вә ийтәәәи ẓил-курбәә вә йәнһәә ганил-фәхшәәәи вәл-мүнкәри вәл-бәгъйи йәгыйиẓукум ләгәлләкүм тәẓәккәрүүн. Үẓкүруллааһәл-галиййәл-гаẓыымәл-хәййәл-каййүүм, йәẓкүрүкүм вәшкүрүүһү йәзидкүм, вәстәгъфирууһүү йәгъфир ләкүм вә ләẓикруллааһи тәбәәракә вә тәгәәләә әгләә вә әүләә вә әгәззү вә әҗәллү вә әгẓамү вә әтәммү вә әкбәр.

## Корбан гаете хотбәсенең тәрҗемәсе

### Беренче хотбә

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Ширек һәм юкка чыгу кебек сыйфатлар каршында мөкатдәс булган Аллаһының заты барча кимчелекләрдән пакьтер. Аллаһының матурлыгына һәм олуглыгына барлык мәхлүкъләр дәлил булып тора.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Аллаһының үзенчәлегенә (Аның рәхмәтле Зат булганына) акыл ияләре хәйран калды.

Аның сыйфатларына төшенүдән тирән белем ияләре гаҗиз калды.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Мөэмин колларына карата айлар һәм көннәр аша юмартлык күрсәткән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер. Бу көннәрдә байларга хаҗны, Олуг Аллаһы каршында изге йорт булган Кәгъбәтуллаһны тәваф кылырга йөкләгән Зат барча кимчелекләрдән пакьтер.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек һәм Аллаһыга мактаулар булсын!

Үзенә тормыш иптәше алмаган, балалар тудырмаган, падишаһлыгында тиңдәше булмаган, кимсетелүдән коткаручы дустына мохтаҗ булмаган Аллаһыны мактыйбыз һәм Аңа тәкбир әйтегез. Аллаһыдан башка бернинди илаһ булмаганлыгы турында гуаһлык бирәм, Ул — бердәнбер, Аның тиңдәше юк, Пәйгамбәребез Мөхәммәд Аның колы һәм расүледер. Ул (Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм) җәза алу көнендә гөнаһлылар өчен юмарт булучы һәм олуг Аллаһының әмере белән шәфәгать кылучыдыр.

Аллаһы Тәгалә аңа, аның гаиләсенә, иң күркәм әхлак һәм иң яхшы әхвәл белән сыйфатланган сәхабәләренә салават һәм сәлам ирештерсен.

Әй кешеләр! Белегез ки, сезнең бу (бәйрәм) көнегез — хөрмәтле көндер, байлар һәм ярлылар өчен юмартлык бәйрәмедер, бу көннең кадере халыклар өчен бөектер, бу көнне изгелек, ихласлылык, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгыту аша бөекләгез. Чынбарлыкта, безгә Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Корбанны «Корбан чал!» дип йөкләде. Шулай ук Үзенең хәлиленә (Ибраһим галәйһиссәламгә) иң танылган баласын корбан итәргә боерган. Якын фәрештә (Җәбраил галәйһиссәлам) аша җәннәттән куй бирелгән. Иң могтәбәр сүзгә таянсак, фәкыйрь корбан чалырга тиеш түгел. Эре терлек җиде кешедән һәм бәрән вә кәҗә бер кешедән йөкләмәне төшерә. Могтәбәр мәзһәб буенча, сукыр, аксак, колагы киселгән, җенес әгъзасы өзелгән, мөгезе сынган һәм корбан чалу урынына үзе бара алмаслык дәрәҗәдә хәлсез булган терлек корбанга ярамас.

Корбаннарыгызны иң яхшы малларыгыздан чалыгыз, һәм Аллаһы Расүленең әмеренә буйсынып, корбаннарыгызны хөрмәт итегез (чалганда йомшаклык күрсәтегез). Аллаһының Расүле (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дип әйткән: «Корбанлыкларыгызны хөрмәт итегез, ник дисәгез, алар Сират күперендә сезнең утырып чыга торган хайваннарыгыздыр». Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә безгә фарыз намазларыннан соң тәкбир-тәшрикъне Гарәфә көненең иртәнге намазыннан алып, Тәшрикъ көненең ахырына кадәр Үзе йөкләгән: «Саналган көннәрдә Аллаһыны искә алыгыз», – дигән. Таш белән атылган шәйтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, Шәфкатьле Аллаһы исеме белән.

Аллаһы Коръәндә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَلْتَنظُرْ نَفْسٌ مَّا قَدَّمَتْ لِغَدٍ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ ۚ إِنَّ
اللَّهَ خَبِيرٌ بِمَا تَعْمَلُونَ ﴿١٨﴾

**«Әй иман китергән кешеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм һәр җан иясе иртәгәсе көн өчен нәрсә әзерләгәнен күрсен. Аллаһыдан куркыгыз, дөреслектә, Аллаһы Тәгалә эшләрегездән хәбәрдар».**

«Хәшер / Сөреп Чыгару», 59:18

Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Гөнаһларны гафу итүче Аллаһы каршында үзем һәм сезнең өчен, шулай ук башка мөселман җәмәгатьләренең бөтенесе өчен, Аллаһы каршында истигъфар кылам (ярлыкау сорыйм). Чынбарлыкта Ул (Аллаһы) — Гафу итүче, Рәхимле, Данлы, Юмартлык иясе, Ишетүче һәм Белүче.

## Икенче хотбә

Аллаһыга мактау булсын, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, истигъфар кылабыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Нәфесләребезнең начарлыгыннан һәм гамәлләребезнең кабахәтлегеннән Аллаһыга сыгынабыз. Кемгә Аллаһы һидаять бирсә — аны адаштыручы булмас, кемне адаштырса — аңа беркем дә һидаять бирә алмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд — Аның колы һәм хак илчесе булуына гуаһлык бирәм.

«Шик юктыр ки, Аллаһы да, фәрештәләр дә Пәйгамбәргә күп салаватлар әйтә. Әй, иман китергән адәмнәр, сез дә аңа салават әйтегез һәм сәламнәрегезне күндерегез».

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә намаз укучыларның һәм ураза тотучыларның саны кадәрле салават ирештер.

Аллаһым, Мөхәммәдкә һәм Мөхәммәднең гаиләсенә утырган һәм басып торган кемсәләрнең саны кадәрле салават ирештер.

Аңа салават һәм сәлам ирештер, шулай ук бөтен пәйгамбәрләргә һәм илчеләргә (расүлләргә), якын булган фәрештәләреңә, шулай ук күкләрдә

һәм җирләрдә яшәүче Сиңа итагать әһелләренә салават һәм сәлам ирештер. Шулай ук, безгә карата рәхимле бул һәм безне алар белән бергә мәхшәр мәйданында җый. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, мәгъфирәтең белән мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, аларның исәннәрен дә, үлгәннәрен дә гафу ит. Чынбарлыкта, Син догаларны кабул итүче, бәрәкәт индерүче, дәрәҗәләрне күтәрүче, хаҗәтләребезне үтәүче. Синең рәхмәтең белән, йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

Аллаһым, тугры хәлифәләргә һәм хак белән казыйлык иткән вә гаделлек кыла торган булып үткән әмирләргә карата рәхимле бул.

Аллаһым, кем дингә ярдәм итә, шуңа ярдәм ит һәм кем динне кимсетә, шуңа һидаять бир.

Аллаһының коллары! Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә гаделлек, ихсан, якыннар белән йөрешүне әмер итә һәм фәхешлекне, кире кагылган нәрсәләрне, чиктән чыгуны тыя. Аллаһы сезне вәгазьли, шаять, сез искә алырсыз.

Бөек, Олуг, Тере, Уяу булган Аллаһыны зикер итегез – Ул сезне зикер итәр, Аңа карата шөкер итегез – Ул арттырыр. Аның каршында тәүбә-истигъфар кылыгыз – Ул мәгъфирәте белән гафу итәр. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләне зикер итү исә – иң бөек, иң гүзәл, иң олуг, иң җәляләтле, иң камил, иң зур гамәл.

*11 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Корбан гаете вәгазе

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим!

Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү!

Мөхтәрәм дин кардәшләребез, һәрбарчаларыбызга да Аллаһының сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте булса иде!

Бүген без сезнең белән зур бәйрәм – Гыйд әл-әдха – Корбан гаетен каршы алабыз. Аллаһы Тәгалә барлык яхшы гамәлләребезне кабул итеп, гыйбадәтләребез өчен савапларын арттырып, ике дөньяда да Үзенең чиксез мәрхәмәтен насыйп итсә иде! Гаетебез мөбарәк булсын, һәр йортка да шатлык, иминлек һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен алып килсен.

Әлеге изге көндә Россиянең уннарча миллион мөселманнары, дини хисләре тулган хәлдә, иртә таңнан мәчеткә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә булу һәм гаиләләребезгә, туганнарыбызга, дусларыбызга, мохтаҗларга дога кылу өчен җыелдылар.

Корбан бәйрәме – җир шарының барлык почмакларында зурлап билгеләп үтелә торган мөселман бәйрәме ул. Корбан – Аллаһы безгә насыйп иткән зур гыйбадәт, Раббыбыз биргән сансыз нигъмәтләр өчен рәхмәтебезне белдереп, буйсынуыбызны күрсәтү. Кәламе Шәрифтә:

فَصَلِّ لِرَبِّكَ وَانْحَرْ

**«Раббың ризалыгы өчен намаз укы һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!»** – дип әйтелгән.

«Кәүсәр», 108:2

Корбан чалуның асыл мәгънәсе корбан китерелгән хайванда, аның итендә түгел, ә күндәмлек күрсәтү, тәкъвалык һәм диндарлыкта яшерелгән. Коръәни Кәримдә:

لَن يَنَالَ اللَّهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَـٰكِن يَنَالُهُ التَّقْوَىٰ مِنكُمْ

**«Чалган корбаннарыгызның итләре вә каннары Аллаһыга ирешмәс, ләкин сездән Аллаһыга тәкъвалык вә изге гамәлләр ирешер»,** – дип әйтелгән.

«Хаҗ», 22:37

Корбан чалу – Аллаһы Тәгалә әмеренә буйсыну һәм гыйбадәт хакына бар милкеңне корбан итәргә әзер булуның, Раббыбызның әмерләренә буйсынуның чагылышы ул.

Корбан чалу мөмкинлеге булган кешеләргә аларның Аллаһы Тәгалә каршында да, мөселман өммәте каршында да билгеле бер бурычлары барлыгын искә төшереп тора. Кеше нindидер мөмкинлекләргә ия булса, аларны үз байлыгын арттыру өчен генә түгел, ә изге максатларда кулланырга тиеш. Аллаһы Тәгалә бай кешеләргә мохтаҗ һәм фәкыйрьләрне кайгыртырга, бар кешеләр белән яхшы мөнәсәбәттә булырга омтылып яшәргә боера.

Кәламе Шәрифтә болай дип әйтелә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۗ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ مَن كَانَ مُخْتَالًا فَخُورًا

**«Аллаһының Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изге-**

**лек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһы, әлбәттә, сөйми!»**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм юкка гына: «Күршесе ач булганда тук булган (кеше) бездән түгел», – димәгән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бу хәдисеннән, әгәр кемнең дә булса мөмкинлеге бар икән, аңа башкаларга ярдәм күрсәтү җаваплылыгы йөкләнелгәне аңлашыла.

Корбан чалу кешеләр арасындагы аермалыкларны бетерә, аларны берләштерә, кардәшлек-дуслык җепләре ныгуга китерә, чөнки бәйрәм көннәрендә мөселманнар якыннарына гына түгел, ә бар кешегә дә яхшы эшләре вә изге гамәлләре белән ярдәм итәргә омтыла, корбан итләрен тарата. Бу көнне һәр мөселман өендә кунакчыллык, шатлык, юмартлык хөкем сөрә. Табигый ки, мөселман кешесе Рамазан аенда һәм Корбан бәйрәме көннәрендә генә түгел, ә һәрвакытта да кунакчыл һәм юмарт булырга тиеш. Моңа дәлил булып, «Юмарт кеше Аллаһыга, Җәннәткә һәм адәм балаларына якын һәм Җәһәннәм утыннан ерак», дигән хәдис тора.

Шулай ук балаларыбызда башка көннәрдән аермалы буларак, бигрәк тә гает бәйрәмнәрендә шатлык, куаныч һәм бәхет хисләре тусын өчен, бу көннәрдә аларга бүләкләр бирү, аларны татлы ризыклар белән сыйлау киңәш ителә.

Гает вакытында юмарт һәм тирән акылга ия кеше күпләргә шатлык һәм куаныч китерә ала, ә иң мөһиме – Раббысының рәхмәтенә ирешеп, кайбер кешеләр гомере дәвамында да тоя алмаган җан тынычлыгына ирешергә мөмкин.

Бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләре китерелә: «Саран кешеләрдән иң начары – корбан чалуны башкарырга тиеш була торып та, бу эшне башкармаучылар».

Корбан бәйрәмендә Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе ике корбан чала торган булган: берсен – үзе, ә икенчесен бар мөселман өммәте өчен. Шуңа күрә, җитәрлек байлыклары булган мөселманнар тагы да күбрәк савап алырга теләсәләр, шулай ук ике яки аннан күбрәк корбан чала ала.

Шул рәвешле, корбан чалу мөэминнең үзенең рухи чистарынуын гына түгел, ә күпмедер вакытка булса да, мохтаҗларны ризык белән дә тәэмин итә.

**Корбан бәйрәменең тарихы**

Ә хәзер кыскача гына Корбан бәйрәменең барлыкка килү тарихына тукталып китик. Ул бөек пәйгамбәр, Аллаһының дусты Ибраһим галәйһиссәлам һәм аның улы Исмәгыйль галәйһиссәлам белән бәйле.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә зур сынау әзерли. Аңа үз улын корбан китерергә әмер бирелә. Ибраһим иң кадерле, көтеп алган һәм йөрәгенә якын булган кешесен корбан китерергә кирәклеген аңлый. Беләбез, Аллаһы Тәгалә Ибраһимга улын ул инде бик өлкән яшьтә булганда гына бирә.

Ибраһим галәйһиссәлам иң хөрмәтле пәйгамбәрләрнең берсе, аның исеме белән Коръән-Кәримнең ундүртенче сүрәсе аталган, аны шулай ук яһүдиләр һәм насаралар да таный. Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә аның югары дәрәҗәгә ия булуын безгә түбәндәге аятьтә белгертә:

وَمَن يَرْغَبُ عَن مِّلَّةِ إِبْرَاهِيمَ إِلَّا مَن سَفِهَ نَفْسَهُ ۚ وَلَقَدِ اصْطَفَيْنَاهُ فِي الدُّنْيَا ۖ وَإِنَّهُ فِي الْآخِرَةِ لَمِنَ الصَّالِحِينَ

**«Ибраһим галәйһиссәлам тоткан ислам диненнән һичкем баш тартмас, мәгәр үз-үзенә ахмаклык кылган җаһил кеше генә баш тартыр. Шиксез, Ибраһим галәйһиссәламне Үзебез дөньяда**

**имамга һәм пәйгамбәрлеккә сайладык, ә Ахирәттә ул изгеләр белән җәннәттә булыр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:130

Коръәни Кәримдә Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам белән күптөрле хикмәтле тарихлар һәм нәсыйхәтләр китерелә, әмма әлеге вәгазебездә без аларның берничәсенә генә тукталырбыз.

Олы яшькә җитеп тә Ибраһим галәйһиссәламнең балалары булмый. Шул чакта ул Аллаһыга дога кыла:

رَبِّ هَبْ لِي مِنَ الصَّالِحِينَ

**«Ий Раббым, миңа бер изге ир бала бирче, миңа ярдәмче булсын!»**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:100

Пәйгамбәрнең догасын кабул итеп, Аллаһы Тәгалә аны ир бала белән бүләкли, аны Исмәгыйль дип атыйлар.

Еллар уза һәм Исмәгыйль үзенең әтисенә терәк һәм таяныч булырлык яшькә җитә. Шул чакта Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне зур сынауга тарта.

Аңа Аллаһының әмере белән үз улын корбан итәргә боерыла. Бу хакта түбәндәге аятьтә хәбәр ителә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ مَاذَا تَرَىٰ ۚ قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«Ул бала җиде яшенә җитеп атасы илә йөри башлагач, Ибраһим әйтте: «Ий углым, мин төшемдә Аллаһы тарафыннан сине корбан итеп чалырга боерыламын, уйлап күр, бу эшкә ничек карыйсың? Углы Исмәгыйль әйтте: «Ий атам, ни белән бое-**

**рылган булсаң, шуны эшлә, мин Аллаһы хөкеменә ризамын, бу эштә мине, Аллаһы теләсә, сабыр итүчеләрдән табарсың».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:102

Шул рәвешле, Ибраһим иң кыйммәтле, күптән көтелгән һәм аңа иң якын булган улын корбан итәргә кирәклекне аңлый, чөнки Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә баласын аның хәләл җефете олы яшьтә булганда бүләк итә. Әмма барлык авырлыкларга да карамыйча, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә ышанып, Аның таләпләрен үтәргә алына.

Ибраһим галәйһиссәлам улы белән ерак юлга чыга. Берничә мәртәбә кеше рәвешенә кереп алар каршысына Иблис очрый. Кешелекнең дошманы аңа мөрәҗәгатьне үтәмәскә һәм Корбан китермәскә сорый. Аллаһының әмереннән баш тартырга котыртып йөргән шәйтанны күргәч, ул аңа ташлар ата. Шул вакыттан башлап, хаҗ кылган вакытта хаҗилар «Җәмарат» җирендә таш ыргыта.

Әмма барлык тереклеккә, мал-мөлкәткә Хуҗа булган дөньяларның Раббысы, беркемнең дә, бигрәк тә кешеләрнең корбанына мохтаҗ түгел. Аллаһының кушканын үтәгән Ибраһим галәйһиссәлам, улы Исмәгыйль өстенә пычак китергәннән соң өндәмә ишетә:

قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا ۚ إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«Төшеңдә күргән Безнең әмерне тәсдикъ кылдың, үтәгән хөкемендә булдың. Әнә шулай Үзебезгә итагать иткән яхшы мөэминнәрне изге җәзалар белән нигъмәтлибез!»**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:105

Шулай итеп, улының корбаны хайван белән алышына. Бу хакта «Саффат» сүрәсенең 107 нче аятендә болай әйтелә:

وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ

**«Без аны (Исмәгыйльне) бөек корбан (бәрән) белән түләп алдык».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:107

Аллаһы бу Корбанны бөек дип атый. Моңа берничә сәбәп бар. Беренчедән, Ул бөек пәйгамбәрнең бөек улына йолым иде. Икенчедән, Корбан чалу буынның бөек йолаларының берсенә әйләнә. Өченчедән, бу йола сакланып калды һәм Кыямәт көненә кадәр дәвам итәчәк.

Бу гамәлләрдән соң, Ибраһим галәйһиссәламнең игелекле рәвештә икенче улы – Исхак галәйһиссәлам туа. Ул да бөек пәйгамбәр була.

Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең ныклыкны һәм тугрылыкны тикшерергә кушкан барлык авыр сынауларны да намус белән башкарып чыкты. Аллаһы Тәгалә алдында бөек юашлык һәм Аллаһыга бөек тугрылык күрсәтеп, ул Аның чын дустына әйләнде.

Ибраһим галәйһиссәламнең тарихы безгә Аллаһы Тәгалә юлында үзебезнең милкебезне, вакытыбызны, көчебезне корбан итәргә өйрәтә. Бу динне ныклап тотучы кешегә зур үрнәк. Мин һәр мөселманга йоклар алдыннан «Мин бүген Аллаһы ризалыгы өчен нәрсә эшләдем?» дигән сорауны бирүен теләр идем.

Мөхтәрәм җәмәгать! Корбан һәм Ураза гаете намазларына бик күп дин кардәшләребез килә, гәрчә динебездә аларның хөкеме вәҗиб, ә көндәлек намазларыбызныкы – фарыз дәрәҗәсендә булып тора. Әбү Хәнифә хәзрәтләре әйткән: «Фарыз белән вәҗиб арасы, җир белән күк кебек». Башкача әйткәндә, көндәлек биш тапкыр укыла торган фарыз намазы Аллаһы каршында бәйрәм гает намазларыннан күпкә кадерлерәк. Шуңа күрә, җәмәгать, сезне Аллаһы йортына гыйбадәт кылырга һәр намазга чакырам, ә мөмкинлелегез булмаса, җомга көнне бәйрәм намазына килегез! Тормышыбыз кайнап тора, бик күп вакыйгаларның шаһиты булабыз, каядыр ашыгабыз, кабаланабыз. Шушы кыска гына гомер эчендә иң мөһим булган гыйбадәтне – намазны онытмыйк! Ул Кыямәт

көнне бездән беренчеләрдән булып соралачак! Хәдисләрнең берсендә Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләре китерелгән: «Чыннан да, Кыямәт көнендә беренче булып биш вакыт намаз соралачак. Ул тәртиптә булса, башка гамәлләрең дә тәртиптә булачак».

Корбан бәйрәменә кабат әйләнеп кайтканда, бу көнне кемгә корбан чалу вәҗиб (тиешле) булуын карап китик.

Корбан чалучы:

1. Мөселман,

2. Үз акылында,

3. Балигълык яшендә,

4. Ирекле булырга тиеш;

5. Сәфәрдә булмавы,

6. Нисаб күләмендә мал-мөлкәте булуы шарт. Нисабка ел дәвамында ия булмаска да мөмкин.

**Ничек һәм кайчан корбан чалырга була?**

Корбан фәкать Корбан бәйрәменең әүвәлге өч көнендә генә чалына. Иң яхшысы – беренче көнне. Бәйрәм намазлары үткәреләчәк шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларда корбан намаздан соң ук, ә бәйрәм намазы укылмаган авылларда таң җиткәннән соң чалына башлый. Ышанычлы хәдистә әйтелә: «Бүген безнең иң беренче эшебез – бәйрәм намазы уку, ә аннары – корбан чалу. Кем шулай эшли, сөннәтебезне үти. Әгәр дә кемдер корбанны намаздан иртәрәк чалса, аның ите гаиләсенә бирелгән гади иттән китәчәк».

Корбанны кич һәм төнлә чалу – мәкруһ, чөнки караңгы вакытта кеше хата җибәрә ала, әгәр бу җир яхшы яктыртылган булса, мәкруһ саналмый.

Өченче көннең ахшам намазыннан соң корбан чалу дөрес булмый.

Корбанлык хайванын, газап кылмыйча, сул ягына яткырырга һәм башын кыйблага борып куярга; үткен пычак кулланырга тиешле. Чаласы кеше «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр», – дип хайван чала һәм дога кыла.

Хайванның җаны тәненнән киткәнче, башын аеру һәм тиресен алу дөрес булмас. Чалган вакытта «Бисмилләһ» дип кенә әйтү җитми, «Бисмилләһ, Аллаһу Әкбәр», дип тутырып әйтү тиешле. Әгәр чалучы белә торып шулай әйтмәсә, әлеге ит тыелган булып санала. Әгәр онытып әйтмәгән булса, бу очракта Аллаһы гафу итәр.

Хәзер безнең янәшәдә бәйрәм намазында төрле шәһәр, илләр, хәтта төрле кыйтгалардан килгән мөселманнар катнаша. Тышкы аерымлыкларыбыз, тел, тән төсе төрле булса да, без бер-беребезне ихластан сәламлибез һәм бер Аллаһыга итагать итеп гыйбадәт кылабыз. Ислам безнең йөрәкләрне берләштерде һәм барлык мөселманнарны бер-берсенә карата дин кардәш итте.

Аллаһы Тәгалә бу көндә безгә рухи шатлык һәм Аның шәфкатьлелеген күрергә, чын күңелдән намаз укырга рөхсәт бирсә иде. Аллаһы Тәгаләдән безнең корбаннарыбызны кабул итүен, үсеп килүче яшь буынның гыйлемле, әхлаклы, намуслы, талантлы, Татарстан Республикабыз һәм Россиянең барлык халыкларына файда китерә торган булуын сорыйм.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешүне, бәхет һәм сәламәтлек, ә безнең илебезгә һәм Татарстан Республикасына тынычлык, иминлек һәм чәчәк атуны теләп дога кылам. Бәйрәм белән сезне, мөселман дин кардәшләрем.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин,*

*Татарстан Республикасы мөфтие*

*16 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Гошер садакасы

Галәмнәрне юктан бар итүче, безләргә Үзенең күп нигъмәтләрен биреп һәм безгә: «Әй, бәндәләрем, Миңа шөкер итегез – арттырып кайтарырмын», – дип мөрәҗәгать итүче Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә данмактауларыбыз булса иде. Һәм шушы сынаулар белән тулы; ялгышу бик җиңел булган дөньяга пәйгамбәр итеп җибәрелгән Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават һәм догаларыбыз булса иде.

Аллаһы Тәгалә бу дөньяга безне гыйбадәт кылыр өчен халык кылды. Раббыбыз иман китергән бәндәләре Аңа якынаю юлларын эзләп, тагын да якынайсын өчен, бөтенесен безгә җиңеллек белән кылган: кечкенә генә бер гамәл өчен дә Ул безгә күп итеп әҗерләрен бирә. Әйтик, Рамазан аенда ихластан ышанган һәм: «Аллаһы Тәгалә гафу итәр», – дип уйлаган ураза тотучының ничәшәр дистә еллар кылынган гөнаһларын да гафу итә Аллаһы Тәгалә. Безгә исә фәкать тырышлык куеп, гыйбадәтләребезне һәрдаим кылу тиешле. Ә гыйбадәтләр арасында күңелгә шатлык, бу дөньяда бәрәкәт һәм кешеләргә сөенеч китерә торган бер гыйбадәт бар: ул да булса – садака, ягъни үз малыңның бер өлешен мескеннәргә, фәкыйрьләргә, ятимнәргә бирү. Мохтаҗ кешеләргә ярдәм иткәч, алардан килә торган рәхмәтлекне һәрберебезнең күргәне яки, һичьюгы, ишеткәне бардыр һәм моны аңлатып кына бетереп булмый. Әле ул яшерен рәвештә бирелсә, гомумән, күңелләр яктыра, чөнки садака алган кешеләр синең өчен ихлас күңелдән дога кыла. Ә андый кешеләрнең догалары кабул була. Шуңа шушы төр гыйбадәтләрне Аллаһы Тәгалә яшерен, ихластан эшләргә

куша һәм савапның иксез-чиксез икәнен искәртә. Аллаһы Тәгалә Үзенең мөбарәк китабында безгә болай дип хәбәр итә:

الَّذِينَ يُنفِقُونَ أَمْوَالَهُم بِاللَّيْلِ وَالنَّهَارِ سِرًّا وَعَلَانِيَةً فَلَهُمْ أَجْرُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ

**«Аллаһы юлында көндезләрен вә төннәрен ачыктан-ачык һәм яшерен малларын корбан итүчеләргә олы әҗерләр әзерләнгән. Һәм алар Ахирәттә курку һәм моңсулану һич белмәсләр».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:274

Ягъни үз кулы белән эшләп алган малны Аллаһы Тәгалә кушкан җирләргә бирүчеләрне Аллаһы Раббыбыз Үзе зурлый.

Әбү Давыд хәдисләр җыентыгында түбәндәге хәдис бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Әгәр бер мөселман киемсез калган бер мөселманны киендерсә, Аллаһы Тәгалә аны җәннәт киеменнән киендерер. Әгәр ач калган кардәшен ашатса, аны да Аллаһы Тәгалә җәннәт ризыкларыннан ашатыр. Сусаган кардәшенә су биреп эчерсә, Аллаһы Тәгалә аны да җәннәт суы белән эчерер».

Шушы ризыкка бәйле садакалар арасында барыбызга да билгеле булган гошер садакасы бар. Бу төр садака иң хәерле һәм бәрәкәтле садакалар төреннән санала. Ә бу садаканы ничек итеп бирергә соң? Кем нинди күләмдә бирергә тиеш, һәм кемнәргә бирелергә тиеш?

Бу садака акчалата бирелми. Ул яшелчә, җиләк-җимеш белән бирелә. Әгәр алар яңгыр суы белән үстерелгән булсалар, 10 нан бер өлеш бирелә, ә инде кеше үзе су сибеп үстергән очракта, 20 дән бер өлеш бирелә. Кайбер кешеләрдә түбәндәге ялгыш фикер дә йөри: имеш, бәрәңгедән 10 нан 1 өлеш, ә бүтән яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән 20 дән бер өлеш кенә бирелә . Әмма бу фикер – ялгыш. Яңгыр суы белән үскән барлык үсемлек:

җиләк-җимеш, яшелчә һ.б. ризыклардан садака итеп 10 нан 1 өлеш бирергә кирәк.

Әмма бер күңелсез хәл дә бар: бүгенге көндә күп кешеләр шушы гыйбадәттән (изге гамәлдән) баш тарталар. Үзләренә дәлил итеп: «Мин үзем тир түгеп үстергән малымны кемгәдер илтеп биреммени? Бөтен кешегә өләшсәм, миңа нәрсә калыр? Миңа берәүнең дә китереп биргәне юк бит әле», – дигән фикерләр китерәләр. Әлбәттә, бу халыкның гыйлемсезлеге аркасында һәм Аллаһы Тәгаләгә тиешле рәвештә тәвәккәл кылмаганлыктан килеп чыга. Без бит бакчага әйбер утыртканда уңышның бик күп булуын телибез. Ә үзебез шөкер итү йөзеннән әз генә булса да малны корбан итмибез, ягъни өлеш чыгармыйбыз. Әгәр дә шулай уйлыйм икән, җәмәгать, мин нинди күңел белән шул уңышны өмет итәргә тиеш инде. Шунлыктан, сүзләрне әйткәндә, нинди дә булса карар кылганда, уйлап эш итәргә кирәк.

Садакаларны кемнәргә бирергә кирәк соң? Гадәттә, безнең җирлектә бу хәерне мохтаҗ кешеләргә, мәдрәсәләргә, мәчетләргә тапшыралар. Чыннан да, бу садаканы фәкыйрь, мескен, ятим кешеләргә, гыйлем алу юлындагы шәкертләргә, ялгыз яшәүче әби-бабайларга бирергә мөмкин. Бу акчалата бирелгән садакадан да шул ягы белән аерылып тора: авыр хәлдәге гаиләләргә акчалата садака биргәндә, алар аны дөрес юлларга кулланмаска да мөмкиннәр. Ә ризык белән биргәндә, мондый проблема булмаячак. Мин үзем, шәхсән, дөньяви уку йортларында укучы һәм тулай торакларда яшәүче мөселман егет-кызларга тапшыргалыйм. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Садака малны киметми», – дип әйткән, шулай булгач, кадерле җәмәгать, садакаларыбызны тапшырыйк. Бер капчык уңышыбызны садака итеп тапшырудан беркем дә ач яки ярлы булып калмаячак, Аллаһыга шөкер, без бүгенге көндә туклык заманында яшибез. Әгәр җиләк-җимештән үзебез өчен төрле кайнатмалар ясыйбыз икән, аннан да гошерне бирү тиешле була.

Ислам динендәге һәр бәйрәм, һәр садака, һәр гыйбадәт кешеләр арасын якыйнайтыр, сөендерер өчен боерылган. Әй, кардәшләрем, бер өммәт булып, бер-беребезгә ярдәм итешеп яшик. Кардәшенә ярдәм иткән кешегә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәм итә. Шуңа күрә, әгәр дә без мохтаҗларга ярдәм итсәк, Аллаһы Тәгалә дә безгә ярдәм итәр. Аллаһы Тәгалә һәрбарчаларыбызга ике дөньяның да бәхетен насыйп кылсын.

*Алмаз хәзрәт Галимҗанов,*
*Саба районы имам-мөхтәсибенең яшьләр*
*белән эшләү буенча ярдәмчесе,*
*Сатыш авылы имам-хатыйбы*

*23 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 22 нче көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Дини һәм дөньяви гыйлем алуның әһәмияте

Барча галәмнәрне бар кылып, аларны тәрбия кылып торучы, безне нигъмәтләндереп торучы, мөэмин-мөселманнар өчен каберне җәннәтнең бер бакчасы итеп кылучы, имансыз бәндәләр өчен каберне җәһәннәмнең бер утлы чокыры итеп кылучы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед вә сәналәребез булса иде! Аның хак хәбибе, кешелеккә туры юлны өйрәтеп калдырган, мөселманнарны җәннәт белән сөендергән вә имансызларны җәһәннәм белән кисәткән, дөньяда яшәгән иң яхшы мөселман, иң яхшы хәләл җефет, иң яхшы әти, иң яхшы дус, иң күркәм үрнәк әһеле булган пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламгә күңелебезнең иң түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде! Аллаһы Тәгалә үзебезгә дә күңел тынычлыгы, нык сәламәтлек насыйп итсә иде!

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Гыйлем бирүче галим бул, йә гыйлем өйрәнүче бул, йә аларның сүзенә колак салучы бул, гыйлемгә һәм гыйлем әһеленә мәхәббәтле бул, тик бишенчесе булма – һәлак булырсың», – дип әйткән.

Мөхтәрәм җәмәгать! Гыйлем сүзе Коръәндә 70 тән артык урында кабатланып килә. Аллаһы Тәгалә изге Коръәндә болай дип әйтә:

يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ ﴿١١﴾

**«Аллаһы Тәгалә сезнең арадан иманлыларның һәм гыйлем ияләренең дәрәҗәсен арттырыр. Аллаһы бөтен кылган гамәлләрегезне белеп тора».**

«Мүҗадәлә / Бәхәсләшү», 58:11

Дөрестән дә, гыйлем бүгенге көндә зур байлык булып тора. Һәм, Аллаһыга шөкер, аны алу юллары да җиңеләйде. Үзебезнең җирлегебездә генә дә мәктәпләр, мәдрәсәләр, техникумнар, университетлар бар, алар үз көчләренә эшләп киләләр. Нинди генә өлкә буенча укырга теләсәң дә, еракка китәргә кирәк түгел.

Шулай да, гыйлем алу системасын бик дөрес аңламаган кешеләрне дә очратырга мөмкин. Балаларын мәдрәсәгә генә биргән әти-әниләр аз түгел. Аларга җөмһүриятебездәге дөньяви уку йортларына укырга керү – ул ниндидер бер хата буып тора. Чыннан да, мәдрәсәләрне тәмамлаган кайбер шәкертләр белән күрешеп сөйләшергә туры килде. Араларында башка беркая да укырга кермәячәген әйткәннәре булды. Ягъни дөньяви гыйлемнең Ахирәт өчен файдасы юк имеш.

Аллаһы Тәгалә безне бик катлаулы кануннарга корылган Җир шарына урнаштырды. Бу дөньяда барлык нәрсәләр дә нинди дә булса законнарга, системаларга корылган. Һәм шуңа күрә, «Мин бары тик мәдрәсәдә генә укыячакмын», – диючеләр дә, «Баламны мәдрәсәгә кертеп тормыйм, искелектән ерак булсын», – диючеләр дә ялгышалар. Әйткәнебезчә, Аллаһы Тәгалә безне законнар дөньясына урнаштырды, аларны өйрәнмичә яшәү хата санала.

Аллаһыга шөкер, күрә, ишетә алабыз. Ә ничек итеп кеше күрә? Ничек итеп ул ишетә? Беркөнне ул күрү сәләтен югалтса, нәрсә эшләргә?

Әгәр дә кеше мәдрәсәдә генә утырса, ул боларны беркайчан да белмәячәк. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сәхабәләргә кошларның һавада ни рәвешле очканнарына кадәр аңлаткан. Мәдрәсәдә генә утырсаң, самолет төзеп булмаячак. Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә үткен фәһемлек бирсә иде. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ ﴿٩﴾

**«Әйт син аларга: «Белгән белән белмәгән бер булырмы?»**

«Зөмәра / Халык Төркеме», 39:9

Коръән дә безне гыйлемгә чакыра. Безнең бу дөньябыздагы бәрәкәтебез дә дөньяви гыйлем белән берлектә дини гыйлемне алу, һәм, киресенчә, (кемнәрдер өчен) дини гыйлем алган вакытта дөньяви гыйлемне дә үзләштерү. Югарыда, балаларын мәдрәсәгә бирергә курыккан ата-аналар бар, дип әйттек. Беренчедән, бу фикердән кире кайтырга кирәк. Икенчедән, андый ата-ананың үзләренә дә дини уку йортында гыйлем алырга кирәк. (Кичке курслар, мәчет каршындагы мәдрәсәләр һ.б.)

Ни өчен дини гыйлем дә кирәк соң? Аллаһы Тәгалә кешеләрне дә, җеннәрне дә гыйбадәт кылсыннар өчен яратканын барыбыз да беләә. Ә гыйбадәт – ул нинди дә булса гамәлләрне күз алдында тота. Намаз укыйбыз икән – андагы укыла торган сүрәләрне, догаларны белергә тиешбез. Намазга соңга калып килгәнбез икән, ничек кушылырга икәнен белергә тиешбез. Эшмәкәр булса, аңа акчасыннан зәкят бирү мәсьәләсе килеп басачак. Зәкятне кайчан, нинди күләмнән күпме бирәсе; яңгыр ярдәмендә үстерелгән яшелчәдән күпме гошер чыгарасы – боларның барысына да Коръәннән һәм сөннәттән җавап табарга туры киләчәк. Димәк, дини гыйлемне дә алырга кирәк.

Шуңа күрә, нинди генә гамәлгә тотынсак та, иң беренче очракта ул эш буенча үзебезнең гыйлем запасына карарга тиешлебез.

Хөрмәтле мөселманнар, игътибар итегез! Аллаһы Раббыбыз Коръәннең иң беренче аяте белән безне белем алырга чакыра. Аллаһы Тәгалә:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾

**«Сине барлыкка китергән Раббың исеме белән укы!»** – дип боера.

«Галәкъ», 96:1

Шуңа да, безгә гомумән, гыйлемнең бөтен кешелек өчен әһәмиятлелеге турында искәртеп узарга кирәк. Кешелек тормышын чорнап алган нинди генә өлкәне алмыйк – барысына да белем кирәк: трактор-машина йөртү өчен дә белем кирәк, тегү-чигү өчен дә белем кирәк, табиб булыр өчен дә гыйлем кирәк, шулай ук укытучы булыр өчен дә гыйлем кирәк. Юкка гына Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәрим китабында: «Мин һәрбер әйберне гыйлем белән әйләндереп алдым», – дип әйтмәгәндер. Ислам динендә гыйлем алу һәр мөселманга фарыз итеп куелган. Гомумән, динебез белем-мәгърифәткә бик зур игътибар бирә.

Без дини һәм фәнни гыйлем дип тә әйтергә яратабыз. Фәнни гыйлемгә «дөньяви» дигән ярлык тагылса да, исламда дин һәм фән – игезәкләр кебек, бер-берсенә бәйле. Әмма без аны бик сизмәскә дә мөмкин. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә баланың ана карынында барлыкка килүен, аның этапларын, таулар системасын, болытларның һәм күк җисемнәренең хәрәкәтен, диңгез-океан серләрен ачып бирә. Санап киткән әйберләр генә дә – барысы да төрле өлкәләргә карый. Коръәндә җиһан турында (космос) бик күп җирләрдә язылган. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә:

وَالسَّمَاءَ بَنَيْنَاهَا بِأَيْدٍ وَإِنَّا لَمُوسِعُونَ ﴿٤٧﴾

**«Күкне Без зур бер куәт белән кордык һәм Без аны җәелдереп торабыз»,** – дип әйтә.

«Зарият / Таратучы», 51:47

Һәм бу күренешләрнең барысын да дәүләт университетларында эшләүче профессорлар өйрәнә. Әмма шушы күренешләрне Аллаһы Тәгалә халыкка бик күптән җиткергән инде. Әгәр Аллаһы Тәгалә мөселманнарга дини гыйлемнән тыш, ошбу дөньяга караган гыйлем дә биргән икән, димәк, без аны кабул итәргә, өйрәнергә тиешбез.

Үзенең «Мөстәфадел-әхбар...» китабында Ш. Мәрҗани Болгар иле һәм анда исламның керүе турында аерым фасыл багышлый: «Шәһре Болгар – җир йөзенең өч яки дүрт кисәгеннән берсе булган Европа өлешендәге Румия һәм Константиядән кала, иң элек мәдәнияте үскән Әндәлес мәмләкәтеннән соң шул ук гасырда беренче булып Ислам диненә кергән шәһәр», – дип яза ул.

Ш. Мәрҗани биредә, дин кабул ителүнең сәүдә һәм башка алшартлары булуын, дин белән бергә гыйлем, язу, һөнәр-сәнагать, мәдәният, дәвалау ысуллары кебек дөньяви нәрсәләрнең үтеп керүен һәм аларның болгарларга һичшиксез көчле йогынты ясаулары шикелле бик мөһим бер күренешкә игътибар итә һәм аны болгарларга Ислам дине керүнең гаять зур уңай тәэсире итеп күрсәтә. Болгарлар арасында укый-яза белү шактый киң таралган була, чөнки мәчет булган һәр җирдә мәдрәсә эшләп килә һәм аларда өйрәнү эше алып барыла. Шәрык медицинасының дәвалау ысуллары белән танышканнан соң, борынгы табибларыбыз, җирле шартларга яраклаштырып, әллә никадәр дәвалау ысуллары уйлап чыгаралар. Шуңа өстәп, Ислам дине белән пакьлек, тән саулыгы, камил әхлак, шәхси гигиена кагыйдәләре керүне исәпкә алсак, болгар бабаларыбызның ничек яшәвен күз алдына китерү кыен түгел.

Югарыда әйтелгәннәрдә чыгып, шуны әйтеп була: гыйлем – кешене ике дөнья бәхетенә ирештерә, бу дөньяда карьера буенча югарыга күтәрә, Кыяматтә җәннәт дәрәҗәләрендә күтәрә. Мөмкинлеге булган кеше укудан курыкмаска, вакытым юк дип әйтмәскә тиеш.

Аллаһы Тәгалә тәүфыйк, һидаять биреп, безләрдән разый булып, югары дәрәҗәләргә күтәрсә иде. Барчаларыбызга да файда китерә торган гыйлемнәргә ия булырга, шуларны кулланып яшәргә насыйп булсын. Әәмин!

*«Хозур» редакциясе*

*30 август вәгазе,*

*Зөлхиҗҗә аеның 29 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1440 ел*

# Яңа ел – нәтиҗәләр ясау вакыты

Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, 31август көнне без яңа 1441 һиҗри елга аяк басачакбыз. Ул без, мөселманнар өчен аерым мәгънәгә, игътибарга лаек мөхәррам ае белән башланып китә. Мөхәррам аеның 10 нчы көне – «Гашурә» дип атала. Үз вакытында Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе нәкъ менә мөхәррам аен һиҗри календарьның беренче ае итеп билгеләде. Мөселманнар яңа елны бәйрәм кебек билгеләп үтмәсәләр дә (Пәйгамбәребез ике бәйрәм – Ураза һәм Корбан гаете белән килде), аны яңа фазага аяк басу кебек кабул итәләр. Яңа елда бер елга үтәләсе яңа планнар корыла, яңа өметләр баглана һ.б.

Мөхәррам ае зөлхиҗҗә аеннан соң килгәнгә күрә дә, Гомәр Әл-Хаттаб бу айны беренче ай итеп куйгандыр. Моның да үз сәбәбе бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кем дә кем начар сүзләр сөйләшмичә, бозыклыклар кылмыйча бу Йортка (Кәгъбәгә) хаҗ кылса, ул өенә анадан туган сабый кебек (пакь, гөнаһларсыз) кайтыр»[1], – дип әйтә. Хаҗ кылганнан соң кеше үзенең гөнаһларының авырлыгыннан котылып кайтыр, шуңа күрә аны сабый бала белән чагыштырып булыр иде. Һәм әле генә хаҗ кылып, гөнаһларыннан арынып кайткан кеше, яңа елга чиста килеш аяк баса. Бу халәт кешегә алдагы елга оптимизм һәм уңай караш белән карарга мөмкинлек бирә, шулай ук элеккеге хаталарга һәм гөнаһларга әйләнеп кайтмыйча, елны тулысы белән шушы рухи чисталыкта үткәрергә этәргеч була.

Әмма мөхәррам аеның беренче ай булуы гына аны шундый зур дәрәҗәләргә күтәрми. Беренчедән, бу айда олы кичә – «Гашурә» көне бар;

[1] Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: 1819.

икенчедән, бу айның һәр көнендә ураза тоту бик фазыйләтле булуы белән аерылып тора. Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеннан соң иң фазыйләтле ураза – Аллаһы аенда, мөхәррамда», – дип әйткән[1]. Тагын бер хәдисендә: «Айларның саны унике, шул айларның дүртесе харам айлар булып санала, (аларның) өчесе чиратлашып киләләр: зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам, ә дүртенче ай – раҗәб – җөмәдәл ахыр һәм шәгъбан арасында», – дип әйтелә[2].

Шулай ук моның турында Аллаһы Тәгалә дә Үзенең китабы Коръәни Кәримдә болай дип әйтеп уза:

إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ يَوْمَ خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ مِنْهَا أَرْبَعَةٌ حُرُمٌ ۚ ذَٰلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ ۚ فَلَا تَظْلِمُوا فِيهِنَّ أَنفُسَكُمْ ۚ وَقَاتِلُوا الْمُشْرِكِينَ كَافَّةً كَمَا يُقَاتِلُونَكُمْ كَافَّةً ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ مَعَ الْمُتَّقِينَ ﴿٣٦﴾

**«Аллаһы хозурындагы китапта айлар саны унике, җирне һәм күкләрне яраткан көннән бирле, ул унике айдан дүртесе сугышлар харам булган айлар: ягъни раҗәб, зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам айлары. Ошбу хөкемнәр – туры дин, ул дүрт айда үзегезгә золым кылмагыз.., бер-берегезгә ярдәмдә булыгыз, ташламагыз! ... Вә белегез, Аллаһы тәкъвалар белән бергә».**

«Тәүбә», 9:36

Кешеләр бу айда бер-берсен сүз белән дә, гамәле белән дә рәнҗетмәскә тиеш. Әйе, мөселманнар, гомумән алганда да, бер-берсен теле белән дә, гамәле белән дә, хәтта ки уй-фикерләре белән дә рәнҗетмәскә тиешләр. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Мөэмин-мөселманның бер сыйфаты – башка кешеләрнең мөэминнең теленнән дә, кулыннан да имин булула-

1 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: 1163.

2 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан.

ры», – дип әйтте. Рәнҗетү бик зур гөнаһ санала. Киресенчә, Аллаһыдан сабырлык сорыйк. Мөхәррам аеның һәрбер көне фазыйләтле, шуңа күрә мөселман кешегә мөхәррам ае буе, яки калган айларга караганда бу айда күбрәк көннәр ураза тоту рөхсәт ителә. Гашурә көне бу көннәр арасында аерым урынны биләп, Аллаһы Тәгаләдән зур саваплар бирелә торган көн буларак аерылып торса да, ул әле Ислам дөньясындагы кайбер тарихи вакыйгалар белән дә бәйле.

Яңа елда яңа үрләргә менү вакыты башланып китә. Дөнья буенча таралган бер гыйбарә бар: «Дүшәмбедән тотынам». Дүшәмбе – ул атна башы булганга күрә, бездә ниндидер яңа эшне дә аннан башлау дөрестер дигән фикер яши. Яңа ел белән дә шулай ук. Без яңа елдан соң эшләячәк планнарыбызны иске елда ук корып куярга яратабыз. Гадәттә, берәр кешегә бурычы булган кеше, яңа елга бурычлы килеш чыкмыйм дип, әҗәтләрен кайтара. Икенчеләре яңа елга яңа җиһазлар белән керик дип, яңаларын алып куя. Һәм 31 нче декабрьдән соң килгән 1 нче гыйнвар калган көннәрдән артык берни белән аерылмаса да, без инде аны яңа циклга аяк баскан кебек кабул итәбез. Планлаштырган эшләрне тормышка ашыра башлыйбыз.

Тиздән без 1441 елга аяк басабыз. Ә яңа елда һәрчак яңа үрләр көтә. Галимнәребез, гадәттә, үзләренең барлык кылган гамәлләрен дәфтәр яки блокнотка язып бара торган булганнар. Берәр ай тәмамлану белән, икенче айга керер алдыннан, үзләренең нинди изге гамәл, нинди начар гамәл кылганнарын карап, анализлап чыга торган булганнар. Аннан соң икенче айда начар гамәлләрен төзәтү, изге гамәлләрен арттыру өстендә эшли башлаганнар. Инде иртәгәдән яңа һиҗри ел башлана. Кадерле җәмәгать, без дә үзебезнең гамәлләребезне барлап, гөнаһлы гамәлләребез өчен тәүбә кылып, изге гамәлләр кылырга план төзеп, яңа елны каршы алырга тиешбез. Нинди изге гамәлләргә план корып була соң? Мәсәлән:

– ел дәвамында Коръән Кәримнең «Бәкара» сүрәсен ятлау;

– көн саен Коръәннән бер аять укый башлау;

– хаҗ кылырга дип акрынлап акча җыя башлау;

– биш вакыт намаз укый башлау һ.б.

Мөселманнарда яңа ел нинди чара белән бәйле соң? Гарәпләрдә бу айлар күптәннән билгеле булалар. Югарыдагы Коръән аяте шуны дәлилли. Әмма Пәйгамбәребез вафатыннан соң берничә вакыт үткәч, дөресрәге Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе хәлифә булган вакытта, айларны ел белән бергә язарга кирәк дигән фикер туа. Бу мәсьәлә дәүләтнең төрле төбәкләреннән килгән хатлар аркасында ачыла. Ул хатларда ай исеме язылган була, әмма елы билгеләнми. Шул сәбәпле, мөселманнарның әмире олы сәхабәләрдән торган шура җыеп, бу мәсьәләне күтәрә. Кемнәрдер мөселманнарның елына башлангыч итеп Пәйгамбәребез туган датаны алырга тәкъдим иттеләр, кемнәрдер Пәйгамбәребез галәйһиссәламгә пәйгамбәрлек иңгән елны алырга куштылар. Әмма беренчесендә Ислам турында беркем дә белми иде, ә икенчесендә исә Ислам дине бик көчсез вакыт иде. Әлбәттә, ел исәбен Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең вафатыннан башларга да тәкъдим ителде, әмма Ислам календарен кайгылы елдан башлыйсылары килмәде.

Әмма ахыр чиктә ел башы итеп һиҗрәт вакыйгасы алына, ягъни милади ел белән караганда бу 622 елны була. Пәйгамбәребез Мәккәдәге эзәрлекләүләр ешайгач, Мәдинә (ул вакытта әле ул Ясриб була) шәһәренә күченергә карар кыла. Мөхәммәд галәйһиссәлам шулвакыттагы мөселманнар белән Мәдинәгә күченгәч, Ислам дине куәтләнә, бер шәһәрдә бик күп мөселманнар бергә яши башлый. Ул вакытта Мәдинә халкы Мәккәдән килгән мөһаҗирләрне иң күркәм каршылау белән каршы алалар, аларга үзләренең йортларын, малларын бүләк итәләр. Һәм бу шәһәрдә мөселманнар үзләренә иминлек табалар. Һиҗрәтне шуңа да Ислам диненең чәчәк аткан, ныгыган чагы да дип йөртәләр. Ул мөселманнар дөньясында гына түгел, бөтен кешелек дөньясында да мөһим борылыш

чоры дип карала. Шул вакыттан Ислам дөньясы мәдәнияте, гыйлеме, фәне югарыга таба күтәрелә башлый. Ислам дине галимнәре уйлап чыгарган бик күп җиһазлар, медицина, оптика приборлары; алар нигез салган төгәл фәннәр – математика, мәсәлән – бөтен дөньяга тарала, өйрәнелә.

Ни өчен бүгенге мөселманнар григориан календаре белән генә файдаланмыйлар дигән сорау туарга мөмкин. Югарыда әйтеп узганыбызча, бу айлар гарәпләрдә бик күптәннән билгеле була. Шулай ук вакытны айга карап билгеләү бар кеше өчен дә җиңел булган. Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

هُوَ الَّذِي جَعَلَ الشَّمْسَ ضِيَاءً وَالْقَمَرَ نُورًا وَقَدَّرَهُ مَنَازِلَ لِتَعْلَمُوا عَدَدَ السِّنِينَ وَالْحِسَابَ ۚ مَا خَلَقَ اللَّهُ ذَٰلِكَ إِلَّا بِالْحَقِّ ۚ يُفَصِّلُ الْآيَاتِ لِقَوْمٍ يَعْلَمُونَ ﴿٥﴾

**«Көндез кояшны, кич айны нурлы-якты кылучы Зат та Аллаһы Тәгаләдер, елларны вә башка хисапларны белер өчен ул айга урыннар билгеләде».**

«Юныс», 10:5

Ягъни Аллаһы Тәгалә Үзе үк күк җисемнәре ярдәмендә вакытны билгеләргә куша. Без, мөселманнар, бер ай дип күктәге айның циклын әйтәбез. Һәм бу дөреслеккә күбрәк тә туры килә. Шуңа да карамастан, миллади буенча да 30 яки 31 көнне дә бер ай дип әйтергә күнеккән инде без. Ни өчен бүген дә кулланабыз соң? Ислам динендә бик күп әһәмиятле вакыйгалар булган. Һәм аларның барысы да тарихка Һиҗри айлардагы даталар белән кереп калган (Рамазан, Бәраәт, Гарәфә, Гашурә һәм башкалар).

Калган халыкларда Гашурә көнендә ураза тоту рәвеше ничек була соң?

Гайшә радыяллаһу ганһәдән: «Җәһилият чорында корәешлеләр Гашурә көнендә ураза тоттылар, Пәйгамбәребез бу көндә Рамазан ае ура-

засы мәҗбүр булганчыга кадәр ураза тотарга кушты. (Рамазан уразасы мәҗбүр булгач), Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Кем тели шул тотсын, ә кем тели калдырсын», – дип әйтте», – дигән хәдис тапшырыла[1].

Яһүдиләр дә бу көнне зур бәйрәмгә санаганнар. Әбү Муса Әл-Әшгарыйдан тапшырыла: Хәйбәр кешеләре (яһүдиләр) Гашурә көнендә ураза тоттылар, ул көнне бәйрәмгә санап, хатын-кызларын кыйммәтле киемнәргә киендерделәр, бизәндерделәр. Шуннан соң Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам (мөселманнарга): «Сез дә бу көнне ураза тотыгыз», – дип әйтте.

Аллаһының Илчесе бу көнне ураза өчен аерым билгели торган булган. Гашурәдән кала Пәйгамбәребез галәйһиссәлам тарафыннан төгәл датасына кадәр билгеләнә торган бүтән бер көн дә булмаган. Бу көн турында Ибне Габбастан сорагач, ул: «Пәйгамбәребезнең бер көннең икенчесенә караганда бөегрәк булганы аркасында, шулай ук бер айның икенче айга караганда бөегрәк булганлыгы аркасында ураза тотканын хәтерләмим. Бары тик бер ай һәм бер көннең бөеклеге аркасында ураза тота иде, ул – мөхәррам. Әмма Рамазан моңа карамый»[2], – дип җавап биргән.

Әгәр дә кеше бу уразаны хак курку белән куркып, ярлыкауга өмет белән башкарып чыга алса, аның узган ел өчен булган гөнаһлары ярлыканачак. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән Гашурә уразасы турында сорагач, ул: «Ул узган елгы гөнаһларның кичерелүенә сәбәп була», – дип әйткән. Шуңа күрә шушы яңа елларны матур гына каршы алып, күркәм планнар корып, тагын бер елны Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга тырышып яшәргә насыйп әйләсен. Әмин!

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

1 Имам Бохари хәдисләр җыентыгыннан: 1893.

2 Имам Мөслим хәдисләр җыентыгыннан: 2718.

*6 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 7 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Гашурә көне

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм хак илчесе, галәмнәргә рәхмәт булараk җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Мөхәррам ае – һиҗри тәкъвим (календарь) буенча беренче ай булып килә. Харам булган, сугыш кылу тыелган дүрт айның берсе булып санала (зөлкагъдә, зөлхиҗҗә, мөхәррам һәм раҗәб айлары). Бу айның фазыйләтен күрсәтеп, Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә үзенең сөннәтендә искә алды. Шул сәбәпле, һәрбер мәселман бу айны лаеклы итеп үткәрергә тырышырга тиешле. Аллаһы Тәгаләне олылап, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне искә алып, салаватлар әйтеп үткәрсә, ин шә Аллаһ, зур әҗерләргә ирешер.

Бу айны кеше ничек итеп үткәрсә, аның калган бөтен айлары да шул рәвешле үтәр. Имам Газали хәзрәтләре үзенең «Ихья големед-дин» («Иман турында фәннең яңадан торгызылуы») китабында болай дип искә алып үтә: «Әгәр берәү мөхәррам аен гыйбадәттә үткәрсә, һичшиксез аның хәер-бәрәкәте елның калган айларына да җитәр».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аеннан соң ураза тотар өчен иң күркәм ай – ул мөхәррәм ае», – дип әйтә.

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәү мөхәррам аеның бер көнен уразада үткәрсә, Аллаһы Тәгалә аңа утыз көн тоткан ураза әҗерен бирер», – дип хәбәр итә. Бу айның дәрәҗәсен күрсәткән башка бик күп хәдисләр һәм риваятьләр дә бар.

Бу ай ни өчен шул дәрәҗәгә күтәрелде соң? Ни өчен бу айга шундый игътибар бирергә кирәк? Моның төп сәбәбе булып бу айда булган кайбер мөһим вакыйгалар тора. Шуларның берсе – Гашурә көне. Мөхәррам аеның унынчы көнен «Гашурә көне» дип атап йөртәләр («ун» сүзе гәрәпчә – «гашәра»).

Алдан әйтелгәнчә, мөхәррам ае айларның иң өлкәне, ә аның 10 нчы көне –иң кыйммәтлесе булып санала.

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә һиҗрәт кылганнан соң, анда яшәүче яһүдиләрнең Гашурә көнендә ураза тотуларын күрә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сез бу көндә ни өчен ураза тотасыз?» – дип сорагач, алар бу көн – Муса галәйһиссәлам Фиргавен гаскәреннән котылган көн икәнен, шул вакыйганы олылап тотуларын әйтәләр.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Нәхнү әхакку биһә – без ул көнне ураза тотарга хаклырак», – дип, ураза тота башлый. Ләкин яһүдиләрдән аермалы буларак, ул бу көннән алда тагын бер көн һәм соңыннан бер көн өсти (димәк, 9, 10, 11 нче көннәр).

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Берәү Гашурә көнен олылап ураза тотса, Аллаһы Тәгалә аның үткән елгы гөнаһларын кичерер», – дип хәбәр итә. Башка риваятьтә: «Әгәр кеше Гашурә көнендә бер кечкенә орлык кадәр генә булса да садака бирсә, Аллаһы Тәгалә аңа Өхед тавы кадәр әҗер бирер», – дип әйтелә. Шул рәвешле, мөселманнар бу көндә төрле изгелекләр кылалар, берберсен сөендерәләр, Аллаһы Тәгалә дә шул рәвешле аларны сөендерә.

Ни өчен соң бу көн мөселманнарның игътибарына лаек? Риваятьләрдә әйтелгәнчә, бу көнне Аллаһы Тәгалә җир һәм күкләрне яратты, беренче кеше – Адәм галәйһиссәлам яратылды. Бу – аның җәннәткә кертелгән, аннан чыгарылган һәм дә тәүбәсе кабул ителгән көн.

Шулай ук бу көнне күп кенә пәйгамбәрләр төрле бәла-казалардан котылып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешкән. Мәсәлән:

– Нух галәйһиссәламнең көймәсе коры җиргә җитеп, Җуди тавы итәгенә туктаган;

– Ибраһим пәйгамбәр галәйһиссәлам туган;

– Гайсә галәйһиссәлам һәм Идрис галәйһиссәлам күккә ашкан;

– Ибраһим галәйһиссәламне дошманнары утка ыргытканнан соң, ул уттан котылган;

– Муса галәйһиссәлам Фиргавен гаскәреннән котылган;

– Юныс галәйһиссәлам зур балык карыныннан котылган;

– Әюб галәйһиссәлам авыруыннан дәваланган;

– Сөләйман галәйһиссәлам патша булган;

– Йосыф галәйһиссәлам зинданнан азат булган һ.б.

Димәк, бу көннең дәрәҗәсе, һичшиксез, зур. Гашурә көнендә түбәндәге догаларны укырга киңәш ителә:

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

حَسْبُنَا الله وَنِعْمَ الْوَكِيلُ نِعْمَ الْمَوْلَى وَنِعْمَ النَّصِيرُ

سُبْحَانَ اللهِ مِلْءَ الْمِيزَانِ وَمُنْتَهَى الْعِلْمِ وَمَبْلَغَ الرِّضَى وَزِنَةَ الْعَرْشِ لاَ مَلْجَاءَ وَلاَ مَنْجَأَ مِنَ اللهِ إِلاَ إِلَيْهِ سُبْحَانَ الله عَدَدَ الشَّفْعِ وَالْوَتْرِ وَعَدَدَ

كَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّاتِ كُلِّهَا، أَسْئَلُكَ (نَسْئَلُكَ) السَّلاَمَةَ بِرَحْمَتِكَ يآ
اَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللهِ العَلِيِّ الْعَظِيمِ وَهُوَ حَسْبِى
(حَسْبُنَا) وَنِعْمَ الْوَكِيلُ نِعْمَ الْمَوْلَى وَنِعْمَ النَّصِيرُ وَصَلَّى الله عَلَى سَيِّدِنَا
مُحَمَّدٍ خَيْرِ خَلْقِهِ وَعَلَى آلِهِ وَصَحْبِهِ أَجْمَعِينَ.

**Бисмилләһир-рахмәнир-рахим**

Хәсбүнәл-лаһи вә нигъмәл-вәкиил, нигъмәл-мәүләә вә нигъмән-нәсыйр.

Сүбхәәнәл-лаһи мил’әл-мизәәни вә мүнтәһәл-гыйлми вә мәбләгар рида вә зинәтәл-гаршә ләә мәлҗә’ә вә ләә мәнҗәә минәл-лаһи илләә иләйһи.

Сүбхәәнәл-лаһи гадәдәш-шәфгый вәл-вәтри вә гадәдә кәлимәәтил-лаһи әт-тәәммәәти күллиһә. Әс’әлүкә (нәс’әлүкә) әс-сәләәмәтә бирахмәтикә йә әрхәмәр-раахимин. Вә ләә хәүлә вә лә куввәтә илләә бил-ләһил-галийийил-газыйм.

Вә һүә хәсби вә нигъмәл-вәкиилү вә нигъмәл-мәүләә вә нигъмән-нәсыйру.

Вә салләллаһү галә сәййидинә Мухәммәдин хайри халькыйһи вә галәә әәлиһи үә сахбиһи әҗмәгыйн

**Мәгънәсе:** Бу дөньяда барча мәхлүкъларга да, Кыямәт көнендә мөэминнәргә генә рәхимле булган Аллаһы исеме белән. Безгә бары Аллаһы җитә. Иң яхшы ярдәмче, иң яхшы Мәүлә һәм яклаучылар арасыннан иң яхшы Зат. Аллаһыга Мизан тулганчы, Аның гыйлеме кадәр, Аның ризалыгын алганчы, Гареш авырлыгы кадәр мактаулар булсын. Аллаһыдан баш-

ка коткаручы юк. Аллаһыга так вә җөп саннар, Аллаһының камил сүзләре саны кадәр мактаулар булсын.

Синең рәхмәтең илә тынычлык сорыйбыз, ий Рәхимле вә Шәфкатьле.

Аллаһыда булган көч һәм куәт һичбер затта юк.

Ул миңа (безгә) җитә, Ул таянырлык иң яхшы Зат, ярдәм бирүче иң яхшы Зат. Иң күркәм кеше – Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә, аның әһле бәйтенә вә сәхабәләренә Аллаһының салаваты вә сәламе булса иде.

Әс-Сухраварди хәзрәтләре: «Гашура көнне бу доганы 10 мәртәбә укырга хәленнән килгән кешенең янына ул елны Газраил фәрештә килмәс. Әгәр ул елны кешегә дөньядан китәргә тәкъдирендә булса, Аллаһы Тәгалә аңа бу доганы укырга мөмкинлек бирмәс!» – дигән.

Шулай ук тагын бер нәрсә хакында әйтмичә узып булмый, чөнки мәгълүмат чыганакларында бу вакыйганы киң яктырталар һәм аны Ислам дине белән бәйлиләр. Ул Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең оныгы Хөсәен вафат булган көн (626-680). Без ул көндә аларга дога кылабыз. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен сорыйбыз. Ләкин башка фиркалар кебек шуннан артык гамәлләр кылмыйбыз.

*Дамир хәзрәт Гаффаров,*

*Лаеш мөхтәсибәте*

*13 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 14 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# «Хизбүт-тәхрир» – шәйтан партиясе!

Барча мактауларыбыз – Аллаһы Тәгаләгә, барча салават-шәрифләребез – Мөхәммәд галәйһиссәламгә булса иде. Аллаһы Тәгалә изге Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاءً فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا وَكُنتُمْ عَلَىٰ شَفَا حُفْرَةٍ مِّنَ النَّارِ فَأَنقَذَكُم مِّنْهَا ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ ﴿١٠٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Берләшкән хәлегездә Аллаһы арканына ябышыгыз. Аннары һич тә аерылмагыз! Һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! Янә Аллаһы сезгә биргән нигъмәтләрен күңелегездә саклагыз: мөселман булганчы, бер-берегезгә дошман идегез. Аллаһы Ислам дине белән күңелегезгә дуслык, өлфәт мәхәббәтен салды да, бер-берегезгә дин кардәшенә әвереледегез. Сез җәһәннәм ярының читенә килгән идегез, Аллаһы рәхмәт кылып, сезне коткарды. Әнә шулай Аллаһы сезгә аятьләрен ачык бәян итәр, шаять, дөрес аңлап, дөрес гамәл кылып, туры юлдан барырсыз!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча без кешеләрне изгелеккә чакырырга, золымнан сакланырга һәм ялган идеология таратучы, Ислам дине

нигезләрен бозучы кешеләр, оешмалар турында сөйләргә тиешбез. Кызганыч, күп кешеләр белемсезлекләре аркасында йә баю максаты белән үз ялгыш фикерләрен Ислам дип атаган секталар кочагына эләгәләр. Алар үзләре үк адашканнар һәм бүтәннәрне дә шул ялган юлга чакыралар, динне фани дөнья мәнфәгатьләре өчен кулланалар, Коръәни аятьләрне саталар. Ә бит Аллаһы Тәгалә боларны эшләргә тыя:

وَلَا تَشْتَرُوا بِآيَاتِي ثَمَنًا قَلِيلًا وَإِيَّايَ فَاتَّقُونِ

**«Безнең аятьләребезне дөнья малына сатмагыз! Аллаһы хөкемнәрен яшермәгез һәм үзгәртмәгез, Минем газабымнан сакланыгыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:41

Тәфсирләрдә байлар малына кызыгып, яки алардан куркып, Аллаһы хөкемнәрен яшермәгез һәм үзгәртмәгез, Аллаһының газабыннан сакланыгыз дип килә.

«Хизбүт-тәхрир» – кешеләрне ялган идеяләр белән алдый торган, мөселманнарны халык алдында начар итеп күрсәтә, халыкта исламофобия хисен тудыра торган оешмаларның берсе булып тора. «Хизб» гарәп теленнән «партия», «төркем»; «тәхрир» – «иреклек» дип тәрҗемә ителә. Әлеге оешманың тулы исеме «Ireклек партиясе» дип атала.

Бу агым турында сөйләшә башлаганчы, түбәндәгене искә төшерик әле. Коръәни Кәрим буенча мөэминнәр башка диннәрдәге кебек төрле агымнарга, партияләргә бүленергә тиеш түгел. Шулай ук, Коръәни Кәрим буенча безгә бары тик ике генә төркем хакында билгеле: «Аллаһы төркеме» (Хизбуллаһ) һәм шәйтан төркеме (хизбуш-шәйтан). Аллаһы төркеменә Аллаһы Тәгаләнең китабына һәм Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сөннәтенә ияргән мөэминнәр керә, ә шәйтан төркеменә яңа партияләр, дингә яңалык кертүчеләр, җәмәгатьне таркатучы, фетнә чыгаручылар

керә. «Хизбүт-тәхрир» оешмасы «шәйтан төркеме»ннән икәненә бернинди дә шик юк.

Аллаһы Тәгалә алар хакында болай дип әйтә:

اسْتَحْوَذَ عَلَيْهِمُ الشَّيْطَانُ فَأَنسَاهُمْ ذِكْرَ اللَّهِ ۚ أُولَٰئِكَ حِزْبُ الشَّيْطَانِ ۚ أَلَا إِنَّ حِزْبَ الشَّيْطَانِ هُمُ الْخَاسِرُونَ ﴿١٩﴾

**«Шәйтанны аларга ирекле кылдык. Ул аларны үзенә кол итте, Аллаһы зекере булган Коръән вәгазьләрен һәм хөкемнәрен аларга оныттырды, ул монафикълар шәйтан партиясеннән, игътибарлы булыгыз, алар – һәлак булучылардыр».**

«Мүҗадәлә / Бәхәсләшү», 58:19

Бу «төркем» Аллаһының шушы сүзләренә туры килгәнен аңлар өчен оешманың эшчәнлек тарихына игътибар итәргә кирәк.

«Хизбүт-тәхрир» оешмасы 1953 елда Тәкыеддин Ән-Нәбһәни исемле кеше тарафыннан оеша. 1977 елда Тәкыеддин Ән-Нәбһәнинең үлеменнән соң, әлеге оешманың эшчәнлеген 2003 елга кадәр Габделкадим Зәллүм исемле кеше дәвам итә. Ул идарә иткән вакытта әлеге агым «иреклелек таратабыз» дип ышыкланып, Көнбатыш Европа һәм Урта Азиягә кадәр үтеп керә.

«Хизбүт-тәхрир» оешмасы «террорчылар әзерләү мәктәбе» булып тора, монда эләккән кешеләр идеологик яктан шомартылалар. Тәхрирчеләр Аллаһы Тәгаләгә каршы чыкканнардан! Аларның «Ислам хәлифәте» төзү – фарыз гамәл» дигән сүзләре ялган, чөнки Коръәни Кәримдә хәлифәт төзү турында бернинди дә аять юк. Әмма шулай булса да тәхрирчеләр дәлил итеп «Әли Гыймран» сүрәсенең 103 нче аятен китерәләр:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا

**«Ий мөэминнәр! Берләшкән хәлегездә Аллаһы арканына ябышыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Алар бу аятьтәге «جَمِيعًا»дигән сүз хәлифәт төзүне күз алдында тотыла дип аңлаталар. Әмма бу аять хәлифәт төзү хакында сөйләми, ә, киресенчә, мөселманнарның кайда гына булуына карамастан, Коръәнгә нык тотынуны һәм партияләргә бүленмәүне искәртә. Һәм «جَمِيعًا»дигән сүз берничек тә «хәлифәт» дип тәфсир кылынмый. Тәхрирчеләрнең Коръәни Кәрим аятен үз нәфес-теләкләре буенча үзгәртүләре зур җинаятьләренең берсе булып тора. Шушы аять белән аларга каршы чыгарга мөмкиннәр дип, тәхрирчеләр тагын хәйләгә баралар. Мөселманнарны тулысынча бутар өчен, алар үзләренең оешмасын аклап, түбәндәге аятьне дә китерәләр:

وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿١٠٤﴾

**«Сезләрдән арагызда шәригатьне яхшы белгән төркем булсын! Алар сезне хәерле эшләргә чакырырлар, фарыз гамәлләрне, башка төрле яхшы эшләрне кылырга әмер бирерләр һәм фәхеш, харам эшләрдән вә бидгать гамәлләрдән тыярлар. Әнә шундый җитәкчеләре булган җәмәгать һәлак булудан котылып, өстенлек табучыдыр».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:104

Тәхрирчеләр исә тагын «أُمَّةٌ»сүзен «партия», «төркем» дип тәфсир кылдылар. Әмма изгелеккә чакыручы, тыйганнарны тыючы төркем Аллаһы Тәгаләнең төркеменнән һәм мөселманнар белән бергә булырга

тиеш. Андый төркем яңа партия ясап, Ислам диненнән, мөселманнардан аерылырга омтылырга тиеш түгел.

Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ وَتُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ ۗ

**«Ий, сез Мөхәммәд өммәте, дөньяга чыгарылган өммәтләрнең иң хәерлесе булдыгыз, Аллаһыга хак ышану белән ышандыгыз, кешеләрне хәерле эшләргә, изге гамәлләргә өнди белү белән өндәдегез һәм бозык, зарарлы эшләрдән тыя белеп тыйдыгыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:110

Аллаһы Тәгалә бар мөселман өммәтен изгелеккә чакыручы дип искәртә, әмма бернинди дә партия, төркем турында сүз әйтми! Әй кардәшләрем! Исегезгә төшерегез: иблис Худ галәйһиссәламнең халкын пәйгамбәрләренә нинди сүзләр белән дәшергә котырта:

قَالَ الْمَلَأُ الَّذِينَ كَفَرُوا مِن قَوْمِهِ إِنَّا لَنَرَاكَ فِي سَفَاهَةٍ وَإِنَّا لَنَظُنُّكَ مِنَ الْكَاذِبِينَ ﴿٦٦﴾

**«Без сине акылсызлыкта яшәүче итеп табабыз һәм сине ялганчы дип уйлыйбыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:66

Иблис мәлгунь Аллаһыга: «Син мине азгынлыкка мәхкүм иттең, шуңа күрә мин дә аларны аздырыр өчен синең тугры юлың өстендә утырачакмын», – дигән вәгъдә биргәнен онытмагыз. Шуңа да аны арабызга кертмик.

Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Әгәр берәр авыл йә башка бер җирдә өч мөселман кеше җәмәгать намазыннан аерылсалар, алар-

ны шәйтаннар әйләндереп алыр. Шуңа күрә бергә нык торыгыз, аерылмагыз. Чынлыкта, көтүдән аерылган сарыкны бүре ашый», – дип әйтә.

Газиз кардәшләрем! Югарыда искә алган «Хизбүт-тәхрир» 73 фирканың берсе генә. Әмма шундый ялган юл белән яшьләрне адаштыручы оешмалар, кешеләр саны әле бик күп.

Бу хакта Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَمِنَ النَّاسِ مَن يُجَادِلُ فِي اللَّهِ بِغَيْرِ عِلْمٍ وَلَا هُدًى وَلَا كِتَابٍ مُّنِيرٍ ﴿٨﴾

**«Кешеләр арасында ләгънәт кылынган иблис артыннан ияреп, Аллаһы Тәгалә турында белемнәре булмыйча да, Аның турында теләсә нәрсә сөйләп, тавыш кубаручылар бар».**

«Хаҗ», 22:8

Аллаһы Тәгалә сөйләнелгән вәгазь белән миңа да, сезгә дә вәгазьләнергә; бердәм җәмәгать булып, Үзенең яраткан колларыннан булырга насыйп итсә иде. Әмин!

*Ирек хәзрәт Нуриев,*

*Менделеев районы имам-мөхтәсибе*

*20 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 21 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Раббыбызның мәрхәмәтеннән читләшмик

Барча мактауларыбыз галәмнәрне юктан бар кылган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Һәм дә салават-шәрифләребез Аның хәбибе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булса иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ!

Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмин, без даими рәвештә Аллаһы Тәгаләгә хәмед-сәналәребезне әйтәбез. Әлхәмдүлилләһи Раббил гааләмин, Аның сөекле илчесе Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребезне җиткерәбез.

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ كُنتُمْ أَعْدَاءً فَأَلَّفَ بَيْنَ قُلُوبِكُمْ فَأَصْبَحْتُم بِنِعْمَتِهِ إِخْوَانًا وَكُنتُمْ عَلَىٰ شَفَا حُفْرَةٍ مِّنَ النَّارِ فَأَنقَذَكُم مِّنْهَا ۗ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ ﴿١٠٣﴾

**«Ий мөэминнәр! Берләшкән хәлегездә Аллаһы арканына ябышыгыз. Аннары һич тә аерылмагыз! Һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! Янә Аллаһы сезгә биргән нигъмәтләрен күңелегездә саклагыз: мөселман булганчы, бер-берегезгә дошман идегез. Аллаһы Ислам дине белән**

**күңелегезгә дуслык, өлфәт мәхәббәтен салды да, бер-берегезгә дин кардәшенә әверелдегез. Сез җәһәннәм ярының читенә килгән идегез, Аллаһы рәхмәт кылып, сезне коткарды. Әнә шулай Аллаһы сезгә аятьләрен ачык бәян итәр, шаять, дөрес аңлап, дөрес гамәл кылып, туры юлдан барырсыз!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:103

Бу аятьне ишеткәч, әлбәттә: «Дүрт мәзһәб бар, игътикадта аерымлыклар бар», – дияргә мөмкиннәр. Һәм бу сүзләрдә хаклык та бар. Әмма шушы дүрт мәзһәб һәм матуриди белән әшгарый игътикадлары бер «Әһле-Сөннәт Вәл-Җәмәгать» төшенчәсен тәшкил итә. Ә аның асылы Коръәни Кәрим һәм сөннәткә барып тоташа.

Россиядә, Кавказ республикаларын исәпкә алмаганда, хәнәфи мәзһәбе һәм матуриди игътикады таралган. Шул исәптән, Татарстаныбызда да. Әгәр дә кемдер, безнең янибызга килеп: «Сез динне дөрес тотмыйсыз, сез Коръәнгә, Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә түгел, ә Әбү Хәнифәгә, Матуридига, аларның агымына иярәсез», – дип әйтә икән, белегез: бу – адашкан фирка. Чөнки асылда бөек галимнәребез Имам Әгъзам Әбү Хәнифә һәм Имам Әбү Мансур Әл-Матуриди һәм аларның күпсанлы шәкертләре бары тик Коръәнгә һәм бары тик Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә генә таянган. Тәһарәтне барлы-юклы алырга өйрәнгән, намазыбызны аннан-моннан укыган килеш, дин мәсьәләләрендә иҗтиһад кылудан, галимнәрне сүгүдән һәм, аеруча, шушы ялгыш фикерләребезне таратудан саклансак иде. Халкыбыз: «Бүленгәнне бүре ашар, аерылганны аю ашар», – дип юкка гына әйтмәгән.

Халыкның хикмәтле бу сүзләре дингә дә турыдан-туры кагыла. Бүлендек икән – безне шәйтан «ашап бетерәчәк», чөнки андый аерылулар Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында да, соңрак чорларда да булган. Бүген дә бар. Мәчетләргә керәбез. Имам дөрес итеп намазны алып бара. Аның артында ун кеше басып торса, шуларның берсе йә куллар

селкеп, йә тавыш белән «әәмин» кычкырып, шушы бердәм җәмәгатьтән аерыла. Әйе, башка мәзһәбләрдә ул дөрес. Ләкин бу җирлектә намазны хәнәфи мәзһәбе буенча укыйлар икән – болай аерымлану фетнә чыгарырга мөмкин.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мөселман өммәте бер тән кебектер, берәр әгъзасы авыртса, бөтен тән яна башлый», – дип әйткән. Әгәр беребез аерылырга тырыша икән – нинди бердәмлек турында сүз булырга мөмкин? Намазга басканда да без имамга ияребез, аңа оеп укыйбыз. Бер җәмәгать булып, бердәм булып, имам артыннан кабатлап, гыйбадәтебезне кылабыз. Әгәр намазда да бер тән була алмасак, мөселманның бердәмлеге шул булдымы?! Безгә бүленмичә, талпынмыйча, имамнарыбызга, Диния нәзарәтебезгә итагать кылып яшәү кирәк.

Мәзһәб мәсьәләсендә сораулар еш туа. Фетнә чыгаручылар үзләренең белемсезлегенә таянып, безнең гыйлемсезлегебездән файдаланып, халыкны бутый, шәйтан өчен җирлек тудыра. Мәзһәбләр, бер галим исеме белән йөртелсә дә, аларның нигезендә бик күп гыйлем ияләренең фикерләре, гомерләре буе динне өйрәнүдә, гыйбадәттә, тормыш-көнкүрештә кылган хезмәтләре ята. Алар укыган, өйрәнгән, силсиләләрне барлаганнар. Фикерләшкәннәр, дини бәхәсләр алып барганнар һәм уртак нәтиҗәгә килгәннәр. Ул галимнәр вакыт ягыннан да Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның сәхабәләре яшәгән чорга безгә караганда күпкә якынрак. Төрле ялган агымнарга нигез салган кешеләр дүрт мәзһәбкә нигез салган галимнәрнең иң соңгысы вафатыннан соң өч йөз елдан соң гына туган. Безнең чорның ул вакытлардан күпмегә ерак булганын әйтеп торасы да юк. Кичә нәрсә эшләгәнебезне, кемне рәнҗеткәнебезне белмибез, хәтерләмибез – галимнәргә тел-теш тидерүдән оялмыйбыз. «Мин Коръәнгә һәм сөннәткә генә ияреәм», – дип әйтәбез. Ләкин кайсыбыз әле Аллаһы Тәгалә сүзләрен үзе аңлар дәрәҗәгә ирешкән? Гәрчә гарәпчә белмәсәк тә, Коръәнне, хәдисләрне тәрҗемәдә өйрәнсәк тә, үзебезне

мөҗтәһидләр кебек хис итәбез. Аллаһы Тәгаләнең кануннары бар, һәм галимнәребез безгә ул кануннарны аңлатып биргән. Әйе, кайбер аятьләр безгә ошамаска мөмкин. Нәфесебез аны башкача, үзенә җайлырак итеп аңларга теләр. Шәйтан тырышлыгы белән тәкәбберлегебез дә эшкә кушылыр. Хаклыктан ераклашуыбыз да шулай башланыр.

Адәм галәйһиссәламнең җәннәттән куылуының сәбәбе нәрсәдә? Шәйтанның: «Аша, аша», – дип вәсвәсә кылуына колак салып, Раббысы тыйганнан тыелмау. Үз нәфесебезне тыңламыйк, шәйтанга иярмик. Әлбәттә, һәрберебездә тәкәбберлек бар. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисен онытмыйк: «Калебендә бик аз микъдарда гына да тәкәбберлек булган кеше җәннәткә кермәс». Һәм үзебезне үзебез Раббыбыз рәхмәтеннән читләштермик.

Шәригатьтә шундый канун бар: берәүнең остазы юк икән, аның остазы шәйтан булачак. Шуңа күрә, үзебез белмибез икән, монысы – дөрес, монысы – ялган дип әйтә алмыйбыз, чөнки шәйтан йогынтысына бирелгән булуыбыз бар. Нәфесебезгә кайсы якынрак – шуны кабул итүебез бар. Шуңа да, дингә килдек икән, сорауларыбыз бар икән – ә алар һичшиксез булачак – имамнардан сорарга оялмыйк. Үзебез өчен үзебез фәтва чыгармыйк. Һәм белер-белмәс килеш башкаларның сорауларына җавап бирергә ашыкмыйк. Борынгы гыйлем ияләре дә, мәсьәләне җентекләп өйрәнмичә, җавап бирмәгәннәр. Без исә, уйлап та тормыйча, шунда ук фәтвасын да чыгарып, монысын – җәннәткә, монысын – җәһәннәмгә бүлеп тә куябыз. Гәрчә мәчеткә йөрсәк тә, намазларыбызны укысак та, әгәр дә берәрсе безгә дини сорау белән мөрәҗәгать итсә, шунда ук җавап биргәнче: «Белмим, әйдә, бергә имам янына барыйк, сорыйк, миңа да гыйлем булыр, син дә соравыңа җавап табарсың», – дип җавап бирү хәерлерәк. Катлаулы, нечкә мәсьәлә икән – һәр төбәкнең казыйлары бар. Диния нәзарәтебезнең баш казые, Голәмәләр шурасы бар. Җавапны интернеттан, әллә нинди билгесез кешеләрдән түгел, алардан эзлик. Ял-

гышып, шуларга иярәбез икән – Ахырзаман җиткәч: «Безне шушы кеше бутады», – дип әйтә алмаячакбыз, чөнки ул үзе өчен генә җавап бирә. Аның бернинди җаваплылыгы да юк. Эше җиңел – ялгышты, башкаларны адаштырды һәм юк булды. Ә имам өстендә – бөтен мәхәлләсе өчен җаваплылык. Шуңа күрә имамнар белән дус булу, аралашу, сорауларга җавап табар өчен аларга мөрәҗәгать итү кирәк.

Шәйтан Кыяматкә кадәр безнең арада. Һәм ул безне адаштырырга тырышыр. Төрле фиркаларның максаты – кешеләрне адаштыру, саташтыру, фетнә чыгару. Шундый юлларның берсе – имамнар, галимнәр дәрәҗәсен төшерү. Без андый юлга бармыйк. Саташучылардан, фетнә чыгаручылардан булмыйк. Хаклыктан ерагаймыйк. Раббыбызның тәкъва бәндәләре булыйк. Галимнәргә итагать кылыйк. Имамнарны хөрмәт итик. Адашмыйк. Ялгыш юллардан бармыйк. Йә, Раббым, безләрне хак юлдан алып бар. Адашучылар, Синең ачуыңа дучар булучылар юлыннан түгел.

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*27 сентябрь вәгазе,*

*Мөхәррам аеның 28 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Исламда өлкәннәргә карата мөнәсәбәт

Барлык мактауларыбыз галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рух шәрифенә дип әйткән салават шәрифләребез дә үзенә барып ирешсә иде. Һәм дә Адәм галәйһиссәламнән алып, бүгенге көнгә хәтле килеп киткән барлык мөэмин вә мөэминәләрнең дә рух шәрифләренә дип кылган догаларыбыз аларга барып ирешсә иде. Әссәләмүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ. Җомга көннәребез мөбарак булсын, мөхтәрәм дин кардәшләр!

Вәгаземне башлап җибәрер алдыннан, бер гыйбрәтле хәл турында сөйләп китмәкче булам. Аллаһы Раббыбыз тел ачкычлары бирсен.

Бер олы кеше сүзеннән: «Армиядән кайткан чак иде. Эшкә урнашырга йөрим. Мине колхоздагы бер бригадага билгеләделәр. Эшләп йөрим, намаз да укыштыргалыйм. Ни гаҗәп, әллә эше авыр булгангамы, әллә үзләре шундыймы – бригадасы беләнхәмерне еш эчкәлиләр. Араларыннан бер олырак кеше, сизеп алып, миңа киңәшен бирде: «Карале, кардәш. Намаз да укыйсың. Син болар янында эшләп йөреп, ниятләгән юлыңнан тайпылырсың. Китсәң, хәерлерәк булмасмы икән?» Шуннан соң мин киттем. Дингә бирелдем. Мәчеткә йөри башладым. Аксакалларның нәсыйхәтләрен тыңлап йөрдем. Мине мөәзин итеп тә куйдылар. Инде хәзер үзем дә аксакал булдым. Гаилә дә корып җибәрдем. Сигез бала үстереп, Аллаһыга шөкер, тормышны алып барырга тырыштык. Инде оланнар үстеләр, таралыштылар. Һәрберсе үз гаиләсе белән гомер итәләр. Исән-сау булсыннар инде. Менә 86 яшемне тутырып киләм, әлхәмдүлилләһи

Раббил гааләмин. Гыйбәдәтләремне башкарырга тырышам. Балалар кайтып хәлне белеп торалар. Хәзер шунысы куанычлы: кайчандыр мин эшләп йөргән бригададагы хәмер белән мавыккан кешеләр күбесе намазга бастылар, бергәләшеп мәчеткә йөрибез».

Соңыннан бабай үзенең: «Тәкъвалы булыгыз, намаз кылыгыз, безнең өчен догада булыгыз!» – дигән нәсыйхәтен дә бирде.

Әйе, олыларыбызны без хөрмәтләргә тиеш. Алар яшәгән чорда, ә без әле тумаган вакытларда, нинди авыр тормыш алып барганнар. Ә өлкәннәребез – алар барысы да әти-әниләр. Бүгенге олыларыбыз 60-80 яшьтәгеләр бала чакларын искә ала башласалар, күзләре яшь белән тула. Аларның балачак елларын сугыш афәте тартып алган, күңелле матур яшьлек булмаган. Шуңа күрә, без – киләчәк буын, өлкәннәребезне хөрмәт итәргә тиеш.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кем дә кем олы кешене хөрмәт итсә, Аллаһы Тәгалә шул кешегә дә киләчәктә үзен кайгыртучыны җибәрәчәк», – дип әйткән.

Чыннан да, яшь чакта әле адәм баласы тормышны бик аңлап бетерми. Бөтен авырлык әти-әни җилкәсендә: «Алар минем өчен барысын да башкарыр әле», – дип уйлый. Ә инде үзе үсә төшкәч, уйлана башлана. Әти-әни булу вазифасының нинди җаваплы икәнен аңлый башлый.

Аллаһы Раббүл Гыйззә Коръәни Кәрим китабында болай дип әйтә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ إِلَيَّ الْمَصِيرُ

**«Без кешегә ата-анасына яхшылык итәргә әмер иттек, баланы анасы зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән күтәрде, вә ике елда имезүдән туктады, дәхи кешегә: «Миңа вә ата-анаңа шөкер ит, – дип боердык, бит ахырда Миңа кайтасыз».**

«Локман», 31:14

Димәк, ата-ана начарга өндәми, яхшылыкка, игелеккә дәшә. Без шуны истә тотып, алар өчен дога кылырга тиешбез.

Бер мисал китерәсе килә: мәктәптә дәрес бара икән. Укытучы укучы балаларга өй эше итеп дәрескә иң кыйммәтле әйбер турында сөйләргә әзерләнеп килергә куша. Икенче дәрестә һәрбер бала үзенең иң кыйммәтле әйбере турында сөйли: кем акча җыя торган копилка турында, кем яраткан уенчыгы турында, кем йорт хайваны турында, кем дусты турында. Соңгы укучы кала. Укытучы абыйлары: «Кәрим, син нәрсә әзерләп килдең?» – дип сорый. Укучы бала оялып кына такта янына чыга, ә учында аның – туфрак. Ул шул туфрак турында сүзен башлап җибәрә: «Менә шушы җир өстендә безгә кадәр әби-бабайлар яшәгән. Шул җир өстендә мин йөрим. Әмма, минем әти-әнием шушы җир куенында яталар. Әгәр алар исән булсалар, минем өчен иң кыйммәтле нәрсә – алар белән бергә булуым, чөнки җәннәт аналарның аяк астында. Ә мин ул бәхеттән мәхрүм булдым», – дип сүзен тәмамлый.

Аллаһының Расүле Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләренең берсендә: «Ата-анасы канәгать булган кешедән, Аллаһы да канәгать булыр. Әгәр ата-анасын рәнҗетсә, Аллаһының да рәнҗеше булыр», – дип әйткән.

Мөхтәрәм җәмәгател мөслимин! Исән булган әти-әниләребезне кадерлик. Ә безнең арадан бакыйлыкка күчкән әти-әниләребезгә догалар кылыйк.

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгалә Китабында:

فَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ﴿٧﴾ وَمَن يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ ﴿٨﴾

**«Берәү тузан бөртеге хәтле генә яхшылык кылган булса, аның җәзасын күрер. Вә берәү тузан бөртеге хәтле гөнаһ эшләсә, аның җәзасын күрер».**

«Зүллзиләт / Җир Селкенмәк», 99:7-8

Бу аятьләрдә бәян ителгәнчә, мисалларның төрлесен китерергә була. Мисал өчен, бакчалардагы җиләк-җимешләрне. Су сипмәсәк, җимешләрен бирмәскә мөмкин, ә инде карасак, җирен эшкәртсәк, суын да сипсәк, уңышлары мул, бәрәкәтле булачак, ин шә Аллаһ. Шулай ук баланы дөрес итеп тәрбияләү һәм өлкәннәргә карата мәрхәмәтле булуы турында да шул аятьләргә туры китереп була.

Расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһиссәлам: «Адәм баласы Олуг Затыбызны еш искә алса, ул кешенең калебе йомшак, мәрхәмәтле булыр. Әгәр Аллаһы Тәгаләдән ерагайса, күңеле каты бәгырьле, мәрхәмәтсез булыр», – дип әйткән. Бу хәдис-шәрифтән аңлашылганча, бары тик мөселман булган кешенең генә олыларга мөнәсәбәте, хөрмәте ихлас йөрәктән була, чөнки Ислам динебез безләрне ачык йөзле, киң күңелле булырга, яхшылыкка, изгелеккә, пакьлеккә, юмартлыкка өнди. Калебләребез нык, тулы иман белән тулсын. Әмин!

Тарихка күз салсак, бик аянычлы хәлләр күреп була: мәчетләр бар, әмма манаралары киселгән. Әмма динебезне бетерергә, аны пычратырга тырышсалар да, өлкәннәребез бирешмәгәннәр: динебезне ташламаганнар. Бер-берсенә йөрешеп, йорттан-йортка, хәтта урман читләренә кадәр барып, намаз укыганнар. Һәм бүгенге көндә алар безгә шуны әманәт итеп тапшырдылар. Аллаһының рәхмәтендә булсыннар, догаларыбыз рухларына ирешсен.

Тагын бер мисал китерәсем килә: бер яшь бала мәчеткә йөри башлый. Аны һәрвакыт мөлаем йөзле ак сакаллы карт яшь бала сыман елмаеп каршы алган. Икенче көнне дә, өченче көнне дә шул ук хәл кабатланган. Дүртенче көнне баргач, бала исе китеп, бабайдан сораган: «Бабай, нигә син мине яшь сабый сыман елмаеп каршы аласың?» – дип сораган. Бабай исә: «Әйе, сабый кебек шул, үзем 74 тә булсам да, динебезгә басканга дүрт кенә ел булды. Ә үткән җитмеш ел гомеремне бушка уздырып яшәдем.

Менә синең яшьли килеш мәчеткә йөрүеңә куанып, каршы алам да инде», – дип җавап кайтарган.

Әлбәттә, сез күбесе андый түгел бит, башкачарак кыланалар дип әйтерсез. «Мәчетләребез була торып та йөрмиләр, хәмер эчәләр, тәмәкесен дә тарталар, әшәке сүзләр кыстырып сөйләшәләр. Хәтта яшьләр белән бәхәскә дә керәләр», – дип әйтерсез. Әйе, бу күренешне дә истән чыгарырга кирәкми. Үзеңне өлкән дип санproblemыйсың икән, өлкән бул, яшь буынга үрнәк бул. Элек картлар тәмәке тартып торганыңны күрсәләрме, таяклары белән кизәнгәннәр, кеше алдында оялтканнар. Ә хәзер ачыктан ачык, оялмыйча күзгә карап, хәмер эчәләр. Хәтта юл уртасыннан машинасы белән тузан туздырып узып китүчеләр дә очрый. Кайда монда мәрхәмәтле булу, кайда ул олылау. Шуңа күрә, мөхтәрәм җәмәгать, үзебез күркәм үрнәк күрсәтмәсәк, зарланудан файда юк. Хәдисләрнең берсендә үрнәк турында Аллаһының Илчесе галәйһиссәлам: «Үрнәк буласың килсә, телең белән генә әйтмә, гамәлең белән күрсәт», – дип нәсыйхәтен әйткән.

Шуңа да бер мисал: мәчеткә яшь егет килеп керә дә, әбисе өстеннән зарланырга тотына: «Хәзрәт, нигә минем әби намазга басмый икән? Инде мин аның белән талашып беттем бит». Хәзрәт сабыр гына тыңлагач, үзенә сорау бирә:

– Энекәш, сиңа ничә яшь?

– Унөч.

– Әбиеңә күпме?

– Сиксән тула.

– Унөч белән сиксәннең аермасын сизәсеңме? 67 ел арасы күпне сөйли бит. Сабыр ит, дустым! Ә бит әбиең синең яшьтә булганда, нинди газаплар күргән. Ачысын-төчесен, ачлык вә ялангачлык, сугыш урлаган балалык еллары, көнне төнгә ялгап эшләүләр, хәзерге буын михнәт күрмәсен дип тырышулар. Әле син зарланган буласың – шөкер кылыйк. Менә син мәчеткә намазга йөрисең. Ә беләсеңме шул чорны, укучы-

ларга ураза тотмасын дип су каптыруларны?.. Ашагач дога кылмасын дип тикшерүләр булган. Алар бар да йөрәккә үтеп калган. Аллаһының рәхмәтендә булсыннар. Әбиеңә килгәндә инде, Раббыбыз күңеленә салыр, ин шә Аллаһ. Өметебезне өзмик. «Өметсез шәйтан гына» – диелгән бит хәдис-шәрифтә.

Шуның өчен, мөхтәрәм дин кардәшләрем, безнең арада яши торган олы буынны динебез кушканча хөрмәт итик. Мәрхәмәтле булыйк. Әлхәмдүлилләһ, илләребез тыныч, имин. Күкләребез аяз, күңелләребез киң булсын. Хәтта Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм безнең өчен, өммәте өчен дога кылган: «Йә Аллаһым! Адашкан өммәтемне дөрес юлга күндер, чөнки алар ялгышканнардан булучылар».

Аллаһының рәхмәтендә булырга насыйп әйләсен иде. Сөекле хәбибебез өммәтеннән булып, шәфәгатенә ирешергә насыйп итсен иде! Әәмин, Йә Раббил галәмин!

*Фәнис хәзрәт Низамов,*

*Аксубай районы Яңа Дума авылы имам-хатыйбы*

*4 октябрь вәгазе,*

*Сафәр аеның 5 нче көне, һиҗри исәп буенча 1441 ел*

# Укытучылар – галимнәр дәвамчысы

Барча галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Раббыбызга хәмдесәна, мактау-догаларыбыз булса иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават-шәрифләребез ирешсә иде. Җомга көннәре мөбарәк булсын!

Ислам дине укып, гыйлем иясе булуга бик зур әһәмият биргән. Динебезнең гыйлем алуга игътибар бирүен тагын да яхшырак аңлар өчен Пәйгамбәребезгә беренче иңгән аятьтәге «укы» сүзенә күз салу да җитә. Аллаһы Раббыз болай дип әйтте:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ

**«Ий, Мөхәммәд, һәрнәрсәне халык кылучы Раббың исеме илә Коръәнне укы!»**

«Галәкъ», 96:1

Кешелекне караңгылыктан яктылыкка чыгара торган Коръән китабы кешелеккә йогынты ясый торган китап булгач, аятьләр эчендә «гыйлем» сүзенә басым ясаган очракларны күрергә мөмкин. Мәсәлән, Аллаһы Раббыз болай дип әйтте:

قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

**«Хәбибем! «Гыйлемнәре булган һәм гыйлемнәре булмаганнар бертигез булырлармы әллә?» – дип әйт».**

«Зөмәра / Халык Төркеме», 39:9

Гыйлем – Аллаһы Тәгаләнең бер сыйфатыдыр. Ихласлылыгыбызны түбәннән югары мәртәбәгә күтәрү бары тик белем алу аркылы гына була. Бар милләтнең иң олы дошманы – җаһиллек, наданлыктыр. Наданлык белән көрәшмичә, дошманнарны җиңеп булмый.

Раббыбыз Аллаһы Тәгалә:

وَاللَّهُ أَخْرَجَكُم مِّن بُطُونِ أُمَّهَاتِكُمْ لَا تَعْلَمُونَ شَيْئًا

**«Аллаһы Тәгалә сезне аналарыгызның карыннарыннан шундый бер хәлдә чыгарды ки, хәтта сез берни дә белми идегез...»,** – дип безнең исебезгә төшерә.

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:78

Бу аятьтән беркемнең дә бу дөньяга белеп, ягъни гыйлемле булып тумаганы аңлашыла. Шуңа да адәм баласына белем туплау вәҗиб хөкемендә. Моның иң хәерле юлы: «Галимнәр – пәйгамбәрләрнең варисларыдыр», – дигән хәдискә муафыйк кылып, гыйлемне галимнәрнең (остазларның) авызыннан ишетеп җыярга кирәк.

Бүген без белемне «дистанцион» рәвештә алу шәкеленә өстенлек бирүче яшьләрне очрата алабыз. Балалар җәмгыятьтән аерылып, «домашнее обучение, образование»га, ягъни өйдән чыкмыйча гына, җансыз «экран» аркылы белем ала. Педагог һәм методистлар әйтүенчә: «Ул методика тиз темп белән үсеш ала башласа да, бу – безнең өчен бер яңалык һәм аның кая илтәсен беркем дә әлегә әйтеп һәм фаразлап бирә алмый». Алар бу өлкәдәге яңалыкны ныклап өйрәнергә чакыралар. Хәзер инде бу хәл дөньяви уку йортларында гына түгел, ә дини уку йортларында да кулланыла. Яшүсмернең «электрон» дәрес алган вакытында экранның теге як чыбыгында «дөрес» мөгаллим утырганын каян беләбез һәм моңа кем нинди гарантия бирә ала?

Кеше ялгыз башына хакыйкатьне (дөреслекне) яманнан аеру халәтендә яратылмаган, ул бер сәбәпчегә, ягъни мөгаллимгә мохтаҗ.

Юкка гына Аллаһы Тәгалә җир йөзенә пәйгамбәрләр һәм китаплар җибәрмәгән.

Чын гыйлемне остазсыз-галимсез үзләштереп булмый. Ә без остазларыбызны ничек хөрмәт итәргә тиеш соң? Игътикадыбызда тәкъдир ике төрле була:

1. Без үзгәртә алмаган һәм көчебез җитмәгән тәкъдир;

2. Без үзгәртә алган тәкъдир.

Беренчесенә кешенең тышкы кыяфәте (гәүдәсе, акылы), ата-ана, туган җире (туган туфрак), милләте һәм укытучы-мөгаллимнәр керә. Һәм, әйе, без укытучыларны да сайлый алмыйбыз икән. Алар безгә ата-ана кебек Аллаһы тарафыннан билгеләнгән затлар. Без аларны хөрмәт итәргә тиеш.

Әгәр дә бер шәкерт кеше (укучы) даны таралган укытучыда гына укырга теләп, бер остаздан икенче остазга сикереп, күчеп йөрсә, бу наданлык билгесе була, чөнки гыйлем өстәргә теләгән кеше кая һәм кемдә генә булуга карамастан, шул җирендә хикмәт һәм зирәклек табарга тиеш.

Танылган галимебез Ризаэтдин бине Фәхретдин хәзрәтләре үзенең әдәп китабында мөгаллимнәргә карата хөрмәт итүне болайрак яза:

1. Остаз вә мәктәп җитәкчеләре сезнең эшегезне юлына куючылар вә сезнең өчен хәсрәт чигүчеләр булып, аларның сезнең өстегездә олы хаклары бардыр. Шуның өчен аларның кушканнарын җиренә җиткерүдә кимчелек эшләмәгез вә тыйган эшләрендә әвәләнмәгез!

2. Сөйләшкән вакытыгызда алар белән әдәпле сөйләшегез, артык кычкырмагыз, аларны алдап вә бер кешене гайбәт итеп бер дә сөйләмәгез!

3. Аталарыгыз тәннәрегезне тәрбияләп үстергән хәлдә, остазларыгыз җаннарыгызны тәрбия итеп үстерәләр. Бу сәбәпле, остазларыгыз — бөек аталарыгыздыр. Сез дә боларны чын күңел белән сөегез, нәсыйхәтләрен тыңлагыз, авырулар табибларга тапшырылган кебек, барлык ихтыярыгызны аларга тапшырыгыз, аларның теләкләренә каршы килмәгез!

4. Мөгаллимнәрегезгә түбәнчелекле булыгыз, каршыларында әдәпле утырыгыз, нәсыйхәтләре белән гамәл кылыгыз, саваплы булыр өчен хезмәтләрен җиренә җиткерегез, аларга ялыныгыз, башка урында ялыну – мөэмин-мөселманга хас булмаган хәлдә, гыйлем өйрәнү тугрысында ялыну – мөэмин-мөселман сыйфатыдыр.

5. Мөгаллимнәргә каршы килмәгез, алар белән кычкырышмагыз, һәрбер гүзәл эшләрдә аларның сүзләренә җан вә тән белән иярегез. Ләкин аңламаган урыныгыз булса, шул хәленчә калдырып китмичә, бәлки әдәп вә сабырлык белән: «Әфәндем, бу җирне аңламадым вә бу сүзне белмәдем», – дип кайтарып сорагыз!

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өлкәннәрне хөрмәт итмәгән, кечеләрне кече итмәгән һәм гыйлем ияләренә тиешле хөрмәтне күрсәтмәгән кеше минем өммәтемнән түгелдер», – дип әйтте. Шулай ук Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Фәннәрне өйрәнегез, гыйлемнәр алыгыз. Һәм шул фән белән гыйлемнәрне үзләштерүдә булышкан галимнәргә (остазларга) сабырлык күрсәтүне исегездән чыгармагыз», – дип әйтте.

Гыйлем алу Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына һәм җәннәт юлына алып килә. Бер хәдистә болай дип әйтелә: «Кем гыйлем алу нияте белән юлга чыкса, Аллаһы Тәгалә аны җәннәткә илтә торган юлга чыгарыр. Фәрештәләр гыйлем алучының аяк асларына канатларын җәеп торырлар. Һичшиксез, гыйлем иясе өчен җирдә һәм күктә булган һәрнәрсә, хәтта су эчендәге балыклар да аның өчен гафу сорап торырлар. Гыйлем иясенең гыйбадәт кылучы кешедән фазыйләте (өстенлеге), айның йолдызлардан өстенлеге кебектер. Галимнәр пәйгамбәрләрнең варислары. Пәйгамбәрләр исә үзләреннән соң мираска беркемгә дә динар да, дирһәм дә калдырмаслар. Алар мирас итеп гыйлем калдырырлар. Аны алган кеше мираска мул итеп акча алган кебек булыр» .

Ләкин гыйлем юлы – сабырлык һәм тырышлык сорый торган бер юлдыр. Ул төрле сынаулар һәм авырлыклар белән чорналган. Җәннәткә илтә торган юллар да авырлыклар белән бөтерелгән бит. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең бер хәдисендә: «Тән рәхәтлеге белән генә гыйлем алырга көч җитми», – дип әйтелә.

Белемнең фазыйләтен дәвам итеп башка хәдис тә китерелә: «Үзе өчен яки кемне дә булса өйрәтү ниятеннән гыйлемнән бер бүлек өйрәнгән кешегә, Аллаһы Тәгалә чүлдәге һәр ком бертеге кадәр әҗер-савап язар».

Бер әдәп дәресләрен өйрәтә торган китапта болай язылган: «Кеше гыйлем алуын дәвам иткәнчегә кадәр галим булып санала. Ләкин ялгыш укыган гыйлеме күп дип уйлап, гыйлем алуын туктатса һәм янындагы булган кеше белән сүз көрәштерә башласа, ул кеше дөньяның иң надан кешесенә әверелер».

Бервакыт Габдулла бине Мөбарәк хәзрәтләреннән: «Әгәр Аллаһы Тәгалә сиңа кайчан үләчәгеңне белдерсә, нәрсә белән шөгыльләнер идең?» – дип сорадылар. «Гыйлем белән шөгыльләнер идем», – дип әйткән. «Гыйлемнән өстенрәк нәрсә юкмени?» – дип сорагач, ул: «Әйе, аннан да өстенрәк бернәрсә дә юк», – дип җавап кайтарган. «Гыйлем белән шөгыльләнүнең башка гыйбадәтләрдән фазыйләтлерәк икәнен ни белән исбатлап бирәсең?» – дип сорагач, ул: «Гыйлем һәрнәрсәдән дә югары, чөнки Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәренә һәрнәрсәне дә бирде һәм артыгын сорау белән әмер ителмәде. Гыйлем хакында исә: «Әй, Раббым, минем гыйлемемне арттыр», – дип әйтергә боерды. Әгәр Пәйгамбәребез Аллаһыдан гыйлемнән тыш башка нәрсә сораган булса, мин дә гыйлемне өстен куймас идем», – дип җавап биргән.

Гыйлемнең өстенлеге исбатлый торган Пәйгамбәребезнең түбәндәге хәдисен китерәсем килә: «Сөләйман галәйһиссәлам мал, солтанлык һәм гыйлем сайлау арасында ирекле кылынды. Ул гыйлемне сайлап алды. Шуңа да, нәтиҗәдә, байлыкка һәм солтанлыкка да ирештерелде» .

Әбү Әвсәд хәзрәтләре: «Гыйлемнән башка кыйммәтле бернәрсә дә юктыр. Солтаннар кешеләр өстендә хакимдер. Ә галимнәр исә солтаннар өстендә хакимдер», – дип әйтте. Галимнәр дөньяда кешеләргә юл күрсәтеп, хәерле гамәлләргә сәбәпче буган кебек, Ахирәттә дә юл күрсәтүләрен дәвам итәчәкләр.

Вәгазьне йомгаклап, түбәндәге хәдисне карап китик: «Җәннәт әһелләренең җәннәттә дә галимнәргә ихтыяҗлары булыр. Җәннәт кешеләре һәр җомга көнне Аллаһы Тәгаләне зиярәт итәрләр. Аллаһы Тәгалә аларга: «Миннән теләгән нәрсәләрегезне сорагыз», – дип әйтер. Алар исә галимнәргә борылып: «Нәрсә сорыйк?» – дип әйтерләр. Галимнәр: «Аллаһыдан шуны-шуны сорагыз», – дип җавап бирерләр. Кешеләр галимнәргә дөньяда мохтаҗ булган кебек, Ахирәттә дә мохтаҗ булырлар».

Аллаһы Тәгалә безнең калебләребезгә гыйлемгә карата ихласлык һәм мәхәббәт салып, өстебездә билгеләп куелган остаз һәм имамнарыбызга олуг хөрмәт күрсәтеп, мөгаллим һәм хәзрәтләребезнең хәер-догаларын алырга насыйп итсен. Әәмин!

*Фатих хәзрәт Нуруллин,*

*Зәй районы имам-мөхтәсибе*

# Әссәләму галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

## Хөрмәтле имамнар, укучыларыбыз!

Журналыбыз редакциясе сезне хезмәттәшлек итәргә чакыра. Пәйгамбәребез хәдисләрендә мөселманнарга булган гыйлемнәре белән уртаклашуның зарурлыгын әйтеп калдыра. Шулай ук имам Әхмәд: «Белем байлыкка охшаган: байлык күбрәк булган саен, аннан күбрәк зәкят түләнә», – дип әйткән. Имам Гали әйткән: «Белүче үз гыйлемнәре белән бүлешә барган саен, аңа яңа гыйлем чыганаклары ачыла бара, алар үсә, ныгый һәм аныклана. Башкаларны укытканда ул элек алган белемен ныгыта һәм яңасын ала».

«Шура» журналында вәгазьләрегез, мәкаләләрегез, әдәби әсәрләрегезне урнаштырасыгыз килсә, shura@huzur.ru электрон почтасына яки 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы 6/27 («Шура» журналына» дип) адресына хатлар юллый аласыз.

Редакциягә килгән язмалар үзгәртелә ала, бастырылмаска мөмкин һәм кире кайтарылмый.

# Фәтвалар

# Мөмкинчелеге булганнарга хаҗны кичектерергә ярыймы?

**Сорау:** Мөмкинлек туган очракта, хаҗны шул ук елда кылу мәҗбүриме, әллә соңрак та ярыймы?

**Җавап:** Бу мәсьәләдә галимнәр арасында фикер төрлелекләре бар. Бу фикер каршылыклары ике имам – Әбү Йосыф һәм Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһимнәр арасында туа.

Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһи фикеренчә, барлык шартларны үтәргә мөмкинлек тугач та, хаҗны шул ук елда үтәү фарыз. Ә имам Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһи хаҗ кылу мәҗбүри була, ләкин шул елда ук түгел, дигән фикер яклы. Ягъни кеше хаҗны бу елда һәм киләсе елларда да кыла ала. Имам Әш-Шәфигый рахмәтуллаһи галәйһи дә шушы фикердә торган. Ә имам Әгъзам рахмәтуллаһи галәйһимнән ике фикер дә китерелә, ягъни «мөмкинлек тугач ук фарыз» һәм «фарыз, ләкин вакыт белән чикле түгел».

Иң элек имам Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһинең карашын карап үтик: Аллаһы Тәгалә хаҗны фарыз кылган, ләкин аны вакыт белән чикләмәгән. Коръәни Кәримнең түбәндәге аятендә болай дип әйтелә:

> **«Көче җиткән кешеләргә Аллаһыга гыйбадәт өчен хаҗ кылу фарыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

Хаҗны үтәү вакытына килгәндә, Коръәндә Аллаһы Тәгалә: **«Хаҗ кылу мәгълүм булган айлар, ягъни шәүвәл, зөлкагыйдә, һәм зөлхиҗҗәнең ахыргы ун көннәре»,** – дип әйтә.

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:197

Бу аятьләрдән шунысы аңлашыла, хаҗны төрле елда, ләкин билгеле айларда кылырга ярый. Коръән безне вакыт белән чикләми һәм шуңа да

хаҗны бу елда (ягъни мөмкинлек туган елда ук) кылу мәҗбүри дип раслау нигезсез.

Шуны да искәртеп үтик, Мәккәне яулау һиҗри 8 нче елда була, ә сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хаҗны бары тик һиҗри 10 нчы елда гына кыла. Әгәр дә хаҗны ашыгыч рәвештә кылырга кирәк булса, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам аны үтәүне кичектермәс иде.

Әбү Хәнифә һәм Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһимнәрнең карашларын карап үтик. Хаҗ кылу вакыт белән чикләнмәгән. Ягъни аны мөмкинлек туу белән шул ук елда һәм киләсе елларда да кылырга була. Ләкин мөмкинлек туу белән кылсаң, ышанычлырак. Әгәр кеше бу фарыз гамәлне кичектерсә, тора-бара бөтенләй дә хаҗ кылырга мөмкинлеге булмавы бар. Имам Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһи фикерен алсак, хаҗ кылырга мөмкинлеге була торып та, аны кичектерүчеләргә бу зарар китерергә мөмкин. Ә инде ашыгыч рәвештә хаҗны кылырга кирәк дигән фикерне алсак, бу күпкә ышанычлырак. Имам Әбү Мансур Әл-Матуриди рахмәтуллаһи галәйһи дә шул ук фикердә торган. Аның фикеренчә, вакыт белән чикләнмәгән теләсә нинди фәрманны (әмер) үтәгәндә, якын арада, ягъни шул вакытта башкаруны аңларга кирәк.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

# Зәкятне тапшыру кагыйдәләре

**Сорау:** Кеше мәчет төзү, мәчеткә келәмнәр алу ниятеннән зәкят түләргә теләсә, бу зәкят булып саналамы?

**Җавап:** Зәкят түбәндәге кешеләргә түләнә:

1. Фәкыйрьләргә – мал-мөлкәте нисаб күләменнән азрак кешеләр (минимиль күләме якынча 230 мең).

2. Мескеннәргә – ул бернәрсәләре дә булмаган, йортларында бернинди уңайлыклары да булмаганнннар.

3. Коллыктан котылырга телүче кешеләргә. Бүгенге көндә безнең җирлектә андыйлар инде юк.

4. Бурычын түли алмаучы кешеләргә – бирәчәк бурычлары бөтен мал-мөлкәтеннән күбрәк булганнар.

5. Аллаһы Тәгалә юлында йөрүчеләргә. Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһи фикеренчә, болар – Аллаһы юлына чыга алмаган (хаҗ кылырга теләүче) ярлылар. Ә Әбү Мөхәммәд рахмәтуллаһи галәйһинең фикеренчә, болар – хаҗларын дәвам итә алмаучылар (ягъни элегрәк хаҗ кылучылар Мәккәгә җәяү барганнар. Юлларын дәвам итәр өчен аларның акчалары булмаган. Бу хаҗ кылучыларга акча бирергә, ягъни зәкят түләргә ярый). Әбү Йосыф рахмәтуллаһи галәйһинең фикере дөресрәк.

6. Юлда, сәфәрдә акчасыз калучыларга. Алар мөселман булса – зәкят бирелә. Аңа зәкяттән үзенә тиешле күләмдә алу рөхсәт ителә, ләкин кирәгеннән артыграгын алу хәләл саналмый.

Барлык галимнәрнең дә уртак фикере буенча, бер белмәгән кешегә зәкят бирү рөхсәт ителми. Шулай ук зәкят акчасына мәчетләр, күперләр төзү, юллар салу һәм хаҗга бару рөхсәт ителми.

Дөрес ният – зәкят түләүнең бер шарты булып тора. Шуңа да күңелдән биреләчәк акчаның зәкят булын ниятләп әйтергә кирәк. Әгәр инде, тиешле сумма ният әйтелмичә генә бирелсә, ул акчалар әле кулланылмаган булса, зәкят түләүче күңеленнән бу акчаның зәкят буларак бирелүен билгели һәм бу рәвешле түләү дөрес булып санала. Зәкят алучы булмаганлыктан, зәкят суммасын мәчет төзүгә һәм келәмнәр алуга тотарга ярамый.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

# Тәһарәт алган вакытта аякларны дымлы салфеткалар белән сөртсәң ярыймы? Тәһарәтне кар белән алырга ярыймы?

**Сорау:** Эштә чакта, тәһарәт алганда гел дә аякларны юып тору уңайсыз. Бу очракта аякларны дымлы салфеткалар белән сөртсәң ярыймы? Бу тәһарәт булып саналамы? Мин Рәсәйнең үзәк өлешендә яшим һәм еш кына урамда булырга туры килә. Миңа тәһарәтне кар белән алсам ярыймы?

**Җавап:** Иң элек «госел» (коену) һәм «мәсех» сүзләренең мәгънәләрен карап үтик. «Коену» – тәннең һәр өлешенә дә су ирешү. «Мәсех» –тәннең өлешләрен юеш кул белән сыпыру. Әгәр дә кеше тәһарәт алганда, тәннең юылырга тиешле өлешләреннән су акмаса (ягъни бер-ике тамчы су да таммый), ул суны тәнгә май сөрткән кебек кенә кулланган булып санала (су таммады). «Заһир Әр-Ривайә» буенча болай рөхсәт ителми.

Кар белән тәһарәт алу мәсьәләсенә килгәндә, галимнәр түбәндәге фикердә торалар: әгәр кеше кар ярдәмендә тәһарәт алса, ләкин тәненнән су таммаса, тәһарәт саналмый. Әгәр инде кар эреп, куллардан тамса, тәһарәт булып санала. Факыйһ Әбү Җәгъфар Әл-Хиндуванидан тәһарәтне кар ярдәмендә алу хакында сорагач, ул: «Бу тәһарәт алу түгел, бары тик «сыпыру». Әгәр кеше кар эреп, ике-өч тамчы су тамырлык дәрәҗәдә тәнен сыпырса (ышкыса), бу тәһарәт булып санала», – дип җавап кайтарган.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

# Мәрхүм исеменнән садака бирергә ярыймы?

**Сорау:** Үлгән кеше исеменнән садака бирсәң ярыймы?

**Җавап:** Әгәр кеше үлгән кеше исеменнән садака биреп һәм аның рухына дога кылса, бу гамәл рөхсәт ителә. Моның әҗер-савабы үлгән кешегә ирешәчәк. «Хизәнәтүл-Фәтәвә» китабында шулай әйтелә.

Ә Аллаһыга яхшырак мәгълүм.

*Камил хәзрәт Сәмигуллин, ТР мөфтие*

# Үрнәк затлар

# Рамлә бинте Әбү Суфиян радыяллаһу ганһә

**Исеме:** Өмме Хәбибә Рамлә бинте Әбү Суфиян Сәрх бине Хәрбе бине Өмәйә бине Габдешшәмс.

**Туган елы, урыны:** якынча 589 нчы елда Мәккәдә дөньяга килә.

**Әтисе:** Әбү Суфиян бине Хәрбе.

**Әнисе:** Сафия бинте Әбү Әл-Гас.

**Тормыш иптәше:** Гобәйдулла бине Җәхш, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм.

## Ислам динен кабул итүе

Әбү Суфиян бине Хәрбе корәешлеләрдән кем дә булса үзенә берәр эштә каршы килер, итагатьсезлек күрсәтер дип башына да китермәгән. Ул Мәккәнең җитәкчесе булганга, аңа бөтенесе дә буйсынганнар һәм ияргәннәр.

Әмма аның кызы Рамлә бу тәртипләргә каршы килгән. Ул ире Гобәйдулла бине Җәхш белән Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә иман китергән.

Әбү Суфиян үзенең көчен һәм абруен кулланып, кызын һәм дә киявен бабалары диненә кайтарырга тырышып караган, ләкин нәтиҗәле булмаган, аның барлык тырышлыгы да бушка киткән. Рамләнең (Өмме Хәбибә) калебендәге иманы шулкадәр нык булган ки, хәтта аны әтисенең тырышлыгы да юкка чыгара алмаган.

Әбү Суфиян кызының Ислам динен кабул итүенә бик тә кайгырган, шул рәвешле корәешлеләр каршында абруе төшүдән курыккан.

## Корәешлеләрнең эзәрлекләве

Корәешлеләр Әбү Суфиянның кызы Өмме Хәбибәгә һәм киявенә ачуланганын белгәч, тагы да батыраеп, аларны төрлечә эзәрлекли башлаганнар. Шул сәбәпле, әлеге гаиләгә Мәккәдә яшәү чыдап булмаслык авыр булган.

Аллаһының Илчесе Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга Хәбәшигә (Эфиопия) һиҗрәт кыларга рөхсәт иткәч, Рамлә, кечкенә кызы Хәбибә һәм ире Гобәйдулла бине Җәхш үзләренең иманнарын һәм Аллаһының динен саклап калу, Хәбәши негусыннан ярдәм, яклау сорау өчен шул тарафларга качарга ниятлиләр.

Әмма Әбү Суфиян һәм Корәешнең башка җитәкчеләре мөселманнарның Хәбәшигә китеп, анда тыныч кына яшәүләренә риза булмаганнар. Алар Хәбәши негусы Нәҗашигә илчеләр җибәреп, аны качакларга каршы котырталар, аларны кире бирүен сорыйлар. Корәешлеләрнең илчеләре негуска мөһаҗирләрнең Гайсә һәм Мәрьям ана турында начар сүзләр сөйләүләрен хәбәр итәләр.

Гайсә һәм Мәрьям ана турында нәрсә сөйләгәннәрен белергә теләп, Нәҗаши мөһаҗирләр янына кеше җибәрә. Шулай ук Коръәннән берничә аять укуларын да сорый.

Нәҗашигә Ислам турында хакыйкатьне сөйләгәч һәм Коръәннән кайбер аятьләр укыгач, ул елап ук җибәргән һәм болай дигән: «Хакыйкатьтә, сезнең пәйгамбәрегез Мөхәммәдкә иңгән нәрсәләр һәм Гайсә бине Мәрьям алып килгән нәрсәләр бер чыганактан».

Шуннан соң ул үзенең бер Аллаһыга һәм Мөхәммәд галәйһиссәламнең пәйгамбәрлегенә иман китерүен игълан иткән. Шулай ук үзенең епископлары Ислам динен кабул итүдән баш тартып, насара булып калсалар да, негус Хәбәши җирлегенә күченеп килгән һәр мөселманның аның яклавы астында булачагын хәбәр иткән.

Әлеге хәлләрдән соң Өмме Хәбибә барлык авырлыклар артта калып, якты көннәр җитте дип уйлаган. Ләкин Аллаһы Тәгалә аны тагын бер сынауга дучар иткән.

## Төшнең чынга ашуы

Бер төндә Өмме Хәбибә ире Гобәйдулланың диңгездә бата язуын, диңгез дулкыннары аны каплавын, ә тегесенең нәрсә эшләргә дә белмичә, һаман диңгез караңгылыгына керә баруын төшендә күрә. Бик нык курыккан һәм кайгырган хәлендә йокысыннан уянып китә. Ул әлеге төшне иренә һәм беркемгә дә сөйләргә теләми.

Ләкин озакламый Өмме Хәбибәнең төше чынга аша: аның ире Гобәйдулла бине Җәхш Ислам диненнән баш тарта һәм насара диненә күчә. Шуннан соң «яшел елан» белән дуслашып, сәрхүшкә әйләнә.

## Ныклык һәм сабырлык

Өмме Хәбибә авыр сайлау алдында кала. Аңа өч юлның берсен сайларга кирәк: беренчесе – ул иренең тәкъдимен кабул итеп, Ислам динен насара диненә алыштыра; икенчесе – иреннән аерылып, әтисе йортына кайта; өченчесе – ул иреннән аерылып, Хәбәшидә кала. Өмме Хәбибә бик нык уйлана, борчыла, кешеләрдән читләшә. Аның өчен бу бик авыр вакытлар була. Ниһаять, ул Хәбәшидә калырга һәм Аллаһы Тәгаләдән җиңеллек көтәргә дигән карарга килә.

Иренә килгәндә, Гобәйдулла бине Җәхш насара динен кабул иткәннән соң озак яши алмый, вафат була.

## Җиңеллек

Иренең вафатыннан соң, гыйддә вакыты тәмамлангач, Аллаһы Тәгалә аңа җиңеллек ирештерә.

Бер төнне Өмме Хәбибә төшендә үзенә Өмме мөэминин (Мөэминнәрнең анасы) дип дәшкәннәрен ишетә. Йокысыннан уянып, ул озакламый Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аңа өйләнәчәген аңлый.

Кояшлы иртәләрнең берсендә аның ишеген кагалар. Ишеген ачкач, ул анда Хәбәши патшасының хезмәтче кызы Әбраһа торганын күрә. Өмме Хәбибә аңа керергә рөхсәт бирә. Хезмәтче кыз аңа болай дип әйткән: «Хәбәши патшасы сине сәламли һәм ул сиңа Мөхәммәд пәйгамбәрнең сине яучылавын хәбәр итәргә кушты. Мөхәммәд галәйһиссәлам аңа хат җибәреп, патшаны никахта вәли булырга чакырган. Син үзең теләгән кешене вәлиең итеп билгели аласың».

Өмме Хәбибә бик нык куанган һәм шатланып: «Аллаһы Тәгалә сине шатлыклы хәбәр белән җибәргән!» – дип әйткән. Шушы шатлыклы хәбәр белән сөендергәне өчен, Әбраһаны бүләкләргә теләп, ул үзенең бизәнгечләрен салып, барысын да (алкаларын, йөзекләрен һәм беләзекләрен) шушы хезмәтче кызга биргән. Аның кулында барлык дөнья байлыклары булса да, ул шулвакытта рәхәтләнеп барысын да биргән булыр иде. Шуннан соң ул Әбраһага: «Минем вәлием Халит бине Сәгыйд бине Гас булачак, чөнки ул минем туганым», – дип әйткән.

## Никах мәҗлесе

Никах мәҗлесе Нәҗашинең бик матур һәм затлы сараенда узган. Никахта пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе булмаса да, Хәбәшидә яшәгән күренекле сәхабәләр чакырулы булган. Алар арасында Җәгъфар бине Әби Талиб, Халит бине Сәгыйд бине Гас, Габдулла бине Хозәйфә Әс-Сәһми һ.б. Алар бу никахның шаһитлары булганнар.

Мәҗлес тантанасын Нәҗаши ачып җибәргән. Ул Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәгә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең ку-

шуы буенча мәһәр итеп дүрт йөз динар биргән. Шуннан соң инде кунакларны сыйлаган.

## Өмме Хәбибә һәм хезмәтче кыз Әбраһа

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә болай дип сөйләгән: «Миңа акча китергәч, мин илле мыскал алтынны Әбраһага җибәрдем. «Син миңа хәбәр китергән көнне үк акча биргән булыр идем. Ләкин ул көнне минем акчам юк иде. Әмма тиздән Әбраһа минем яныма килде дә, алтыннарны һәм бизәнгечләрне кире кайтарды. Ул: «Патша синнән әлеге бүләкләрне алуны тыйды һәм хатын-кызларга үзләрендә булган ислемайларны сиңа бирергә кушты», – дип әйтте.

Икенче көнне миңа хуш исле сары агач, гамбәр китерделәр. Әбраһа миңа: «Минем сиңа бер үтенечем бар», – дип әйтте. Мин аннан нинди үтенече барлыгы турында кызыксындым. Ул минем соравыма: «Мин Ислам динен кабул иттем һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм диненнән барам. Шуңа күрә, Мөхәммәд пәйгамбәргә миннән сәлам әйтергә онытма», – дип җавап кайтарды. Шуннан соң ул миңа бирнәмне әзерләде.

Мине Пәйгамбәр янына илттеләр. Аның белән очрашкач, мин мәҗлеснең ничек узганын, Әбраһа белән булган хәлләрне сөйләдем. Пәйгамбәргә аннан сәлам әйттем. Бу хәл Пәйгамбәрне бик тә шатландырды. Ул: «Аңа Аллаһының сәламе, рәхмәте һәм мәрхәмәте булсын», – дип әйтте».

## Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең Мәдинәгә кайтуы

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең әтисе – Әбү Суфиян никах килешүе төзелгән вакытта Мәккәдә яшәгән. Ул Пәйгамбәребез галәйһиссәлам һәм мөселманнар белән сугышуын дәвам иткән.

Кызының Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кияүгә чыкканын ишеткәч: «Ул – бик яхшы ир, аңа тиңнәр юк», – дип әйткән әтисе. Аның күңелендә Аллаһының Илчесенә карата дошманлык хисләре булса да, ул Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең күркәм сыйфатларын танымый булдыра алмаган.

Корәешлеләр Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән килешүне бозганнан соң, Әбү Суфиян Аллаһының Илчесе белән килешү төзү өчен Мәдинәгә килгән. Ул кызының өенә кереп, келәмгә утырырга теләгән. Ләкин кызы моны күреп алып, тизрәк келәмне җыеп алырга ашыга. Шул чагында әтисе: «Кызым, сиңа минме, әллә шушы келәм кадерлеме?» – дип сораган. Кызы әтисенең соравына: «Бу Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең келәме, ә син – пычрак мөшрик», – дип җавап кайтарган. Әтисенең моңа ачуы килгән һәм ул тавышын күтәреп болай дип кычкырган: «Аллаһы белән ант итәм, минем өемне ташлап чыгып киткәннән соң син үзгәргәнсең». Кызы аңа җавап итеп болай дигән: «Аллаһы Тәгалә мине хак юлга – Ислам юлына бастырды. Ә син, әти? Син – корәешлеләрнең җитәкчесе, үзең һаман да Ислам динен кабул итмисең. Әле дә булса син җансыз ташларга гыйбадәт кыласың. Алар исә сине күрмиләр һәм ишетмиләр дә!»

## Әбү Суфиянның Ислам динен кабул итүе

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә кайчан да булса әтисенең дә Гомәр бине Хаттаб, Халит бине Әл-Вәлид радыяллаһу ганһүмәләр кебек Ислам динен кабул итүенә өметен өзмәгән. Ул әтисе иман китермичә үлеп китәр һәм аның өчен җәннәт мәңгелеккә ябык булыр дип курыккан. Догаларында һәрдаим Аллаһы Тәгаләдән әтисен хак юлга күндерүен сораган. Бик еш Коръәннең түбәндәге аятен укыган:

**«Ихтимал, Аллаһы мөшрикләрдән дошман булган якын кардәшләрегез белән сезнең арагызда дуслыкны булдырыр.**

**Аллаһы кадирдер, бу эшкә көче җитәдер. Аллаһы – Ярлыкаучы, Рәхимле».**

«Мүмтәхәнә / Сыналучы Хатын», 60:7

Әбү Суфиянның Ислам динен кабул итүе Мәккәнең яулап алыну вакыйгасы белән бәйле. Аның кыскача тарихына күз салыйк.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәне яулау өчен походка чыгуларын игълан итә һәм аның әмере буенча уң мең учак ягыла. Корәешлеләр бу хәлне күреп, бик борчылалар һәм үзләре ягыннан Әбү Суфиянны белешергә җибәрәләр. Юлда аңа Габбас бине Габделмотталиб очраган һәм Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Мәккәне яулап алыр өчен килүен хәбәр иткән. Әбү Суфиян бу хакта ишеткәч бик нык куркуга калган: «Берәр чара әйт», – дип ялварган. Габбас бине Габделмотталиб аны иминлек сорар өчен качырының артына утыртып, үзе белән Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм хозурына алып килгән. Гомәр Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе бу хакта белгәннән соң, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам хозурына килеп, аны үз хөкеменә тапшыруын сораган. Ләкин Габбас бине Габделмотталиб: «Мин аңа иминлек вәгъдә иттем» дип, – Әбү Суфиянны кичерүләрен үтенгән. Шуннан соң Расүлуллаһ галәйһиссәлам Габбас бине Габделмотталибка: «Бу төнне аны чатырыңда сакла, иртәгә алып килерсең», – дип боерган.

Икенче көнне Әбү Суфиян Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хозурына килгәч, Аллаһының Илчесе аннан: «Йә Әбү Суфиян, сиңа әле «Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт кылырга яраклы Зат (илаһ) юк», дип әйтер вакыт җитмәдеме?» – дип сораган. Әбү Суфиян: «Атам-анам синең өчен фида булсын, нинди шәфкатьле һәм мәрхәмәтле икәнсең. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләдән башка гыйбадәт итәргә лаек бер нәрсә булса, Корәеш халкының вәзгыяте болай булмас иде», – дип җавап кайтарган. Шуннан соң Расүлуллаһ галәйһиссәлам аннан: «Мөхәммәд расүлуллаһ»,

дип әйтергә вакыт җитмәдеме?» – дип сораган. Әбү Суфиян аңа: «Бу хакта күңелемдә шөбһәм әле бетмәде», – дип җавап кайтарган.

Бераз соңрак Әбү Суфиян барыбер иман кәлимәсен әйтеп, Ислам динен кабул иткән. Кызы Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһә бу көнне бик бәхетле булган.

## Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең дәрәҗәсе

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәне яраткан һәм тирән хөрмәт иткән. Ул бик еш аның дәрәҗәсе турында искәрткән һәм «Өмме Хәбибә һәм аның абыйсы Могавия – җәннәттә булачаклар», – дип әйтә торган булган.

Өмме Хәбибә радыяллаһу ганһәнең дәрәҗәсенә килгәндә, иң элек аның Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтенә иярүен атарга кирәк. Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән берәр боерык ишетүгә, ул аңа бик теләп буйсынган һәм ул гамәлне даими үтәргә тырышкан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм намазның рәкәгатьләре турында хәдисендә болай дип әйткән: «Кем даими рәвештә көн буена (иртәннән төнгә кадәр) 12 рәкәгать намаз укыса, аңа җәннәттә йорт салыныр». Әлеге хәдисне ишеткәннән соң, Өмме Хәбибә шул рәвешле гыйбадәтен кылган. Бөтен гомерен Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылуга һәм дә Аның әмерләрен үтәүгә багышлаган.

Шулай ук Аллаһы Тәгалә якынаю, Аның ризалыгына ирешү өчен ул фарыз гамәлләрне һәм дә өстәмә нәфел гамәлләрне дә башкаруга бик игътибарлы булган. Иренең ризалыгына ирешү өчен дә ул зур көч куйган.

Иманлы мөслимә нәкъ шундый булырга да тиешле. Аллаһы Тәгалә Коръәндә мөэминнәрнең аналарына мөрәҗәгать итеп, болай дип әйтә:

**«Өегездә укылган Аллаһының аятьләрен вә хөкемнәрен зекер итегез, Аллаһы бик нечкә нәрсәләрдән дә хәбәрдар булды».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33: 34

## Рамлә бинте Әбү Суфиянның вафаты

Мөэминнәрнең анасы Рамлә бинте Әбү Суфиян (Өмме Хәбибә) радыяллаһу ганһә 665 нче елда, абыйсы Могавия бине Әби Суфиян радыяллаһу ганһе идарә иткән чорда 70 яшендә вафат булган. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән 65 хәдис тапшырган.

# Фән

# Шәригать хөкемнәре

## Бисмилләһир-рахмәнир-рахим

## Мөстәхәб гамәлләр

Мөстәхәб шул гамәлдер: пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам ул гамәлләрне күп вакытларда кылмыштыр вә дәхи ул гамәлне кылган кешегә савап, бәрәкәт булачагын аңлатмыштыр. Мөстәхәб гамәлне кылган кеше саваплы булыр, кылмаган кеше гөнаһлы да булмас, Кыямәт көнендә шелтә дә тиеш булмас. Мөэмин-мөселман булган кешегә кылу сөекле булган мөстәхәб гамәлләрнең мәшһүрләре 122дер:

1. Мәдинә-и Мөнәүвәрәгә барып, пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең кабер шәрифе булган Раузаи Мутаһһәране зиярәт кылу (бу гамәл вәҗиб вә сөннәт дәрәҗәсендә тиешле мөстәхәбтер).

2. Нәфел намазлары уку.

3. Нәфел рузалары тоту.

4. Нәфел хаҗы кылу.

5. Гошер вә зәкяттән башка нәфел садакалары бирү.

6. Һәрвакыт мөмкин кадәр тәһарәт белән йөрү.

7. Намаз вакыты кергәнче, тәһарәт алып кую.

8. Тәкбирне күп әйтү, ягъни «Аллаһу әкбәр» дию.

9. Тәһлилне күп әйтү, ягъни «Ләә иләһә илләллаһ» дию.

10. Тәсбихне күп әйтү, ягъни «Сөбеханәллаһ» дию.

11. «Хәмдү»не күп әйтү, ягъни «Әлхәмдүлилләһ» дию.

12. Истигъфарны күп әйтү, ягъни «Әстәгъфируллаһ» дию.

13. Буш вакытта Коръән уку.

14. Салаватны күп әйтү, ягъни: «Аллаһуммә салли галә Мүхәммәдин вә галә әәли Мүхәммәдин вәсәллим», – дию.

15. Сәхабәләрнең вә дин голәмәсенең исемнәрен тәгъзыйм белән сөйләү, сәхабәләргә радыяллаһу ганһе, голәмәләргә һәм мәшәехларга «рахмәтуллаһи» димәк кеби.

16. Аш ашаганда, ач кешеләрне искә китереп, Аллаһы Тәгаләгә шөкер кылу.

17. Тәгам мәҗлесендә әдәп белән утыру.

18. Тәмам туеп җиткәнче, ашаудан туктау.

19. Табыннан тәгам алынганчы утырган җиреңдә утырып тору.

20. Табында тәгамне үз алдыңнан гына алып ашау.

21. Аш әзер булганда, намаз укыганчы, ашны ашау.

22. Тәгамне суытып ашау, эчемлек суны суытып эчү.

23. Йоннан вә кылдан эшләнгән киемнәр кию.

24. Киемнәрне кигәндә әүвәл уң кулга вә уң аякка кию.

25. Киемнәрне салганда әүвәл сул кулдан вә сул аяктан салу.

26. Яңа киемнәрне җомга көнне кию.

27. Киячәк киемне берәр кат селкеп кию.

28. Каралган киемнәрне юып кию.

29. Киемнәрне салгач, төреп кую.

30. Йорт-җирне чүп-чардан пакь тоту.

31. Аяк киемнәрне утырып кию.

32. Кич булгач, капка вә ишекләрне «Бисмилләһ»не әйтеп бикләү.

33. Тәрәзә пәрдәләрен төшерү.

34. Йокыга ятканчы, ястык вә юрганнарны берәр кат селкү.

35. Йокыга ятканчы, утларны сүндерү.

36. Йокыга ятканчы, кешеләргә тиешле васыятьләрне әйтү.

37. Йокыга ятканчы, догалар уку, тәүбә вә истигъфар кылу.

38. Йокыга ятканда, йөзеңне кыйблага каратып, аягыңны мәшрикъ тарафына сузып, кырын яту.

39. Ата-анасы белән, аз дигәндә, һәр атнада бер мәртәбә күрешеп, хәер-догаларын алу.

40. Үзеннән олы туганнарын ата-анасы кебек якын күрү.

41. Үзеннән кече туганнарын үз баласы кебек якын күрү.

42. Ата-анасының дусларын дус вә якын күрү.

43. Хатынга иренең кардәшләрен якын күрү.

44. Иргә хатынының кардәшләрен якын күрү.

45. Акыллы вә күркәм холыклы кешеләр белән юлдаш вә мәҗлестәш булу.

46. Якын кардәшләрең вә дусларың белән күрешкәндә, ачык йөзле булу.

47. Кул белән күрешкәндә, баш бармакларның төпләреннән тотышып күрешү.

48. Әүвәл мәртәбә күрешкән кешенең исемен вә нәселен сорашу.

49. Дус вә якын күргән кешеләреңә гаепләрен аулакта аңлату.

50. Дусларыңа вә үзеңнең хәләл хатыныңа күркәм күренү өчен яхшы киемнәр кию.

51. Көзгегә карап, килеш вә кыяфәтеңне төзәтү.

52. Хатынның иренә күркәм күренүе өчен зиннәтле киемнәр кию.

53. Киемнәргә хуш исле нәрсәләр сөртү.

54. Күзгә файдалы сөрмә тарту.

55. Ирләргә чәч вә сакалларына кызгылт кына сөртү.

56. Чәчне, сакал вә мыекларны тарап вә майлап, күркәм итеп тоту.

57. Чәчне китәрү яки кыскарту.

58. Йөзне даимән сөртеп вә юып, пакь тоту.

59. Тырнакларны, чәчләрне вә башка төкләрне җиргә күмеп кую.

60. Изге вә тәкъва кешеләрнең изгелекләрен яратып, дус күрү.

61. Изгелек юлында булган кешегә кулыннан килгән кадәр ярдәм кылу.

62. Мазлум, ягъни җәберләнгән кешеләрне җәбердән коткару өчен ярдәм кылу.

63. Сүзең сыйган кешеләрне вәгазь кылып, дингә йә дөньяга файдалы эшләргә димләү.

64. Үзеңә артык зарар килмәслек булганда, мөмкин кадәр һәркемгә ярдәм кылу.

65. Үзенең гаепләрен вә гөнаһларын кешедән яшерү.

66. Башка кешеләрнең гаепләрен дә кешегә белгертмәве, саклану.

67. Адашкан кешегә юл күрсәтү.

68. Кайгы ирешкән кешене шатландырып юату.

69.Үзеңә бер кайгы вә зарар ирешсә, тәрҗигъ кылу, ягъни «Иннә лилләәһи вә иннә иләйһи рааҗигуун» дию, ягъни: «Дөреслектә, без Аллаһы Тәгаләнеке вә һәркайсыбыз Аллаһы Тәгаләгә кайтачакбыз».

70. Нахак бәла белән бәлаләнгән кешегә хаклык белән шәфәгать кылу.

71. Гөнаһлы кешегә: «Аллаһы Тәгалә тәүфыйк бирсен», – диеп хәердога кылу.

72. Изге вә саваплы гамәлләрне кешегә белгертмичә, яшерен кылу.

73. Вәгазь мәҗлесендә утырып, вәгазь тыңлау.

74. Җеназа узганда аягүрә тору (мәет башка дин әһленнән булса да).

75. Мохтаҗ кешеләргә кирәкле булган йорт нәрсәләрен хаксыз биреп тору.

76. Мәчет-мәдрәсә вә мәктәп кебек дин өчен кирәкле булган нәрсәләргә акча сарыф кылу яки хезмәт итү.

77. Чишмә карату, юл төзәтү вә күпер суктыру кебек адәмнәргә файдалы булган эшләр өчен акча сарыф кылу яки хезмәт итү.

78. Адәмнәргә файдалы агачлар утырту.

79. Юлларда уңайсызлык итә торган ташларны алып, читкә ташлау.

80. Ир баласы туган кеше ике куй вә кыз баласы туган кеше бер куйны корбан чалып, итен фәкыйрьләргә бирү.

81. Туганына җиде көн тулганнан соң, баланың чәчен китәреп, чәче авырлыгы кадәр алтын йә көмеш садака бирү.

82. Җиденче көнендә балага бер яхшы исем кушу.

83. Кәсепкә иртә торып чыгу.

84. Сату-алу мөгамәләсен җиңеллек вә батырчылык илә кылу.

85. Хәләллеге шөбһәле малларны алудан саклану.

86. Сатучы сатканына үкенеп, кире кайтаруны үтенсә, файда алмыйча кайтарып бирү.

87. Бер нәрсәне сатканнан соң, алучысы үкенеп кайтармакчы булса, үзе саткан бәһа белән кире кайтарып алу.

88. Юлдашлар белән сәфәр чыкканда арадан берсен баш итеп сайлау.

89. Хайванга атланып йә арбага утырып барган кешегә тауга менгәндә аттан вә арбадан төшү.

90. Рамазанда сәфәрдә булган кешегә рузасын казага калдырмаска тырышу.

91. Сәфәрдән вә юлдан кайткан кешегә бала-чагасына вә якын кардәшләренә аш вә бүләкләр алып кайту.

92. Бурыч биреп торган кешегә бурычын мөмкин кадәр көтү.

93. Бурыч алган кешегә бурычын мөмкин кадәр тизрәк үтәргә тырышу.

94. Дәүләтнең чамасын кешедән яшерү.

95. Аллаһы Тәгалә биргән дәүләт вә нигъмәтнең чамасын әйтмичә, халыкка изһар кылу.

96. Зуррак малларны ике шаһит алдында сату һәм алу.

97. Кәефе вә табигате бозылган кешегә күп ашаудан тыелу.

98. Бурыч бирүче бурыч алучыдан бер кәгазьгә кул куйдырып, дәхи ике шаһит алдында яздырып алу.

99. Кеше явыз гамәл кылырлык җирләрдә йөрүдән саклану.

100. Үлгән кешене мактап сөйләү.

101. Коръән укып вә нәфел гыйбадәтләр кылып, мәетләргә мәгъфирәт өстәү.

102. Аш вә су савытларын каплап кую.

103. Һәр эштә сабырлык вә акрынлык белән эш кылу.

104. Һәрнәрсәгә вә һәр кешегә йомшаклык вә мәрхәмәтле күңелле булу.

105. Малының бар кадәренә сөенеп, канәгать булу.

106. Һәр эштә оятлы вә әдәпле булу.

107. Кунак сыйлаганда тәгамне вә ширбәтне олыларга бирү.

108. Үзе бик һавалы вә тәкәббер кешегә каршы тәкәбберлек күрсәтү.

109. Кияү булачак кеше алачак кызын ерактан карап күрү.

110. Әһле Исламга файдалы, шәригатькә муафыйк булган хөкемнәр чыгару.

111. Әһле Исламга файдалы булган хөкемнәрне кылу.

112. Нинди кавемнән булса да, кавеме арасында дәрәҗәсе олуг кешене хөрмәт вә тәкрим кылу (олылау, зурлау).

113. Бер эш башлаганда вә сәфәргә чыкканда, яхшы кешеләргә очрашу вә яхшы эшләргә тугры килүне яхшылыкка юрау.

114. Авыруны «Ин шә Аллаһ, терелерсең», дип шатландыру.

115. Ятим калган балаларга шәфкать вә мәрхәмәт кылу, аларны шатландыру.

116. Фәкыйрь тол хатыннарга мәрхәмәт вә ярдәм кылу.

117. Фәкыйрь карт-карчык вә зәгыйфь кешеләргә хәер-инсан кылу.

118. Хатынының кыз бала табуына бәрәкәт өмет итеп, сөенү.

119. Кыз балаларына шәфкать вә мәрхәмәтне артыграк кылу.

120. Яше унбишкә җитеп, балигъ булган көнне госел кылу.

121. Язу язарга вә язуны күркәм итеп язарга өйрәнү.

122. Һәрбер гыйбадәтне мөстәхәб булган гамәлләре белән үтәү. Мәсәлән: намазда 20 мөстәхәбнең һәркайсын үтәү.

## Мөбәх гамәлләр

Мөбәх шул гамәлдер ки, ул гамәлне кылу да, кылмау да дөрес вә хәләлдер. Мөбах гамәл бәндәнең үз ихтыярындадыр. Теләсә кылыр, теләмәсә кылмас. Аны кылган кеше дә, кылмаган кеше дә саваплы да, гөнаһлы да булмас.

Мөэмин-мөселман булган кешегә мөбәх вә хәләл булган эшләрнең хисабы юктыр. Харам вә мәкруһ булмаган эшләрнең һәркайсы мөбәхтер. Мәсәлән: утыру, тору, йөрү, яту, йоклау, хәләл тәгамнәрне ашау-эчү, зарарсыз сүзләрне сөйләү, һәрбер гөнаһсыз вә зарарсыз эшләрне кылу кебек шәригатьтә боерылмаган һәм тыелмаган эшләрнең һәркайсы мөбәхтер.

Шуларның 52 сен санап китик:

1. Хәләл тәгамнәрне туйганчы ашау, туйганнан артыгы харамдыр.

2. Хәләл эчемлекләрне туйганчы эчү.

3. Имансыз кешеләр пешергән пакь ашларны ашау.

4. Сабак укыту илә шөгыльләнгән кеше, укытканы өчен хак алу.

5. Аш сеңдерү өчен, исертми торган суларны эчү.

6. Исертми торган, йөзем суыннан ясалган серкәне эчү.

7. Тоз күленә төшеп, тозга әйләнгән үләксәдән булган тозны кабу.

8. Ачлыктан һәлак булыр дәрәҗәгә килгәндә, кеше тәгамен алып, бераз ашау (гәрчә тәгам иясенең үзеннән сорамаса да). Ләкин сорау мөмкин булганда, сорамыйча алып ашау дөрес түгел.

9. Киек хайваннарның ите, йоны, тиресе йә сөяге белән файдалану өчен үтерү-аулау.

10. Хайваннарны печтерү.

11. Хатын-кызга ефәк киемнәр кию мөбәхтер.

12. Ефәк комач илә тышланган мендәр, ястык вә киез кебек нәрсәләрне куллану.

13. Ирләргә арка өлеше җеп булып, буе ефәк булган киемнәрне кию.

14. Көмешле җиренә кул тидермичә, көмеш бизәкле савытларны куллану.

15. Хатыннарга алтын вә көмеш зиннәтләр белән бизәнү.

16. Савытларны алтын вә көмеш, вә ак кургаш илә ялтырату.

17. Ирләргә көмеш билбау кию.

18. Зарарсыз сүзләрне сөйләү.

19. Гыйбрәтле вә вәгазьле көйле шигырьләр уку.

20. Гыйбрәтле вә вәгазьле шигырьләрне тыңлау.

21. Үзенә йә бер кешегә золым кылдырмас өчен, ялган сүз сөйләү.

22. Дошманлашкан кешеләрне килештерү вә дуслаштыру өчен, ялган сүз сөйләү.

23. Сугышта дошман гаскәрен алдау өчен, ялган сөйләү. Ошбу өч урыннан башка урыннарда ялган сөйләү харамдыр.

24. Харам кылучы кешедән зарланып, гаеп кылу.

25. Зарары тия торган кешедән саклану өчен, аның усаллыкларын кешегә сөйләп, гаеп кылу.

26. Кем икәнлеген һич аңлатмыйча, бер кешенең гаепләрен сөйләү.

27. Фәлән авыл кешеләре йә фәлән кавем диеп, бер җәмәгатьнең гаепләрен сөйләү.

28. Усаллык илә ачу китергән кешене хаксыз, оятсыз, ахмак вә надан дип әйтү.

29. Хак сүзләр илә аз-маз уен-көлкеле сүзләр сөйләү.

30. Яхшы кешеләргә кызыгып, үзе дә шул яхшы кешеләр кебек булырга тырышу.

31. Зарар булганда, тешләрен көмеш, алтын йә башка нәрсәләр илә ямату.

32. Зарар булганда корсактагы баланы ярып алу.

33. Артык бәһа бирсә, шуңа сату.

34. Йорт-җирләр, агачлар кебек җансыз нәрсәләрнең сурәтен ясау.

35. Дәва кылу өчен, гозер сәбәпле, гаурәт җирләргә карау.

36. Үз хатыныңның йә ireңнең җәмигъ әгъзасына күз төшерү.

37. Мөхтәрәм кардәш булган хатыннарның муеннарына вә иякләренә, вә балтырларына карау.

38. Нәмәхрәм (мәхрәм булмаган) булган ят хатыннарның йөзләренә кызыгудан башка күз төшерү.

39. Ирләр тәннәренең кендектән югары вә тездән түбән булган җирләренә күз төшерү.

40. Гаделлек кылырга кулыннан килеп, дәүләтле вә куәтле булган кешегә мөһим зарур сәбәпле, ике, өч йә дүрт хатын алу (дүрттән артык харамдыр). Әмма гаделлек кулыннан килмәслек вә яхшы тәрбия кыла алмаслык кешегә ике хатын алу да дөрес түгел.

41. Шәригатьчә, сәбәп булганда, хатынын аеру.

42. Хатын-кызга йорт эчендәге мунчага керү.

43. Рамазан аенда мосафир булган кеше, рузасын тотмыйча казага калдыру.

44. Мосафир кеше читегенә өч тәүлек тулганчы мәсих кылу.

45. Ите хәләл булган хайваннарның итләрен, сөтләрен вә йомыркаларын ашау.

46. Исертми торган вә тәнгә агу, вә зарар ирештерми торган, һәрбер ашлык вә орлык вә үләннәрне ашау.

47. Исертми торган вә тәнгә зарар бирми торган су вә шәрабләрне эчү.

48. Үз игенлегендә үскән ашлыкны бәһасе күтәрелгәнче сатмый тору.

49. Алачак бурыч өчен, китереп түләгәнче бер нәрсә алып тору.

50. Ачлыктан һәлак булыр дәрәҗәгә килгәндә, харам тәгамнәрне ашау.

*Әхмәдһади Максудиның «Шәригать хөкемнәре» китабыннан*

# Харамнар

Ислам дине буенча бу дөнья – адәм баласы өчен мәдрәсә, сынау урыны. Аның нәтиҗәләренә карап кеше йә җәннәткә керәчәк, йә җәһәннәм газабына дучар булачак. Бәндәләрне туры юлдан адаштыру өчен Иблис Аллаһыдан бу дөньяда Кыяматкә чаклы калдыруны сораган.

**«Чынлап та, шәйтан ул – сезнең дошманыгыз һәм сез аны дошман итеп күрегез. Ул үзенә ияргәннәрне ялкынлы ут эчендә яшәргә чакыра».**

«Мәләикә / Фәрештәләр» 35:6

**«Ул (Иблис) әйтте: «Йә Рабби! Мине саташтырганың өчен мин аларга җирдәгесен бизәп күрсәтермен һәм, әлбәттә, аларны аздырырмын. Синең сайланган колларыңнан башкаларны».**

«Хиҗер»,15:39-40

Шәйтан кеше кылган гамәлләрне бизи, һәм кеше гөнаһлы, харам гамәлләрне хәерле итеп күрә. Хәләл ризык булганда да, адәм баласы харамны куллана.

Ризык сүзе «бирү» дигән мәгънәне аңлата, ягъни Аллаһы Тәгаләнең җан ияләренә биргән нәрсәләре. Ризык хәләл дә, харам да булырга мөмкин.

Ризык Аллаһы тарафыннан терек җанга бүләк ителә торган (бирелә торган) нәрсә, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

**«Җирдәге һәр җан иясенең ризыгы Аллаһы кулында».**

«Һуд», 11:6

Ризыкны бирүче Аллаһы Тәгалә ялгыз бер Үзедер. Коръән Кәримнең ризык турындагы аятьләренә карасак, аларның бөтенесе дә ризык ялгыз Аллаһы Тәгаләнең кулында икәнлеген, Аллаһы Тәгалә теләгән кешесенә күп һәм теләгән кешесенә аз ризык бирүен раслый:

**«Хакыйкатьтә, Аллаһы – ризык бирүче».**

«Зарият / Таратучы», 51:58

**«Аллаһы сезне ризыкландырган нәрсәләрдән ашагыз».**

«Әнгам / Терлек», 6:142

**«Ризыкны Аллаһыдан сорагыз».**

«Гәнкәбут / Үрмәкүч», 29:17

**«Шиксез, Аллаһы теләгәнен хисапсыз ризыкландыра».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:37

**«Аллаһы сезне барлыкка китерде, соңыннан сезгә ризык бирде».**

«Әр-Рум», 30:40

Бу аятьләр ризыкның фәкать Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгәнлегенә һәм аның Аллаһы Тәгаләнең кулында булуына катгый дәлил була, шуңа күрә ризыкның килүе, аның аз яисә күп булуы кешенең ихтыярында түгел, киресенчә, ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешегә мәҗбүри билгеләнгән нәрсә.

Харам ул ризык кына түгел, ә гамәл дә булырга мөмкин. Ул гамәлләр Аллаһының Сүзе булган Коръәннән аятьләр һәм Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрдә китерелгән катгый дәлилләре белән тыелган. Ул катгый дәлилләргә каршы килә торган бернинди дәлил булмас.

Харамны калдырган, ягъни, харам эш-гамәлләрне кылмаган кеше бик зур әҗерле була, ә инде харамны кылган кешегә, Аллаһы Тәгалә гафу итмәсә, җәһәннәм газабы булачак.

Харамны хәләлгә санаган кешене барлык галимнәр дә динсезгә саныйлар. Мисал өчен, бер кеше: «Аракы эчү – хәләл, дуңгыз ите ашау – хәләл, чит хатыннар белән мавыгу, зина кылу – хәләл», – дип әйтә икән, ул кеше кяфер була.

Имам Бохари һәм Имам Мөслимнең «Сахих хәдисләр» җыентыкларында түбәндәге хәдис тә китерелә: «Әбү Һөрайрадан риваять кылына: «Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Һәлакәткә илтә торган җиде әйбердән сакланыгыз!» – дип әйтте. Сәхабәләр: «Йә Расүлуллаһ! Бу нинди әйберләр?» – дип сорадылар. Ул галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек кылу, сихер, кеше үтерү, риба, ятим малын ашау, яу кырыннан качу, иманлы пакь хатыннарны зинада гаепләү».

### 1. Аллаһыга ширек кылу

Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә ширек кату – имансызлыкка китерә торган иң зур харам гамәл. Бу наданлыктан килә, чөнки гыйлемле кеше Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләне күркәм сыйфатлары белән танып, һәркайсын ачык дәлилләр белән белергә тырыша, берлегенә һәм барлыгына чын күңеленнән ышана.

> **«Дөреслектә, Аллаһы Үзенә тиңдәшлек кылуны (ширек кылуны) кичерми, ә аңардан башка гөнаһларны теләгән кешесенә кичерә».**

«Нисә / Хатыннар», 4:48

### 2. Фарыз, вәҗибләрне кылмау

Намаз укымау, руза тотмау, зәкят бирмәү, корбан чалмау, гошер бирмәү – харам.

### 3. Наданлык (гыйлемсезлек)

Шәригать буенча белү вәҗиб булган, ягъни динебез, шәригатебез буенча белергә тиеш булган эш-гамәлләрне белмәү, белергә тырыш-

мау яисә гыйлем ияләрен яратмау, белмәгән нәрсәләрне белүчеләрдән (галимнәрдән, укымышлы дин әһелләреннән) сорамау – болар да харам.

Наданлыкның капма-каршысы – гыйлемле булу. Гыйлем алу фарыз гамәл.

Без барыбыз да ләхеткәчә, ягъни үлгәнче, гыйлем алырга тиешбез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: «Гыйлем алу – һәр мөселманга фарыз», «Бишектән алып ләхеткәчә белем алыгыз!» – дигән хәдисләре шуңа басым ясый. Хәерле гыйлем алып, аны дөрес кулланса҃ң, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә бу дөньяда да, Ахирәттә дә югары дәрәҗәләргә ирештерә, ин шә Аллаһ. Наданлык, белергә теләмәү – фарызны калдыру булып санала. Фарызны калдыру – харам гамәл.

## 4. Ата-ананы олыламау

Ата-ананы рәнҗетү, аларны тыңламау, каршы булу (кирәк кул белән, кирәк яман сүз белән яисә чытык йөз белән) – болар барысы да шәригатьтә харам һәм, шулай ук, дөнья вә Ахирәттә хур булуга сәбәп. Чөнки Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләгә карата гөнаһлы булганда, Аллаһы Тәгалә Үзе гафу кылуы ихтимал. Әмма ата белән ананы рәнҗетү алай түгел, аның җәзасы бу фани дөньяда яшәгәндә үк килә башлый. Ә Ахирәттә олы җәза һәм бик зур бәхетсезлек булачагы Коръән белән дәлилләнгән.

**«Аллаһы хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһыга гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф»та димә, вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:23

Ибраһим галәйһиссәлам әтисе хәтта потлар ясаучы һәм аларга табынучы зат булса да, әтисенә катылык күрсәтмәде, ата хакын олылады.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә пәйгамбәр булып сайланган затның хәтта потка табынучы атасына да йомшак сүз белән килгәнен, аннан йөз чөермәгәнен күрсәтә. Шуңа да кичә генә намазга өйрәнеп, бүген әти-әниләрен дин тотмауда гаепләүче яшьләр дөрес эшләмәгәнлекләрен аңласыннар иде.

## 5. Остазыңа карата ихтирамсызлык

Остазыңны рәнҗетү дә ата белән ананы рәнҗетү кебек, бик зур гөнаһ һәм харам эш, кешенең чын бәхетсезлегенә һәм абруйсыз калуына, дәрәҗәсе төшүгә сәбәп. Безне заләләттән, ягъни наданлык караңгылыгыннан яктылыкка алып чыгучы, дин һәм иманга өйрәтүче, имансыз булып мәңгелеккә җәһәннәмдә калудан котылуга бер сәбәпче булган, һәм дөньяда вакытта рәхәткә, сәгадәткә ирешүебезгә сәбәпче булган остазыбызны ачулану, аны ихтирам итмәү харам гамәл.

Кеше үз тормышында бик күп гамәлләр башкара, хәерлеләрен дә, хәерсезләрен дә, хәләлләрен дә, харамнарын да. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә безгә тәүбә ишекләрен ачык итеп кылган, гөнаһлардан арынырга мөмкинлек биргән. Кеше зәгыйфь, гөнаһ кылучан. Һәрвакытта тәүбәгә ашкынып, башка бу харәм гамәлне кылмаска омтылып яшәргә кирәк. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән беркайчан да өметне өзәргә ярамый.

> **«Дөреслектә, Аллаһы Үзенә тиңдәшлек кылуны (ширек кылуны) кичерми, ә аңардан башка гөнаһларны теләгән кешесенә кичерә».**

«Нисә / Хатыннар», 4:48

*Наил хәзрәт Әбелханов,*

*Норлат районы имам-мөхтәсибе*

# Тарих

# Ислам яңарышы чорының маяклары

Якынча IX-XV гасырларның аралыгын Исламның алтын чоры (Ислам яңарышы) дип атыйлар. Бу чорларда гарәп хәлифәлеге үзенең территориясе буенча гына түгел, ә мәдәният, сәнгать һәм фәннең төрле өлкәләрендә зур ачышлар ясаган галимнәрнең күплеге белән дә иң эре дәүләтләрнең берсе булган. Мөселман галимнәре фәнгә, икътисад, әдәбият, фәлсәфә, авыл хуҗалыгы, диңгез сәнәгате үсешенә үзләреннән зур өлеш кертkәннәр. Бу чорларда мәчетләр белән янәшә мәдрәсәләр дә ачылган, аларда дини белем белән бергә дөньяви гыйлемнәр дә алганнар. Тора-бара бу мәдрәсәләр уку-укыту үзәкләре һәм университетлар булып үсеп киткәннәр. Ир-атлар белән беррәттән, аларда хатын-кызлар да белем алган. Күп гасырлар элек үз эзләрен калдырган мөселман галимнәренең исемнәрен хәзерге заманда да хәтерлиләр, хезмәтләренә мөрәҗәгать итәләр. Аларның кайберләрен санап үтик…

**Әл-Кинди Йосыф бине Исхак (якынча 803 – 872 еллар)** – гарәп фәлсәфәчесе, астроном, математик һәм табиб; «гарәпләрнең фәлсәфәчесе» дигән кушаматны алган. Ул Аристотельнең язмаларына шәрехләр (аңлатмалар) («Органон» һ.б.) һәм метафизикага караган хезмәтләр язган. Аның күренекле хезмәтләре: «Билгеләмәләр һәм тасвирламалар турында», «Беренче фәлсәфә турында», «Акыл турында», «Йокы һәм төш күрү турында», «Сагыштан ничек сакланырга».

**Гияс Әд-Дин Җәмшид бине Мәсүд Әл-Каши (1380 елда Кашан (Иран) шәһәрендә туган – 1429 нче елның 22 июнендә вафат булган)** – XV гасырның күренекле математигы һәм астрономы, Сәмәрканд обсерваториясенең җитәкчесе. Беренчеләрдән булып унарлы вакланма теориясе турында язып чыга. Асторономия өлкәсендә «Хакан зиҗе» (1414)

төзи. «Күкләр баскычы» (1407) дип аталган трактатында Ай һәм Кояшка кадәр булган аралык, аларның күләмнәре, планеталарга кадәр булган аралык турында яза. «Бакчаларның хозурлыгы» дип аталган китабында йолдызларның киңлеген һәм ераклыгын, аларның Җиргә кадәр булган аралыгын үлчи торган үзе ясаган җайланма турында яза. Аның шулай ук «Астрономия турында трактат», «Меркурий турындагы тәкъдимнәрне хәл итү хакында трактат» кебек хезмәтләре бар. Математика өлкәсенә караган «Арифметика ачкычы» трактатында ул унарлы вакланма теориясе турында яза, аның төп кагыйдәләрен китерә.

**Әбү Бәкер бине Мөхәммәд бине Әл-Хөсәйн Әл-Караҗи (953 – 1029)** – фарсы математигы. Тумышы белән Караҗ шәһәреннән. Ул математикага караган бик күп хезмәтләр язган. Шуларның кайберләре: «Математика буенча җитеш китап», «Алгебра һәм әл-мукабәлә турында китап», «Гыйлемнәр җыелмасы турында китап» һ.б. Аның хезмәтләре көнчыгыш математика тарихында бик тә әһәмиятле булып, Аурупа галимнәренә дә нык этәргеч ясаган.

**Ибне Әл-Хәйтамны (якынча 965 нче елда туган)** «оптиканың атасы», шулай ук фәнни ысулны нигезләүче дип атыйлар. Кече яшьтән үк фәнгә тартылган, шулай ук хакыйкатьне аңларга омтылган иманлы мөселман булган. XI гасырның башында ул Каһирәгә күченгән һәм үзенең иң күренекле хезмәтен дә шушында язган. Ул яктылык өлкәсендә зур яңалык ачкан. Яктылыкның бары тик туры сызык буенча гына таралуын исбатлаган, көзгенең ничек эшләү принцибын аңлаткан һәм яктылык нурларының төрле тирәлек (мәсәлән, су) аша узганда сынарга мөмкин булу фикерен яклап чыккан. Аның күп елларга сузылган фәнни эшчәнлеге «Оптика китабы» дип аталган хезмәтендә яктыртылган. Әлеге хезмәтендә автор сүзләргә генә ышанырга түгел, ә практикада тикшереп

карарга кирәклеген ассызыклый. «Галимнәрнең хезмәтләрен тикшерү белән шөгыльләнүче һәм хакыйкатьне танып белүне үз максаты итеп куйган кешенең бурычы – бөтен укыганнарны да кабул итмәү һәм …аның дөреслеген тулысынча инкяр итү. Шулай ук, критик анализ ясаган вакытта үзенең ялгыш фикерләренә бирелеп китмәсен өчен ул барысын да шик астына куярга тиеш», – дип язган Ибне Әл-Хәйтам. Шул рәвешле аның тарафыннан фәнни ысулның нигезләре салынган.

**Әбү Рәйхан Мөхәммәд бине Әхмәд Әл-Бируни (973 – 1048)** – күренекле үзбәк энциклопедист галиме. Үзенең күренекле «Медицинада фармакогнозия» дип аталган хезмәтендә ул кече яшьтән үк белемгә хирыс булуы турында әйткән һәм үз тормышыннан булган вакыйгаларны да язган. Аңа 7 яшь булган чагында, алардан ерак түгел бер грек кешесе килеп урнашкан. Грек телендә атамаларын белер һәм дә аларны язып алыр өчен Бируни әлеге кешегә төрле әйберләр, үсемлекләр, киемнәр илткән. Инде 20 яшендә үк Бируни «Борынгы халыкларның хронологиясе» дип аталган беренче хезмәтен язган. Әлеге хезмәттә төрле халыклар тарафыннан кулланылган календарьлар системасы тупланган. Бируни киңкырлы эшчәнлек алып барган. Аның 45кә якын хезмәте билгеле һәм алар төрле өлкәләргә караган: медицина, фармакология, фармакогнозия, тарих, география, математика, астрономия, филология, минералогия, геодезия.

Ул Җирнең радиусын санап чыгарган; Кояш һәм Ай тотылу күренешен һәм шул вакытта Айның төсен үзгәртүен тасвирлап язган. Бируни беренчеләрдән булып глобус ясаган.

Аның «Медицинада фармакогнозия» («Китаб әс-Сәйдәнә фит-тыйб») дип аталган хезмәте бүгенге көндә дә кулланылышта. Әлеге хезмәтендә галим 880гә якын үсемлеккә тулы аңлатма биргән, аларның дөрес атамаларын язган һәм терминологияне тәртипкә салган. Һәрбер үсемлеккә тулы аңлатма белән беррәттән рәсемнәре дә бирелгән. Шулай ук әлеге

хезмәттә дару үләннәре турында бай мәгълүмат бирелгән, аларның таралу җирлекләре дә күрсәтелгән. Бируни дүрт мең ярымга якын үсемлекләрнең гарәп, грек, сирия, һинд, фарсы, төрек, хәрәзми телләрендәге атамаларын бирә.

**Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Зәкәрия Әр-Рази (якынча 865 – 925 еллар)** – фарсы галиме, энциклопедист, табиб, алхимик һәм фәлсәфәче. Аның төп хезмәтләре медицинага караган – «Әл-хави» («Медицина буенча барысын да колачлаган китап») һәм «Мансурга багышланган медицина китабы» – 10 томлык гарәп телендәге медицина энциклопедияләре. Соңрак әлеге китаплар латин теленә тәрҗемә ителәләр һәм йөз еллар дәвамында табибларга кулланма буларак хезмәт итәләр. «Җил чәчәге һәм кызамык турында» дип аталган китабында Рази бу авыруларның тулы тасвирламасын бирә һәм кабат алар белән зарарлану мөмкин түгеллеген искәртә. Рази беренчеләрдән булып хастаның авыру тарихын язуны кулланылышка кертә. Шулай ук беренчеләрдән булып яраларны бәйләгәндә мамык һәм теккән вакытта кетгут куллана башлый. Ул хастаханәләр төзү һәм аларны төзүгә тиешле урыннар билгеләү буенча да үз нәсыйхәтләрен бирә.

**Олугбәк Мөхәммәд бине Шәхрух (1393 – 1449)** – татар астрономы, бөек илбасар Тимерланның оныгы. Кече яшьтән үк математика һәм астрономия фәннәрен яраткан. Сәмәркандтагы астрономия обсерваториясендә читтән чакырылган астрономнар белән бергәлектә хезмәт иткән. Олугбәк һәм аның тарафдарларының төп хезмәтләре – планеталарның астрономик таблицалары. Шулай ук тагын бер мөһим хезмәте – аның тарафыннан төзелгән йолдызлар каталогы. 1665 нче елда Томас Гайд әлеге хезмәтне тәрҗемә итеп, Оксфорд шәһәрендә бастырган. Олугбәк гарәп телендә дә берничә хезмәт язган. Соңрак алар фарсы теленә тәрҗемә ителгәннәр.

**Әбү Муса Җәбир бине Хәйян (якынча 721 – 815 еллар)**. Аның язган хезмәтләре арасында иң күренеклесе – «Җитмеш китабы». Әлеге китап 70 бүлектән торган энциклопедияне хәтерләтә һәм анда дин, сәясәт, фәнгә караган мәсьәләләр яктыртылган. Китапның соңгы бүлекләрендә автор металл һәм минераллар турында мәгълүматлар биргән. Төрле химик күренешләрне (эрү, кристаллашу һ.б.) тасвирлап язган. Серкәнең (уксус), азот эремәсенең барлыкка килүен ачыклаган. Аның трактатлары гарәп һәм шулай ук көнбатыш алхимия үсешендә дә зур этәргеч ясыйлар.

**Әбү Әл-Касыйм Хәләф бине Әл-Габбас Әл-Зәхрәви (936 – 1013 еллар).** Чыгышы белән Әндүлүстән. Әндүлүс хәлифәсе Хәкәм II нең сарай табибы. Ул колакларны карау өчен махсус җайланма уйлап тапкан. Гомумән, медицина өлкәсендә 200гә якын хирургия җайланмаларын тәкъдим иткән. Шулай ук аның медицинага багышланган 30 томлы сурәтле практик кулланмасын да («Үзе мондыйны төзи алмаган табиб өчен кулланма») атап үтми мөмкин түгел. Әлеге хезмәттә медицинаның төрле өлкәләре, шул исәптән, хирургия, ортопедия, офтальмология, фармакология, диетология яктыртылган.

**Әбү Габдулла (яки Әбү Җәгъфәр) Мөхәммәд бине Муса Әл-Хәрәзми (783 – 850)** – алгебраның атасы. Үзбәкстанда туган. Багдадтагы гарәп фәненең үзәге булган «Хикмәт йорты»нда эшләгән. Ул «Һинд арифметикасы буенча китап» (яки «Һинд исәбе буенча китап»), «Астрономик таблицалар», «Җир сурәте китабы», «Кояш сәгатьләре хакында китап», «Тарих китабы» һ.б. бик күп хезмәтләр язган. 825 нче елда язылган «Һинд арифметикасы буенча китап» (яки «Һинд исәбе буенча китап») хезмәтендә ул Һиндстанда уйлап чыгарылган позицион унарлы исәпләү системасына беренче мәртәбә аңлатма биргән. Кызганычка каршы, китапның фарсыча беренче язылган нөсхәсе сакланып калмаган. Әл-Хәрәзми яңа си-

стемада исәпләү кагыйдәләрен формалаштырган, һәм, мөгаен, беренче мәртәбә санда төшерелеп калдырылган позицияне билгеләү өчен 0 цифрасын кулланган. Аның һиндча атамасын гарәпләр (الصفر) «as-sifr» яки фәкать (صفر ) «sifr» дип тәрҗемә иткәннәр, моннан «цифра» һәм «шифр» кебек сүзләр килеп чыккан. Шул ук вакытлар тирәсендә һинд цифрларын башка гарәп галимнәре дә куллана башлаганнар. XII гасырның беренче яртысында Әл-Хәрәзминең китабы латин тәрҗемәсендә Европага үтеп кергән. Безнең вакытка кадәр исеме сакланып калмаган тәрҗемәче аңа «Algoritmi de numero Indorum» («Һинд исәбе турында алгоритмнар») атамасын биргән. Китапның гарәпчә атамасы «Китаб әл-җәбр вәл-мукабәлә» («Кушу һәм алу турында китап») булган. Китапның элекке атамасыннан алгебра сүзе килеп чыккан (алгебра – әл-җәбр – кушу).

Шулай итеп, Урта Азия галименең латинлаштырылган исеме китап атамасына куелганын күрәбез, чөнки Әл-Хәрәзминең исеме латин теленә тәрҗемә ителгәндә «Әл-Гаритми» буларак яңгыраган һәм шул рәвешле, унарлы арифметика системасын «алгоритм» дип атаганнар. Хәзер «алгоритм» сүзенең Европа телләренә нәкъ менә бу хезмәттән кергәне күренә.

Әл-Хәрәзминең «Җир сурәте китабы» хезмәте география үсешенә зур этәргеч ясаган. Ул төзегән тригонометрик һәм астрономик таблицалар Көнчыгышта һәм дә Көнбатыш Европада үткәрелгән төрле фәнни тикшеренүләрнең нигезендә торган.

Астрономиягә багышланган хезмәтләреннән аның «Кояш сәгатьләре хакында китап» һәм «Астролябия ярдәмендә хәрәкәт турында китап» дип аталганнары билгеле. Соңгысының 41-42 бүлекләрендә намаз вакытларын билгеләү өчен кулланылган махсус циркуль турында язылган.

*Islam-today сайтыннан тәрҗемә кылынды*

# Әл-Әкъса мәчете тарихы

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөселманнарга биш вакыт намазда имам булгач, алар әле намазларын Кодес (Иерусалим) шәһәренә таба карап укыйлар иде. Әлеге шәһәр Давыд, Сөләйман, Гайсә галәйһиссәламнәр белән дә күзаллана. Ә сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән Мәккә шәһәреннән Кодес шәһәренә гадәти булмаган төнге сәяхәт кылып һәм андагы Әл-Әкъса мәчетендә барлык пәйгамбәрләргә дә имам булып намаз укыгач, соңыннан Аллаһыдан әмер булып, Җәбраил фәрештә белән күккә күтәрелгәч, әлеге шәһәрнең әһәмияте тагын да арткан.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам яшәгән чорларда һәм аның вафатыннан соң берничә еллар Кодес шәһәре мөселманнар өчен буй җитмәслек бер нәрсә кебек булган. Ләкин Гыйракта, аннан 630 нчы елда Сириядә хакимияткә акрынлап мөселманнар килеп, Кодес мөселман шәһәренә, ә Әл-Әкъса мәчете исә мөселман мәмләкәтендә иң әһәмиятле җирләрнең берсенә әверелгән.

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кадәр һәм аннан соң

637 нче елда Кодес шәһәре яулап алынгач, Гомәр бине Әл-Хаттаб хәлифәлек иткән дәвердә мөселманнар Кодес шәһәренең дини дәрәҗәсен кайтарырга телиләр. Кодес шәһәрендәге борынгы гыйбадәтханә бик күп кенә үзгәрешләр кичергән. Безнең эраның 70 нче елында, Фәләстыйнда яһүдиләрнең баш күтәрүләреннән соң румнар әлеге гыйбадәтханәне җимергәннәр. Яһүдиләргә шәһәрдә төпләнергә рөхсәт ителмәгән.

Берничә йөз еллар дәвамында гыйбадәтханә торган урын ташландык хәлдә яткан. Румнар аны чүплек буларак кулланганнар. Гомәр бине Хаттаб шәһәргә кереп, бабаларының гыйбадәт кылган урыннарын карарга теләп, ул урыннарның бик әшәке икәнлеген күрә һәм мәчет буларак кулланып булмаганын аңлый.

Ул бу җирне чистартырга һәм шул урында мәчет салдырырга карар кыла. Гади мөселманнар белән беррәттән, үзе дә җыештыру, чистарту эшләрендә катнаша. Уртак көчләр белән якынча өч меңгә якын кешене сыйдыра алырлык Харам-е Шәриф мәчете төзелә. Ул зур агач корылманы хәтерләткән.

## Харам-е Шәриф

Берничә дистә еллар дәвамында төзелгән әлеге гади корылма төп гыйбадәт кыла торган бина булып торган. Ләкин 690 нчы елда өмәвиләр нәселеннән булган Габделмәлик хәлифә Әл-Әкъса мәчетен күпкә зуррак һәм ныграк итеп төзетергә карар кылган. Габделмәлик хәлифәнең архитектура корылмасы төньякка якынча 200 метр тирәсе булган җирдә торгызылган.

Риваятьләрдән күренгәнчә, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам күккә күтәрелгән кыя өстендә Габделмәлик хәлифә зиннәтле Кыя гөмбәзе төзетә. Кыя гөмбәзе Әл-Әкъса мәчете архитектура комплексының бер өлеше булып саналса да, аерым гыйбадәт кылу урыны булып саналмаган. Гөмбәзне төзегәндә өмәвиләр византиялеләрдән отып алган архитектура традицияләрен һәм мозаиканы кулланганнар. Шул рәвешле, әлеге гөмбәз шул еллар мөселман архитектурасының ачык мисалы булып тора.

Өмәвиләр хакимияттән төшерелгәннән соң, Кодес шәһәре габбасиләр кулына күчкән. Габбасиләр хәлифәлегенең башкаласы Багдад шәһәре булганлыктан, хәлифәләр Кодес шәһәренә артык игътибар

бирмәгәннәр. Харам-е Шәрифкә дә өмәвиләр вакытындагы игътибар һәм финанс яктан ярдәм булмаган. Ләкин хәлифәләр тарафыннан төрле кимсетелүләр булса да, Кодес шәһәре хаҗ кылу урыны булып кала биргән. Әл-Әкъса мәчете исә күп санлы җир тетрәүләр булуга карамастан, 600 һәм 900 нче еллар аралыгында шәһәр дини тормышының үзәге булып торган.

## Фатыймилар идарә иткән вакыттагы таркалыш

X гасырның азагыннан алып Кодес шәһәре һәм Харам-е Шәриф авыр еллар кичергәннәр. 970 нче елда фатыймилар габбасиләрне җиңеп, Кодес шәһәрен үзләренең кул астына алалар.

Мөселманнар Кодес шәһәре белән идарә итә башлагач ук, Харам-е Шәриф һәм Әл-Әкъса мәчете ислам гыйлеме үзәкләре булып торганнар. Студентларга гарәп грамматикасы, ислам хокукы һәм дини тәгълимат буенча белемнәр бирү өчен галимнәр һәрдаим мәчеттә мәктәпләр оештырганнар.

1030 нчы елда көчле җир тетрәү булып узганнан соң, Әл-Әкъса мәчете фатыймилар тарафыннан төзекләндерелә. Мәчетнең хәзерге вакыттагы күренеше фатыймилар тарафыннан ясалган төзекләндерүдән соң бик үк үзгәртелмәгән.

1073 елда Кодес шәһәре төрек-сәлҗуклар тарафыннан яулап алына. Ислам күзлегеннән караганда, Әл-Әкъса ышанычлы сөнни дәүләт кулларына кайтарыла, шул рәвешле шәһәргә дә ислам гыйлеме кире кайтарыла. Харам-е Шәрифтә янәдән ислам хокукы мәктәпләре (Шәфигый һәм Хәнәфи) үз эшчәнлекләрен дәвам итәләр.

Шәһәргә мөселман дөньясының төрле җирләреннән укырга һәм дә укытырга галимнәр кайта. 1095 нче елда шәһәргә Әбү Хәмид Әл-Газали да килеп урнаша. Гомеренең күп өлешен ялгызлыкта калып, Әл-Әкъса, Кыя

гөмбәзендә гыйбадәттә үткәрә. Шулай ук бу елларда ул үзенең күренекле «Дини фәннәрнең яңарышы» хезмәтен язган. Әлеге хезмәт гакыйдә, хокук һ.б. темалар буенча ислам гыйлемен системалаштырган.

*Islam-today сайтыннан тәрҗемә кылынды*

# Мирас

# Әҗем мәчете тарихыннан

Әҗем мәчете (элек Алтынчы җәмигъ, Завод мәчете) – Казан мәчетләренең «йөзек кашы» – Фәткуллин урамы, 15 нче йорт адресы белән урнашкан. Бүгенге көндә бу корылма шәһәрнең бер күрке, казанлыларның тарихи горурлыгы булып тора. Әҗем мәчете архитектура буенча Казанның иң матур гыйбадәтханәләрнең берсе булып санала.

## Мәчет исеме

Казан ханы Мөхәммәд Әминнең (1518 елда вафат) икенче исеме яки кушаматы Әҗем (Иҗем) булуы мәгълүм. Ризаэтдин Фәхретдин шулай дип яза да: «Әҗем хан димәклә иде». Бу хан Казан тәхетенә шәһәрне 1487 елда алган Иван III тарафыннан утыртыла.

Мөхәммәд Әмин Казан тәхетендә 26 ел утыра, дәүләтне шактый ныгыта. Кайбер чыганаклардан күренгәнчә, үзеннән соң, кыз балалары булса да, ир балалары калмый. Шулай да «Әҗем» исем-кушаматы йөрткән ханның ераграк буыннарыннан булса да ир токымы калуы бик ихтимал. Бәлки нәкъ менә шулардан, ә бәлки кызларыннан да, мәшһүр татар эшлеклеләре һәм сәүдәгәрләре Әҗемовлар нәселе таралгандыр.

Рафаэль Мостафин «Кабан күле серләре» дигән китабында язган Әҗемов фамилияле карт, ихтимал, шул мәшһүр токымның соңгы варисларыннан булгандыр. Ул Казан ханлыгы хәзинәсенең серен ачып бирергә теләсә дә, ышаныч һәм кызыксыну тапмагач, кулын селтәгән, аннары, озак та тормый вафат булып, хәзинә серен үзе белән мәңгегә алып киткәндер. Ә инде XIX йөзнең урталарында Әҗемовлар, үзләренең Казан ханлыгы чорындагы шаннарын искә алып, Әҗем (Мөхәммәд Әмин) хан хөрмәтенә һәм үз исемнәрен мәңгеләштерү йөзеннән шушы мәчет бинасын салдырулары мөмкин.

## Нигез салыну

Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» исемле мәшһүр әсәрендә язылганча, бүгенге мәчет урынында 1810 елда хаҗи Гаделмәҗид бине Әбүбәкер тарафыннан манарасыз гына бер агач мәчет салына. Ул чакта шәһәрнең көньяк-көнбатыш ягына, Пләтән авылы тирәсенә бик күпләп мөселманнар килеп утыра башлаган. Аларның күбесе якында гына эшли башлаган Юнысов, Апанаев, Китаевларның сабын заводларында эшләүчеләр. Шул вакытта Габделмәҗит хаҗи Әбүбәкеров акчасына манарасыз, бер катлы гына агач мәчет төзелгән. Биш вакыт намаз биредә укылса да, хаҗи, ни хикмәттер, җомга һәм гаетләрне Яңа бистәгә барып Фазыл муллага, ә аннары Ф. Әмирхан әтисенең бабасы Әмирхан мулла бине Габделмәннанга ияреп башкарган.

## 1851 елда яңартылу

40 еллап вакыт узгач, бу мәчет тузып, яраксыз хәлгә килгән. Аның урынына мәхәлләнең иң бай сәүдәгәрләреннән саналган һәм татарларның шәһәр Ратушасы башлыгы булып торган Мостафа Нәзир улы Әҗемов (1780 – 1865) яңа мәчет төзеткән.

Каюм Насыйри да үзенең 1822 елда чыккан календаренда: «Әҗем мәхәлләсе яки забут мәхәлләсе һәм диерләр, монда хәзер дә икенче агач мәсҗидтер, әүвәлге мәсҗидне Мәҗит хаҗи дигән адәм салдырган иде, әүвәлге мәсҗид тузгач, моны Әҗемләр салдырдылар, кадим монда мәхәллә юк иде», – дип яза. Беркадәр ашыгып салынганлыктан, яңа мәчетнең михрабы көнчыгышка таба көньяктан – 7, кыйбладан 8 градуска авыш килеп чыга.

1873 елда беренче гильдия сәүдәгәр, ике фабрика хуҗасы Мортаза бине Мостафа улы Әҗемов (1812 – 1887) иске мәчетне җимереп, аның урынына зур, киң, якты мәчет төзетә: аны яңарттыра, ягъни сипләтә,

түбәсен һәм түшәмен тимердән эшләтә. Соңрак мәчетнең кайбер урын уңайсызлыкларын искә алып, Мортаза Әҗемов аны Лаеш өязенең Чыты авылына (хәзерге Питрәч районына керә) озата.

XIX йөз урталарында, шушы районда фабрикант Крестовников стеарин һәм сабын җитештерү белән шөгыльләнә башлагач, мәхәлләгә «заводныкы» («заводской») исеме бирелә. Җитештерү үскән саен мәхәллә дә зурая. 1886 елда анда инде 450 ир кеше исәптә тора, шуларның 57се – йорт хуҗалары. Нәкъ шул чорда яңа, зур мәчет төзү зарурлыгы көн тәртибенә килеп баса.

1887 елның 18 мартында Казан мещаны Шиһиәхмәт Исхак улы Әминов Казан губерна идарәсенә «завод мәхәлләсе» кешеләре исеменнән яңа таш мәчет салдыру өчен рөхсәт сорап приговор тапшыра. Монда сәүдәгәр Мортаза Мостафа улы Әҗемовтан үз исәбенә мәчет салдырачагы хакында «подписка» да була.

Бу вакытта сәүдәгәр мәчетнең иске бинасын Лаеш өязендәге Чыты авылына күчереп өлгергән була. 1887 елның 22 апрелендә губерна идарәсеннән рөхсәт алуга, Мортаза бине Мостафа Әҗемов тирә-яктагы күп кенә йортларны сүттереп, киңәйтелгән яңа мәйданга зур һәм төзек итеп таш мәчет салдырырга керешә. Мәчетнең идәне һәм түшәме эшләнеп беткәч кенә Мортаза Әҗемов каты авырып китә һәм 1887 елда вафат була. Мәчетне инде бер-ике ел эчендә Мортазаның варислары тәмам итә.

### «Әҗем («Гаффария») мәдрәсәсе»

Әҗемов мәчете тарихы белән рухани Габделгаффаровлар нәселе тыгыз бәйләнгән. Бу нәсел Сембер губернасы Буа өязе Яңа Чокалы авылы кешесе Габделвәли Габделгаффаровтан (1891 елда вафат) башлана. Ул Әҗем мәчетендә имам-хатыйб булып 1849 елның июненнән 1888 елның ноябренә кадәр хезмәт иткән. Соңыннан аны улы Хисаметдин Габделвәли улы Габделгаффаров (1849 – 1923) алыштырган.

Үз заманының традициясе буенча мәчет каршында революциягәчә зур гына шөһрәт казанган «Әҗем мәдрәсәсе» эшләп килгән (бинасы хәзер дә мәчет янәшәсендә). Мәчет имамнары һәм мөдәррис аталы-уллы Габделвәли һәм Хисаметдин Габделгаффаровлар исеме белән бәйле рәвештә ул икенче төрле «Гаффария мәдрәсәсе» дип тә аталган.

Бу укыту йорты үзенең мәйданы һәм күләме буенча Казан мәдрәсәләреннән калышса да, заманында шактый абруй казанган. Махсус шушы мәдрәсә өчен сәүдәгәр М. М. Әҗемов 1871 елда, архитектор П. Е. Анипин проекты буенча, мәчет чикләрендә бер катлы кирпеч йорт төзеткән. Мөгаен, 1887 – 1890 еллардагы таш мәчет төзелеше вакытында ул хәзерге ярымташ мәдрәсә бинасына үзгәртеп төзелгәндер.

1875 – 1880 елларда «Гаффария» мәдрәсәсендә күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы-галим Х. М. Габәши (1863 – 1936) укыган һәм укыткан; 1890 еллар башында монда драматург Г. Камал белем алган.

1900 елда мәдрәсәдә 84 кеше укыган, алар арасында аксөяк балалары – 2, сәүдәгәр – 4, мишчән – 10, рухани – 18, крестьян балалары 50 кеше булган. 1905 елда шәкертләр саны 130га җиткән, шуларның алтмышын – казанлылар, калганын читтән килүчеләр тәшкил иткән. Габделкадыйр бине Мортаза Әҗемов исә мәдрәсәнең назыйре (попечителе) булып торган.

## Мәчетнең эчке һәм тышкы күренеше

Әҗем мәчетен шәһәрнең иң матур, иң нәфис мәчете дияргә мөмкин. Көнчыгыш Мавритания стилендә салынган булса да, манарасының ян кырыйга урнашканлыгы белән ул татар гыйбадәтханәләренең традицион типтагы таш вариантын гәүдәләндерә. Мәчетнең төньягыннан күтәрелгән шәмдәй төз манара төгәл пропорцияләр, бинасының купшы формасы, зәвыклы архитектура эшләнеше әлеге мәчеткә аерым нәфислек, камиллек, кабатланмас үзенчәлек бирә, аның Шәрык чалымнарын кал-

ку итеп күрсәтә. Кызыл кирпечтән салынган мәчет бинасы майолика (керамиканың бер төре) һәм уелма таш белән матур итеп нәкышланган.

Мәчет түбәсендә зәвык белән эшләнгән сигезкырлык урын алган. Аның өстенә вертикаль валиклар белән бизәлгән нечкә һәм биек цилиндр утыртылган. Цилиндр өстә очлаеп тора торган аркалар белән төгәлләнгән, алары исә бизәлгән кирпечтән эшләнгән «пута» белән уратылган. «Пута» өстендәге манара баганасын ак ташлы челтәрле таянычлар (консольләр) бизи. Барлык бу элемент, детальләрнең искиткеч нәфис, геометрик төгәллек белән башкарылуы, төрле төсләр уены белән баетылып эшләнүе мәчетне тамаша иткән кеше күңелендә гаҗәеп бер канәгатьлелек, чиге күрелмәгән камиллек хисе уята. Мәчетнең гомуми композициясен бина архитектурасы белән стиль ягыннан тыгыз бәйләнгән нәфис киртә тулыландыра.

1939 елның 22 апрелендә Татарстан Республикасының Үзәк Башкарма Комитеты карары белән мәчет ябыла. Әҗем мәчетенең гаять әһәмиятле тарихи һәм сәнгать әсәре үрнәге булуын истә тотып, узган гасырның 70 елларында аны төзекләндерү һәм беренчел кыяфәтенә кайтару юлында зур эшләр башкарылган.

Мәчет 1989 елда ислам динен тотучыларга кире кайтарыла. 1992 елда Р. В. Билялов проекты буенча фасадларны реставрацияләү һәм интерьерларны реконструкция эшләре башкарыла.

*«Татарстан Җөмһүрияте: татар халкының тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре» китабыннан, «Фест» нәшрияты, 1995 ел*

# Васыя нәбәвия

## Мөхәммәд галәйһиссәлам васыяте

أيها الناس، عليكم بحب أهل بيتي، عليكم بحب حملة القرآن، عليكم بحب علمائكم، لا تبغضوهم ولا تحسدوهم، ولا تطعنوا فيهم، ألا من أحبهم فقد أحبني، ومن أحبني فقد أحب الله، ومن أبغضهم فقد أبغضني، ومن أبغضني فقد أبغض الله، ألا هل بلغت؟

### Тәрҗемә

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм васыятендә әйткән: «Ий адәмнәр! Минем әһле-бәйтемне (нәселемне)[1] сөегез, әһле-Коръәнне (Коръәнне өйрәнүче вә аның берлә гамәл итүче кемсәләрне) сөегез вә голәмәгезне (дин белеп, дин өйрәтүче кемсәләр) сөегез.

Мәзкүр /искә алынган/ таифәләрне /төркемнәрне/ дошман тотмагыз вә аларга көнчелек кылмагыз, вә аларга тел тидермәгез, аң булыгыз ки, һәркем аларны сөйсә, мине сөйгән булыр, вә мине сөйгән кеше Аллаһыны сөйгән булыр, вә һәркем аларны дошман тотса, мине дошман тоткан булыр, вә мине дошман тоткан кеше Аллаһыны дошман тоткан булыр.

### Изах /ачыклау, аңлату/

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәселе, вә Коръән әһеле, вә галим әһеле, динне яхшы белүчеләр вә дин буенча гамәл итүчеләр, иң

[1] Монда һәм алга таба җәяләр эчендә мәкалә авторының аңлатмалары, квадрат җәяләр эчендә редакция аңлатмалары китерелә.

динне саклаучылар вә динне халыкка өйрәтүчеләрдер. Пәс /димәк, шулай/ аларны сөймәк Аллаһы җибәргән вә Аллаһының Расүле китергән динне сөймәк булып, Аллаһыны вә Расүлуллаһны сөймәккә кайтадыр.

Әһле-сәлах вә әһле-галимне дошман күрү динне дошман күрү булып, ахырында Аллаһыны вә Аның Расүлен дошман күрү хөкемендә буладыр, мәгаз Аллаһ /Аллаһы сакласын/.

Халык арасында гыйлем газиз күрелмәсә, голәмәгә хөрмәт ителмәсә, гыйлем күтәрелер тәхсыйленә /омтылуга/ касд /максат, теләк/ итүче вә иҗтиһад кылучы булмас; динне чын аңлардай вә яхшы өйрәнердәй кеше калмас, диннең сүңгән көне халыкның харап вә һәлак була торган көне тар, мәгаз Аллаһ.

Пәс, дингә ышанган вә дин өчен кайгырган мөселман гыйлемне алуы вә рауаҗы /тарату/ өчен тырышмалы вә булган кадәрле голәмәнең кадерләрен белмәле вә вөҗүдләренә тәшәккүр әйтмәле.

Вә аларның косурлары /кимчелекләре/, чөнки мәгъсум (кимчелексез) түгелләрдер, бар икән, аңа бакмаенча, яраклы җирләренә күз салмалы. Шул вакытта гына алардан истифадә /файдалану/ мөмкин булыр, шул вакытта гына гаммә нәс /халык, кешеләр/ диннәрен саклый алырлар. Мәсәлән, бер кемсә кеше гаебен күрүчән, хосусән голәмәнең әхвәлен тикшерүчән булса, аның күзенә бер галимнең йөз күркәм эше күрелмәс, бер гаебе күрелер дә, аңа мәхәббәт итмәс, бәлки дошман тотар, вә аннан файда алуны истәмәс /теләмәс/, истәрсә дә, мәхәббәте булмаганга, ала алмас.

Икенче галим хосусында дәхи шул рәвешчә булыр вә һәкәзә /шул рәвешле/ билахир /ахырда/ мондый кемсенә дин эшләрендә фәкать шәйтан вә нәфес әммарәсе /боеручы, мәҗбүр итүче/ мәшвәрәтләрендә генә калып һәлак булыр. Мәгаз Аллаһ.

Ихтиятлы /сакланучы/ вә үзен коткарырга тырышкан мөселман һәркемнең, хосусан голәмәнең яхшылык җәһәтләренә (якларына) генә

багар, алардан, пәйгамбәр булмаганнарыннан бер дә косурсыз вә гаепсез булуны көтмәс, вә халыкны голәмәдән аерып, гыйлемсез вә динсез калдыруны касд /теләү/ иткән мөфсидләрнең (бозучыларның) вәсвәсәләренә колак салмас, бәлки булган кадәрле голәмәнең дөрес булган, Китап вә сөннәткә муафикъ булган (ата-бабадан калма гадәтләргә вә карчыклардан ишетмә сүзләргә хилаф булса да) сүзләренә колак салыр, мөмкин кадәр истифадә итәр, динен төзәйтер, холкын турайтыр вә бигаун Аллаһ /Аллаһы ярдәме белән/ нәҗат /котылу/ табар. Вәллаһу йәһди мән йәшәэ вә йүдиллү мән йәшәэ /Аллаһы Тәгалә теләгән кешесен туры юлдан алып барыр, вә теләгәнен – адаштырыр/.

*Галимҗан Баруди,*
*«Әд-дин вәл-әдәб», 196 нчы бит*

# Васыя нәбәвия

## Мөхәммәд галәйһиссәлам васыяте

أيها الناس أحفظوا ألسنتكم وأبكوا عيونكم واخضعوا قلوبكم واتعبوا أبدانكم وجاهدوا أعدائكم وعمروا مساجدكم واخلصوا إيمانكم وانصحوا إخوانكم وقدموا لأنفسكم وأحفظوا فروجكم وتصدقوا من أموالكم ولا تحاسدوا فتذهب حسناتكم ولا يغتب بعضكم بعضا فتهلكوا، أَلَا هل بلغت

1) Ий адәмнәр! Телләрегезне (гөнаһ сүздән) саклагыз, күзләрегезне елатыгыз, калебләрегезне түбәнләндерегез (сеңдерегез). Бәндә һәр вакытта Аллаһыга әдәп вә шөкер кылуда косурлы вә гаепле булуыннан даимән

үзенең хәлен белеп, күңеленә сеңдереп, тәвазыйг /түбәнчелек, тыйнаклык/ вә хәвеф үзрә булу тиешледер. Бу рәвештә булганда Аллаһыдан өмидле хәлдә булыр, әгәр билгакес /киресенчә/ гөнаһлы вә гаепле була торып, тыныч йөрсә, калебендә Аллаһыдан хәвеф булмаса, вә хәвеф әсәре булган күз яше күрелмәсә, ул бәндәнең газабына (ачыгына) очравы бик ихтималдыр. Мәгаз Аллаһ.

2) Тәннәрегезне мәшәкатьләндерегез (ялкау булмагыз, үз эшегезне үзегез үтәгез).

3) Дошманыгызга сугыш кылыгыз (зираг /чөнки/ сугышсыз дин, вә милләт, вә мәмләкәт сакланылмый; динегезне бозучы, милләтегезне югалтучы, ватан вә мәмләкәтегезне кулларыгыздан алучы булса, ирек бирмәгез, разый булмагыз, сугыш кылыгыз. Бәндәгә динен, милләтен, ватанын сакламак фарыздыр).

4) Мәсҗидләрегезне абад /җитеш, төзек/ кылыгыз (мәсҗидкә йөрмичә, аны ташлап харап итмәгез). Шәргъ /шәригать/ вә Коръән телендәге гыймарә /корылма/ мәсҗидтән морад иң олуг булган – гыймарә батыйнәдер /эчке, күңелдәге/, ягъни әһленең күплеге муафикъ сөннәт биш вакыт намазны һәммә мөселманнар җыелып бергәләшеп укулары-дыр. Гыймарә заһира /ачык, билгеле/, ягъни агачы вә ташы таза, заһири әсбабы /кирәк-яраклары/ җитеш булган морад түгелдер. Бу гыймарә заһира фәкать вәсиләдер /чара, әмәл/, әүвәлге гыймарә батыйнә исә усуль диннән /диннең төп кануннарыннан/ кирәксәнелгән максуд әгъладыр / бөек максаттыр/.

5) Иманнарыгыз, диннәрегезне Аллаһы өчен генә кылыгыз; дин вә иманы дөнья файдасы вә нәфес рәхәте өчен дип белмәгез вә алай кылмагыз, бәлки халис (ялангач) Аллаһы ризалыгы өчен кылыгыз, Коръәндә сүрә «Ләм йәкүн»дә:

«أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ»,

– дигән.

Дин вә гыйбадәтне халис Аллаһы өчен кылу фарыз гайндер. Бер кемсә шәригатьнең хөкемен үз файдасына булырдай күрелсә: «Мин шәригатьнең колы, мин шәригать ни боерса, аңа ризамын», – дип әйтсә, әмма нәфсенә агыйр тоелганда калебендә ризалык булмаенча, ул як, бу як борылса, башка нәфесенә муафикъ гыйлаҗ /чара/ эзләсә, дине халис булган кеше булмас, иман вә игътикады камил булган мөэмин булмас.

6) Карендәшләрегезгә (диндәшләрегезгә) хәерхаһ булыгыз (калебегездә аларга дошманлык булмасын, кулыгыздан килгәнчә ярдәм итегез, хыянәт вә нифакъ /икейөзлелек/ вә хөсед кылмагыз).

7) Үзегез өчен (кирәгегез) элек җибәрегез (Ахирәттә сезгә файда итәчәк гамәл вә хайратны Аллаһы өчен үтәгез, Ахирәткә алдан бара торсын).

8) Гаурәтләрегезне харамнан саклагыз (адәмне һәлак итүче нәрсәләрнең берсе – гаурәтедер).

9) Малларыгыздан садака вә хәер бирегез.

10) Бер-берегезгә хөсед (көнчеллек) кылмагыз, яхшылыкларыгыз югалыр (көнчеллек сәбәпле ихлас югала вә ният бозыла, ихлассыз вә дөрес ниятсез кылган гамәл файдасыз вә сәмрасез (җимешсез) буладыр).

11) Бер-берегезне гайбәт кылмагыз, һәлак булырсыз (гайбәт сәбәпле арагызда инфак /туйдырып тору чыгымнары/ югалыр, дошманлык туар, куәтләнер; арагызда иттифакъ бетсә, гадавәт /дошманлык/ вә ихтилаф туса, динегезне саклый алмассыз, дөнья эшләрегездә дә бәрәкәтле була алмассыз, пәс һәр як берлә һәлак вә вәйран /җимерек/ булырсыз димәктер).

*Галимҗан Баруди,*

*«Әд-дин вәл-әдәб», 263 нче бит*

# Риба бабындагы Расүлуллаһның (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) бәгъзе хәдис-шәрифләре

قال رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ: اجتنبوا السبع الموبقات، قالوا: يا رسول الله، وما هن؟ قال: الشرك بالله، والسحر، وقتل النفس التي حرم الله إلا بالحق، وأكل الربا، وأكل مال اليتيم، والتولي يوم الزحف، وقذف المحصنات المؤمنات الغافلات

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм җиде һәлак кылучы гөнаһтан ерак булыгыз дигән. «Йә Расүлуллаһ, аларниләр?» – дип сораганнарына әйткән: «Аллаһыга шәрик кушу, сихер кылу, тиешсезгә кеше үтерү, риба ашау (алу), ятим малын ашау, сугыш вакытында сугыш сафыннан качу, гөнаһсыз мөселман хатынын зина кылу берлә төһмәт /яла ягу/ итү.

*Ошбу җиде төрле гөнаһ шәригать телендә олуг гөнаһ (гөнаһ кәбира) дип саналадыр. Тәүбә кылмыйча башка кәффәрәтләр берлә кичерелмиләр. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу гөнаһларны мөһлек (һәлак итүче) мәгънәсендә булган мәубикъ дип атаган. Күрәсез ки, бу хәдистә риба ашауны ширек, сихер, катле нәфес /үз-үзеңне үтерү/, ятим малын ашау кыйтарында /рәтендә/ зикер ителгән.*

لَعَنَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ آكِلَ الرِّبَا، وَمُؤْكِلَهُ

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм риба ашаучыга (алучыга), ашатучыга (бирүчегә) ләгънәт укыган.

*Ләгънәт уку Аллаһының рәхмәтеннән ерак булсын димәк буладыр. Пәйгамбәрнең хәер догасы да, бәддогасы да кабул ителәдер.*

لَعَنَ رَسُولُ اللهِ صَلَّى اللهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ آكِلَ الرِّبَا، وَمُؤْكِلَهُ، وَكَاتِبَهُ ، وَشَاهِدَيْهِ، وَقَالَ: هُمْ سَوَاءٌ

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм рибаны ашаучыга (алучыга), бирүчегә вә риба мөгаһиденә /риба хакында килешүче, вәгъдәләшүче/ язучыга вә ике гуаһларына /шаһитләренә/ ләгънәт укыган вә алар бар да бер дигән.

*Язучы, гуаһлар риба мөгамәләсенә ярдәмче булдыкларыннан гөнаһта уртак ителгән.*

قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ أَرْبَعَةٌ حَقٌّ عَلَى اللَّهِ أَنْ لا يُدْخِلَهُمُ الْجَنَّةَ وَلا يُذِيقَهُمْ نَعِيمَهَا : مُدْمِنُ الْخَمْرِ وَآكِلُ الرِّبَا، وَآكِلُ مَالِ الْيَتِيمِ بِغَيْرِ حَقٍّ، وَالْعَاقُّ لِوَالِدَيْهِ

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: Аллаһыга тиешле ки дүрт төрле кешене оҗмахка кертмәс вә аның нигъмәтеннән татытмас: исерткеч эчүче кеше (мөдавәмәт /үзгәрешсез, дәвамлы/ кылучы), риба ашаучы, ятим малын ашаучы, ана вә атасын рәнҗеткән кеше (тиешле урында ата вә анасына буйсынмаган, тиешле хезмәтләрне тыңламаган кеше).

قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ ما ظهر في قوم الزنا والربا إلا أحلوا بأنفسهم عقاب الله

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: бер төрле халыкта зина вә риба (әшкярә /ачыктан-ачык/) булды исә, алар үзләренә Аллаһының газабын иңдерерләр.

قَالَ رَسُولُ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ مَا مِنْ قَوْمٍ يَظْهَرُ فِيهِمُ الرِّبَا ، إِلَّا أُخِذُوا بِالسَّنَةِ، وَمَا مِنْ قَوْمٍ يَظْهَرُ فِيهِمُ الرُّشَا، إِلَّا أُخِذُوا بِالرُّعْبِ

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: кайсы гына халыкта риба булды исә, алар ачлыкка дучар булырлар. Вә кайсы кавемдә ришвәт шәигъ /көчле/ булса, алар куркынычка грифтар /дучар/ булырлар.

Риба ашауда куркынычларны вә газапларны бәян иткән мәзкүр хәдисләрдән башка күп хәдисләр килгән. Мәзкүр аять вә хәдисләрдән аңланадыр ки, риба – гөнаһларның олугларыннан вә тәүбәсез ярлыканмый торган яманнарыннан, хәтта ширек вә сихер кеби оҗмахка керүгә мәнигъ булган кабахәт вә мордар эшләрдән икән.

*Галимҗан Баруди,*

*«Әд-дин вәл-әдәб», 68-69 нчы битләр*

# Тәрбия

# Әдәп-әхлакка караган хәдисләр

## Кешеләр белән ачык йөзле булу

Гата бине Йәсәр әйткән: «Мин Габдулла бине Гамре бине Әл-Гасны күрдем: «Миңа Аллаһының Илчесе турында Тәуратта искә алынган сыйфатлар турында сөйлә әле», – дип әйттем. Ул соравыма: «Ярар», – дип җавап кайтарды. – Аллаһы белән ант итәм, Тәуратта аның турында әйтелгәннәр өлешчә Коръәндә язылганнар белән туры килә. (Моны әйткәч ул Коръәннән аять китерде): **«Ий, пәйгамбәр галәйһиссәлам, Без сине Ислам шәригатен кешеләргә ирештергәнлегеңә шаһит итеп, сиңа ияреп Коръән белән гамәл кылучы мөэминнәрне җәннәт белән шатландыручы, һәм Коръән белән гамәл кылмаучы кешеләрне җәһәннәм газабы белән куркытучы итеп җибәрдек».**

«Әхзаб / Гаскәрләр», 33:45

(Алга таба ул Тәуратта искә алынган сыйфатларны санап китте): «Мин сине надaннарга яклаучы буларак җибәрдем. Син – Минем колым һәм Илчем. Мин сине ышанычка лаеклы дип әйттем». (Шулай ук ул башка сыйфатларны искә алды): «ул тупас һәм дорфа түгел, базарларда тавыш күтәрми. Ул начарлыкка начарлык белән җавап кайтармый, киресенчә, гафу итә һәм кичерә. Адашкан өммәтне аның аша хак юлга бастырмыйча һәм алар «Аллаһыдан башка илаһ юк» дип әйтеп, шуның нәтиҗәсендә сукырайган күзләре, чукракланган колаклары һәм богауланган йөрәкләре ачылмыйча Аллаһы Тәгалә аның җанын алмас».

## Киң күңеллелек

Әнәс бине Мәликтән риваять ителә. Ул: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам шәфкатьле иде. Беркем дә яныннан аның ризалыгын алмыйча китми иде.

Ул бирергә әйбере булмаса, үзенең вәгъдәсен үти иде. Бервакыт намазга камәт әйтелгән вакытта бер бәдәви килеп, аның киеменә ябышты: «Минем калган кечкенә генә үтенечемне тыңла, юкса онытуымнан куркам», – дип әйтте. Үтенечен сөйләп бетергәнчегә хәтле Мөхәммәд галәйһиссәлам аның янында булды. Шуннан соң ул кире килде һәм намазын башкарды», – дип әйткән.

## Тәкәбберлек

Габдулла бине Гамре әйткән: «Без Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында утырган вакытта каймаланган чапанда бер бәдәви килеп керде һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршысына басып: «Сезнең дустыгыз (пәйгамбәрне күз алдында тотып) барлык җайдакларны түбәнсетте яки барлык көтүчеләрне дә артык югары күтәреп, түбәнсетергә тели», – дип әйтте. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны чапан бөрмәсеннән тотып алып: «Күрәм син акылын югалткан кешенең киемен киеп йөрисең», – дип әйтте. Тагын шуңа өстәп: «Нух галәйһиссәлам, үлеме якынлашкач, улын чакырып: «Мин сиңа берникадәр үгет-нәсыйхәт бирәм. Мин ике нәрсәне әмер итәм һәм ике нәрсәне тыям. «Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк» дигән сүзләрдә нык торырга әмер итәм. Әгәр үлчәү тәлинкәсенең бер ягына җиде күкне һәм җиде җирне, ә икенче ягына әлеге «Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк» дигән гыйбарәне салсалар, бу ягы өстенрәк чыгар иде. Әгәр җиде күк һәм җиде җир кара бөҗра булсалар, алар «Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк. Аңа барча дан һәм мактау» дигән сүзләрдән таркалырлар иде. Бу дога ярдәмендә һәркем тормышында үз теләгәненә ирешер. Мин сине Аллаһы Тәгаләгә ширек кылудан һәм тәкәбберлек күрсәтүдән тыям», – дип әйткән.

Мин: «Аллаһының Илчесе без күпаллалык турында беләбез, ә тәкәбберлек нәрсә ул? Безнең беребездә чапан бар, әллә тәкәбберлек шуннан гыйбарәтме?» – дип сорадым. Ул: «Юк», – дип җавап бирде. Мин

тагын: «Беребезнең ике нык каешлы пар аяк киеме (сандалиясе) бар. Бу тәкәбберлек түгелме?» – дип сорадым. «Юк», – дип җавап бирде ул. Мин янә: «Беребезнең атланып йөрерлек малы бар. Тәкәбберлек түгелме бу?» – дип сорадым. Ул тагын: «Юк», – дип җавап кайтарды. «Беребезнең кунакка йөрерлек дуслары бар. Әллә шулмы тәкәбберлек?» – дип сорадым. «Юк», – дип җавап бирде ул. Мин: «Аллаһының Илчесе, алайса нәрсә соң ул тәкәбберлек?» – дип сорагач, ул: «Хакыйкатьне кире кагу һәм кешеләргә карата рәхмәтле булмау», – дип җавап бирде.

## Пәйгамбәр галәйһиссәламнең догалары

Рифага Әз-Зуркый әйткән: «Өхед сугышы вакытында потка табынучылар чигенгәннән соң Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин Аллаһы Тәгаләне мактый алырлык итеп тигез сафларга басыгыз», – дип әйткән. Алар аның артыннан рәт-рәт басканнар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә, Сиңа барча мактаулар булсын. Аллаһым, беркем дә Син киң иткәнне тарайта, Син ераклаштырганны якынайта алмый. Син тотып калганны беркем дә бирә һәм бирә алганны тотып кала алмый. Безгә үзеңнең шәфкатеңне һәм мәрхәмәтеңне ирештер, яшәр өчен кирәкле булганнарны бир! Аллаһым, үзгәрми һәм югалмый торган мәңгелек рәхмәтеңне ирештер. Аллаһым, фәкыйрьлекнең иң соңгы көнендә мәңгелек рәхмәтеңне һәм курку көнендә иминлек бир. Аллаһым, Үзең җибәргән барлык начарлыктан һәм Син саклаган барлык явызлыктан да Сиңа сыенамын. Аллаһым, динебезне яратучылардан булсак иде, аның белән безнең йөрәкләребезне ямьләндер. Иманнан читләшүне, ышанмаучылыкны һәм гөнаһ кылуны күрә алмаучылардан булсак иде. Туры юлдан баручылар арасында безгә урын бир. Аллаһым, безгә мөселман булып үләргә һәм мөселман булып яшәргә насыйп әйлә. Безне туры юлдан баручыларга якынайт. Аллаһым, Синең юлыңда киртәләр куйган һәм Синең

илчеләреңне кире каккан имансызларга зыян сал. Аллаһым, аларны хурлыкка төшер!» – дип әйткән.

## Төчкергән кешегә рәхимлелек теләү

Габдеррахман бине Зийәд бине Әнгам Әл-Ифрики әйткән: «Әтием миңа түбәндәгеләрне сөйләгән иде: Могавийә идарә иткән заманда алар хәрби диңгез походында булалар. Аларның көймәләре Әбү Әюб Әл-Әнсари көймәсенә кушыла. Төш вакыты җиткәч, алар аны үзләре янына чакыралар һәм ул алар янына күченә. Әбү Әюб Әл-Әнсари: «Сез мине чакырдыгыз. Гәрчә уразалы булсам да, сезнең тәкъдимегезне кабул итмичә булдыра алмадым, чөнки мин Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең «Дөреслектә, мөселман үзенең кардәшенә карата алты гамәлне башкарырга тиеш. Әгәр ул аларның берәрсен санга сукмаса, ул кардәшенә карата хакын үтәмәгән булыр. Әгәр кардәше чакырса, ул аның чакыруын кабул итәргә тиеш. Ул төчкерсә, аның өчен рәхимлелек сорарга. Кардәше авыртып китсә, аның хәлен белергә, үлем хәлендә яткан кардәше янына килергә тиеш. Киңәш сораган кардәшенә хәерле киңәшен бирергә тиеш», дигән сүзләрен ишеттем», – дип әйтә.

Габдеррахманның әтисе сүзен дәвам итеп, тагын боларны да сөйләгән: «Безнең белән шаяртырга ярата торган бер кеше дә бар иде. Ул кеше безгә ризык китергән берәүгә: «Аллаһы Тәгалә сине игелек һәм тәкъвалык белән бүләкләсен», – дип әйтте. Тегесенә исә бу теләкләр артык күренепме, аның моңа ачуы килде. Шуннан шаярта торган кеше Әбү Әюбтан: «Әгәр мин «Аллаһы Тәгалә сине игелек һәм тәкъвалык белән бүләкләсен», дип әйтеп, бу сүзләрем өчен миңа үпкәләгән һәм ачуланган кеше турында син нәрсә әйтерсең?» – дип сорады. Әбү Әюб: «Гадәттә без «Кешене яхшылык төзәтмәсә, аны начарлык төзәтер», дип әйтә идек», – дип җавап кайтарды. Шуннан соң ул сөйләм рәвешен үзгәртеп, ризык китерүчегә: «Аллаһы Тәгалә сине явызлык һәм ихтирамсызлык белән

бүләкләсен!» – дип әйтте. Тегесе моңа көлеп җибәрде һәм риза булып: «Бәлкем, җитәдер инде шаяртырга?» – дип әйтте. Шаяртучы исә: «Аллаһы Тәгалә Әбү Әюб Әл-Әнсарины игелек белән бүләкләсен!» – дип әйтте.

## Үз кардәшеңне күргәч урыныңнан тору турында

Мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһә: «Мин сөйләмендә, үз-үзен тотышында Фатыймадан кала беркемнең дә Пәйгамбәр галәйһиссәламгә охшаганлыгын күрмәдем», – дип әйтә. Сүзен дәвам итеп: «Әгәр Пәйгамбәр галәйһиссәлам Фатыйманың килгәнен күрсә, ул аны сәламли иде, аннан урыныннан торып, аны үбә иде, кулларыннан алып, аны тиешле урынга утырта иде. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе аның янына кергәндә, Фатыйма да сәламли, үз урыныннан торып, әтисен үбә иде. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең үлеме алдыннан, авыртып ятканда Фатыйма әтисе янына килде. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аны сәламләде, үпте һәм аңа үз серен әйтте. Фатыйма елап җибәрде. Шуннан соң ул аңа тагын нәрсәдер әйтте, Фатыйма бу юлы көлде. Мин хатыннарга: «(Фатыйма) хатын-кызларның берсе булса да, ләкин ул барлык хатыннардан да өстенрәк. Иң элек ул елады, аннан көлде», – дип әйттем. Мин Фатыймадан: «Ул сиңа нәрсә әйтте?» – дип сорадым. Фатыйма: «Мин серне ачмыйм», – дип җавап кайтарды. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм үлгәннән соң, Фатыйма: «Ул миңа «Мин үләм», дип әйтте», шуңа мин еладым. Шуннан ул сер итеп кенә, «Гаиләбездән иң беренче булып син миңа кушылачаксың», дип әйтте. Шуңа да мин моның белән бик риза булдым һәм шатландым», – дип серне ачты.

## Берәү икенче бер кешене аның бүлмәсендә сәламләсә

Гобәйд бине Хөнәйн Әбү Муса сөйләгәннәрдән риваять кыла: «Мин өч тапкыр Гомәр янына керер өчен рөхсәт сорадым, ләкин ул миңа рөхсәт

итмәде, шуңа да мин киттем. Шуннан соң ул минем артымнан берәүне җибәрде һәм бу сүзләрне ирештерде: «Габдуллаһ, сиңа мине ишек төбендә көтеп торуы авыр идеме? Син шуны да бел, башкаларга да сине ишегең төбендә көтеп тору авыр була. Аның бу сүзләренә карата мин: «Мин бит синнән өч тапкыр керергә рөхсәт сорадым. Өч тапкыр сорап та, рөхсәт ала алмагач китеп бардым, чөнки миңа шулай эшләргә кушылган иде», – дип җавап кайтардым. Ул миннән: «Син бу турыда кемнән ишеттең?» – дип сорады. Мин аңа: «Пәйгамбәр галәйһиссәламнән ишеттем», – дип җавап кайтардым. Гомәр моңа гаҗәпләнеп: «Без ишетмәгәнне, син ничек Пәйгамбәр галәйһиссәламнән ишеттең икән соң? Әгәр син миңа ачык дәлилен китермәсәң, мин сиңа җәза бирәчәкмен!» – дип әйтте. Мин аның яныннан чыгып киттем һәм мәчеттә утырган әнсарлар төркеме янына килдем. Мин аларга булган хәлне сөйләп бирдем. Алар гаҗәпләнеп: «Әллә бу нәрсәдә кем булса да шикләнәме?» – дип сорадылар. Мин аларга Гомәр әйткән сүзләрне ирештердем. Алар: «Синең белән безнең арадан иң кече булганыбыз барыр», – дип әйттеләр. Шулай итеп, минем белән Гомәр янына Әбү Сәгид Әл-Худри яки Әбү Мәсгүд барды һәм ул әйтте: «Без Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән урамга чыктык. Ул Сәгъд бине Өбәд өенә таба юнәлде. Ул сәламләде һәм керергә рөхсәт сорады. Ләкин аңа җавап килмәде. Аннан ул икенче, өченче мәртәбә сәламләде һәм керергә рөхсәт сорады, ләкин берсендә дә рөхсәт булмады. Шуннан соң Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Без ничек тиеш идек, шулай эшләдек», – дип әйтте. Аннары ул кире китте һәм Сәгъд аны куып тотып: «Әй Аллаһының Илчесе! Аллаһы белән ант итәм, мин синең сәламләвеңне ишеттем һәм сиңа җавап та кайтарасым килгән иде, ләкин аннан соң минем синең тарафтан үземә һәм гаилә әһелләремә дә сәламләүләреңне (иминлек теләү) ишетәсем килде», – дип әйтә. Әбү Муса: «Аллаһы белән ант итәм, мин Аллаһы Илчесенең хәдисенә ышанам», – дип әйтә. Шуннан соң Гомәр: «Әйе, ләкин минем инанасым килгән иде», – дип әйтә.

## Кемдер рөхсәтсез кергәч

Рибги бине Хираштан риваять ителгән: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бәну гамир кабиләсеннән берәү килә: «Керергә рөхсәтме?» – дип сорый. Пәйгамбәр галәйһиссәлам кол хатынга: «Аның янына чык та: «Әссәламү галәйкүм. Керергә мөмкинме?» дип әйтсен», – дип әмер бирә. Теге кеше: «Мин моны колыгыз миңа чыгып әйткәнче үк ишеттем һәм сездән «Әссәламү галәйкүм. Керергә мөмкинме?» – дип сорадым. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Сиңа да. Кер!» – дип әйтә. «Мин кердем дә, Пәйгамбәрдән: «Син ни өчен җибәрелдең?» – дип сорадым. Пәйгамбәр галәйһиссәлам соравыма: «Мин бары тик яхшылык кына алып килдем. Мин, сез бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылып, Аңа беркемне дә тиңдәш итмәү, Лат һәм Гуззә потларыгызга табынмавыгыз, көн дәвамында биш тапкыр намаз кылуыгыз, елның бер аенда руза тотуыгыз, шушы Йортка (Кәгъбәтулла) хаҗ кылып, байларыгызның малларыннан (билгеле бер) өлешне алып, ярлыларга бирүегез өчен сезгә җибәрелдем», – дип җавап кайтарды. Мин янә аннан: «Сиңа мәгълүм булмаган берәр нәрсә бармы?» – дип сорадым. Пәйгамбәр галәйһиссәлам миңа түбәндәгечә җавап кайтарды: «Аллаһы Тәгалә яхшыны хәбәр итә. Бары тик Ул белгән генә нәрсәләр бар. Биш нәрсә бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм: **«Дөреслектә, Кыямәтнең кайчан булачагын белү Аллаһы хозурындадыр, Ул теләгән вакытта яңгыр иңдерер һәм Ул хатыннарның карыннарындагы балаларның ирме, кызмы икәнен белер. Һичбер кеше кайда үләчәген белмәс һәм һичбер кеше иртәгә нәрсә эшләячәген белмәс. Аллаһы һәрнәрсәне белүче һәм һәр нәрсәдән хәбәрдардыр».**

«Локман», 31:34

## Киемгә төренү

Сәлим бине Җәбир Әл-Хуҗәйми: «Мин Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килдем. Ул чапанына төренгән хәлаттә иде. Чапанының читләре аның үкчәләрен япкан иделәр», – дип әйтә. Сүзен дәвам итеп ул: «Аллаһының Илчесе, миңа киңәш бир әле», – дип сорадым ди. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Сиңа тәкъвалыкта нык торырга кирәк. Бер изге гамәлдән дә читләшмә. Әгәр синнән берәрсе сораса, үз чиләгеңдә булган суны да аның чиләгенә сал, ачык йөз белән үз кардәшең белән сөйләш. Бик озын, җирдән өстерәлеп йөргән кием киеп йөрүдән саклан, бу тәкәбберлек билгесе, Аллаһы моны яратмый. Әгәр берәү синең хакта берәр нәрсә белеп һәм сиңа шелтә белдерсә, син аның хакында белгәннәрдән чыгып, аны бернәрсәдә дә шелтәләмә. Аны үз явызлыгы хөкеменә калдыр. Син үз әҗереңне алырсың. Теләсә нинди сәбәп белән дә әрләшмә», – дип киңәш бирде. Ул (Сәлим бине Җәбир Әл-Хуҗәйми): «Бу хәлдән соң мин беркемне дә – бернинди хайванны һәм беркемне дә орышмадым», – дип әйтә.

*«Әл-әдәб әл-мофрад» хәдисләр җыентыгыннан*

# Мәчет һәм балалар

Ислам дине таралгач та балаларны мәчеттә күрергә мөмкин булган. Әлбәттә, ул вакытта да инде балалар бүгенге кебек уйнаганнар, сикерешкәннәр, йөгергәннәр. Намаз вакытында елап та, көлеп тә җибәрә торган булганнар.

Риваятьләрдә хәбәр ителгәнчә, бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ачык урында сәхабәләр белән намаз кылган. Ибне Габбас (ул вакытта әле ул кече яшьтә булган) үзенең ике дусты белән ишәккә атланып, шушы җиргә килгәннәр. Болар Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршысыннан узып китеп, ишәктән төшеп, ишәкне намаз укучы сафлар арасына җибәргәннәр. Үзләре дә сәхабәләр арасында йөгерешеп уйнаганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм сәхабәләрнең берсе дә аларны бу гамәлләре өчен шелтәләмәгән. Шул рәвешле, олыларның мондый мөнәсәбәте балаларны җәмәгатьтән читләштермәгән, киресенчә, балаларда намазга һәм Аллаһының йорты булган мәчеткә мәхәббәт уяткан.

Икенче яктан караганда, ул вакытларда мәчетләр гыйбадәт кылу урыны гына булмаган. Мәчетләрдә дин гыйлеме дә өйрәтелгән, көндәлек, иҗтимагый һәм сәяси сораулар да хәл ителгән. Шуңа да мәчетләрдә балалар бик күп булган, хәтта алар аерым бер саф булып тезелеп баса торган булганнар. Мәчеттә булганда балалар мөселман кешесе нинди булырга тиешлеген, аңа нинди бурычлар йөкләнүен өйрәнгәннәр.

Күп кенә риваятьләрдән билгеле булганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм кайвакытларда кулына берәр оныгын яки оныкчыгын алып, намазын кыла торган булган. Ул сәҗдә кылган вакытта, алар аның аркасына менеп утырганнар. Алар җиргә төшмичә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәҗдәдән күтәрелмәгән. Моннан күренгәнчә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең

оныклары кече яшьтән үк мәчеткә йөргәннәр дип әйтә алабыз. Шулай ук мәчеткә хатын-кызлар күкрәк балалары белән дә килгәннәр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйткәне билгеле: «Аллаһының коллары булган хатын-кызларга мәчеткә йөрергә комачауламагыз». Мөхәммәд пәйгамбәр галәйһиссәлам балаларга мәчеткә йөрергә бернинди каршылыклар ясамаган, киресенчә, үзе аларны намазга өйрәткән.

Алда әйтеп үтелгәннәрдән күрәбез, төрле яшьтәге балаларның да мәчеткә тартылулары гадәти күренеш булган. Моны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик яхшы аңлаган, алар турында кайгырткан һәм аларга шартлар тудырырга тырышкан.

## Мәчеткә ничә яшьтән йөрергә?

Баланы ничә яшьтән мәчет белән таныштырырга була соң? Кемдер «бик яшьтән», дип әйтер. Кемдер «үзе аңлый башлагач», дип җавап бирер. Ә кайберәүләр баланың үзенә сайлау мөмкинлеге калдырырлар. Шәригатьтә фарыз намазлар һәм башка мәсьәләләргә бәйле яшь күрсәткечләреннән кала төгәл күрсәтмәләр юк. Шуңа да алда санап кителгән очракларның барысы да дөрес кебек.

Шулай да кайбер кыенлыкларга игътибар итеп китик. Мәсәлән, күкрәк баласын үзен генә калдырырга ярамый, чөнки ул кычкырып елап җибәрергә мөмкин, ә гыйбадәт кылучы әнисе аны тынычландырыр өчен намазыннан бүленә алмаячак.

Бер яки ике яшьлек баланы да үзен генә калдыру ярамый, чөнки ул, әлбәттә, әти-әнисен көтеп, ялгызы гына тыныч утыра алмый. Ул сафлар арасында йөри, шаяра, көлә яки елый башлый. Кайбер аналар кызы яки улы олыларга карап, шул ук вакытта намаз хәрәкәтләрен ясый башлыйлар дип ялгышалар.

Бераз зуррак яшьтә булган балаларны да үзеңнән ераграк җибәрергә ярамый. Алар һәрвакыт янында булырга тиешләр. Әгәр 5-6 яшьлек бала һәрвакыт йөри торган мәчетенә унынчы яки йөзенче тапкыр намазга килгән очракта гына аңа бераз ирек бирергә була: ул үзе теләгән кешесе янына басып намаз укый яки бераз алгарак китеп, имамга якынрак баса ала; яки олылардан соң, дуслары белән үз «җәмәгатен» оештырып баса.

## Рәсемнәрдәге мәчет

Бала сораулар бирә башлагач, аңа тулы һәм аңлаешлы мәгълүмат бирү бик мөһим. Бу сорауларга җавапларны аның белән бергә тапсагыз, тагын да хәерлерәк. Балага төрле мәчетләр мисалында бөтен дөньяны күрсәтергә була. Мәсәлән, беренче мәчет нинди булган? Хәзерге вакытта дөньядагы иң зур мәчет кайда? Бу сорауларга әлеге мәчетләрнең рәсемнәрен күрсәтеп тә җавап бирергә була.

Буш тартмалардан яки картоннан ясалган мәчет мисалында намаз уку залын, минбәр, тәһарәтханә бүлмәсен билгеләргә була.

## Мәчет ул гыйбадәт кылу урыны гына түгел

Башка дин вәкилләренең гыйбадәтханәләреннән аерылмалы буларак, мәчет ул гыйбадәт кылу урыны гына түгел. Теләсә нинди пакь, нәҗес булмаган җирдә намаз укырга яраганлыгын балалар белергә тиеш. Моның өчен мәчеткә бару шарт түгел. Мәчетнең үзендә намаз уку гына түгел, дини дәресләр үткәрергә, бәйрәмнәр оештырырга да мөмкин.

Хәзер инде бала мөстәкыйль рәвештә мәчеттә үз-үзен ничек тотарга кирәклеге турында уйланырга мөмкин. Мәсәлән, башкалар намаз укыганда комачауларга ярыймы? Юк, әлбәттә. Димәк, намаз укылган вакытта йөгерергә, тавышланырга ярамый. Мәчеттә чүпләргә ярыймы? Әлбәттә, юк. Чөнки монда намаз укыла, ә намаз чиста, пакь җирдә укылырга тиеш.

## Баларга мәчеткә йөрүне тыяргамы?

Әлбәттә, балаларны мәчеткә йөрергә һәм күңелләрендә мәчеткә карата мәхәббәт уятырга кирәк. Ләкин шул ук вакытта мәчеттә чисталыкны сакларга һәм анда гыйбадәт кылучыга комачау итмәскә кирәк. Җәмәгать белән намаз укымаучы балалар өчен иң хәерлесе – намаз залының ахыргарак өлешендә яки мәчет ишегалдында уйнау. Аларның уйнаганнарын олылардан берәрсе карап торса яхшы. Әйткәнебезчә, балаларның мәчетне чүпләмәүләрен һәм уйнаган вакытларында гыйбадәт кылучыларга комачау итмәүләрен күзәтеп торырга кирәк. Кайбер мөселманнар балаларын җомга намазына алып киләләр. Җәмәгать намаз кыла башлагач, балалар сафлар арасында йөгерешә, кычкырып сөйләшә башлыйлар. Бу бер дә матур күренеш түгел. Әгәр дә бала әтисе янәшәсенә басып, намаз кыла ала икән, аны үзең белән мәчеткә алып килергә була. Әгәр инде бала үзе дә намаз укымый һәм башкаларга да гыйбадәт кылырга комачаулый икән, бу очракта аны мәчеткә алып килмәү хәерлерәк.

## Файдалы киңәшләр

Балалар булган мәчетләрдә тавыш һәм дә тәртипсезлек булырга тиеш дигән сүз түгел. Алга таба берничә киңәш биреп китәбез:

1. Шелтәне йомшаклык белән белдер

Әнәс бине Мәлик Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең беркайчан да әшәке һәм түбәнсетә торган сүзләр әйтмәвен риваять иткән (Бохари).

Безгә балаларның бер гөнаһсыз икәнлекләрен онытмаска кирәк. Аллаһы Тәгалә балаларга начар торышлары өчен җәза бирми, киресенчә, алар белән нинди мөнәсәбәттә булуыбыз өчен безне җаваплылыкка чакыра.

Безнең бурычыбыз – балаларга йомшаклык белән мәчеттәге тәртипләрне аңлату. Төрле яшьтәге бала да үзенә тавыш күтәреп, түбәнсетеп әйткән кешенең сүзенә колак салмый. Әгәр инде кайгыртып, йомшаклык белән үзенә эндәшкән кешенең сүзен игътибар белән тыңлар.

2. Ярдәм кулыңны суз

Бер атаның шук баласы артыннан йөгереп йөргәнен яки сабыен тынычландырырга теләгән ананы карап торганчы, аларга ярдәм итәргә тырышырга кирәк. Әгәр «сез намаз укыган вакытта мин сезнең улыгызны карап тора алам» яки «пакетыгызны күтәреп торыйм», дип ярдәмегезне белдерсәгез – ул сезгә, ин шә Аллаһ, садака булып язылыр.

3. Искә төшерү

Мәчетләрдә һәрвакытта да әти-әниләргә һәм балаларга мәчеттәге тәртипләр һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшереп, әйтеп торырга кирәк.

4. Уңайлы шартлар булдыру

Мәчетләрдә ата-аналар һәм балаларга аерым урын бүленеп куелса хәерле. Монда әти-әниләре гыйбадәт кылганда яисә дини темаларга лекцияләр тыңлаган вакытта балалар үз уенчыклары белән уйный алырлар иде.

*islam-today.ru*

# Хаж

# Хаҗ кылуның фазыйләтләре

عَنْ عَبْدِ اللَّهِ بْنِ عَبَّاسٍ رَضِيَ اللَّهُ تَعَالَى عَنْهُمَا، قَالَ: كُنَّا مَعَ النَّبِيِّ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ بِمِنًى، إِذْ أَقْبَلَتْ طَائِفَةٌ مِنَ الْيَمَنِ فَقَالُوا: فِدَاكَ الْأُمَّهَاتُ وَالْآبَاءُ، أَخْبِرْنَا بِفَضَائِلِ الْحَجِّ؟ قَالَ: «بَلَى ، أَيُّ رَجُلٍ خَرَجَ مِنْ مَنْزِلِهِ حَاجًّا أَوْ مُعْتَمِرًا فَكُلَّمَا رَفَعَ قَدَمًا، وَوَضَعَ قَدَمًا تَنَاثَرَتِ الذُّنُوبُ مِنْ بَدَنِهِ، كَمَا يَتَنَاثَرُ الْوَرَقُ مِنَ الشَّجَرِ، فَإِذَا وَرَدَ الْمَدِينَةَ، وَصَافَحَنِي بِالسَّلَامِ، صَافَحَتْهُ الْمَلَائِكَةُ بِالسَّلَامِ، فَإِذَا وَرَدَ ذَا الْحُلَيْفَةَ، وَاغْتَسَلَ طَهَّرَهُ اللَّهُ مِنَ الذُّنُوبِ، وَإِذَا لَبِسَ ثَوْبَيْنِ جَدِيدَيْنِ جَدَّدَ اللَّهُ لَهُ مِنَ الْحَسَنَاتِ وَإِذَا قَالَ لَبَّيْكَ اللَّهُمَّ لَبَّيْكَ، أَجَابَهُ الرَّبُّ عَزَّ وَجَلَّ: بِلَبَّيْكَ وَسَعْدَيْكَ أَسْمَعُ كَلَامَكَ، وَأَنْظُرُ إِلَيْكَ، فَإِذَا دَخَلَ مَكَّةَ، وَطَافَ وَسَعَى بَيْنَ الصَّفَا وَالْمَرْوَةَ، وَاصَلَ اللَّهُ لَهُ الْخَيْرَاتِ، فَإِذَا وَقَفُوا بِعَرَفَاتٍ، وَضَجَّتِ الْأَصْوَاتُ بِالْحَاجَاتِ، بَاهَى اللَّهُ بِهِمْ مَلَائِكَةَ سَبْعِ سَمَوَاتٍ، وَيَقُولُ: مَلَائِكَتِي وَسُكَّانَ سَمَوَاتِي، أَمَا تَرَوْنَ إِلَى عِبَادِي، أَتَوْنِي مِنْ كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ شُعْثًا غُبْرًا قَدْ أَنْفَقُوا الْأَمْوَالَ وَأَتْعَبُوا الْأَبْدَانَ فَوَعِزَّتِي وَجَلَالِي وَكَرَمِي لَأَهَبَنَّ مُسِيئَهُمْ بِمُحْسِنِهِمْ، وَلَأُخْرِجَنَّهُمْ مِنَ الذُّنُوبِ كَيَوْمِ وَلَدَتْهُمْ أُمَّهَاتُهُمْ، فَإِذَا رَمَوُا الْجِمَارَ، وَحَلَقُوا الرُّؤُوسَ، وَزَارُوا الْبَيْتَ نَادَى مُنَادٍ مِنْ بُطْنَانِ الْعَرْشِ، ارْجِعُوا مَغْفُورًا لَكُمْ وَاسْتَأْنِفُوا الْعَمَلَ.

1. Факыйһ үзенең иснәде белән Ибне Габбастан риваять итте. Ул болай дип әйтте: «Без Расүлуллаһ белән Минада булдык. Шулвакытта

Йәмәннән бер төркем халык килеп чыкты. Алар: «Ата-аналар сиңа фида булсын, безгә хаҗның әҗерләре турында сөйлә», – диделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам болай дип әйтте: «Нинди генә кеше үзенең йортыннан хаҗ яки гомрә нияте белән чыкмасын, агачтан яфраклар коелган кебек, аның һәр аяк адымы саен гөнаһлары коелыр. Ул кеше Мәдинәгә килеп, сәлам биреп, минем белән күрешсә, фәрештәләр сәлам биреп, аның белән күрешерләр. Ул кеше ихрам микатына килеп госел коенса, Аллаһы Тәгалә аны гөнаһлардан пакь кылыр. Ул кеше ике яңа кием кисә, Аллаһы Тәгалә аның изгелекләрен яңартыр. Әгәр: «Ләббәйкәллаһуммә ләббәйк», – дип әйтсә, Аллаһы Тәгалә аңа: «Ләббәйк вә сәгадәйк», – ягъни «сүзеңне ишетәмен һәм сиңа карыймын» дип җавап бирер, Мәккәгә кереп, Кәгъбәне тәваф кылса һәм Сафа белән Мәрвә арасында йөгерсә, Аллаһы Тәгалә аңа изгелекләрне ирештерер. Кайчан (ул кеше) Гарәфәттә торып, көчле тавышы белән хаҗәтләрен сораса, Аллаһы Тәгалә алар турында җиде кат күкләрнең фәрештәләренә мактанып, болай дип әйтер: «Әй, Минем фәрештәләрем, әй, Минем күкләрдә торучыларым. Минем бәндәләремне күрмисезме? Бик күп ерак җирләрдән чәчләре тузанланган хәлдә Миңа килделәр. Малларын сарыф кылдылар, тәннәренә мәшәкатьләр китерделәр. Үземнең олуглыгым, кәрамем белән ант итәм: аларның явызларына да, яхшыларына да бүләк бирермен – аналары тудырган көндәге кебек аларны гөнаһларыннан чыгарырмын. Вак ташларны атсалар һәм чәчләрен кыскартсалар, Кәгъбәне зиярәт итсәләр, Гареш янында бер тавыш салучы болай дип кычкырыр: «Ярлыканып кайтыгыз һәм кабаттан гамәлләрегезне кыла башлагыз».

عن علي رضي اللَّهُ عنْه قال : كنت طائفا مع النبي. ببيت الله الحرام، فقلت : فداك أبي وأمي ما هذا البيت؟ فقال لي: يا علي، أسس الله سبحانه وتعالى هذا البيت في دار الدنيا كفارة لذنوب أمتي. فقلت:

فداك أبي وأمي ما هذا الحجر الأسود؟ قال: تلك جوهرة كانت في الجنة أهبطها الله إلى الدنيا لها شعاع كشعاع الشمس، واشتد سوادها وتغير لونها لما مستها ايدي المشركين.

2. Гали радыяллаһу ганһедән риваять ителә. Ул болай дип әйтте: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам белән бергә Кәгъбәне тәваф кылырга булдым. Мин: «Ата- анам сиңа фида булсын, әй Расүлуллаһ, бу нинди йорт?» – дип сорадым. Ул миңа: «Аллаһы Тәгалә дөнья йортында бу йортны минем өммәтемнең гөнаһларына кәффарәт булсын өчен салды», – дип җавап кайтарды. Мин: «Ата-анам сиңа фида булсын, әй Расүлуллаһ, кара таш нәрсә ул?» – дип сорадым. Ул галәйһиссәлам: «Ул – җәннәттә булган бер җәүһәр таш иде. Аллаһы Тәгалә аны дөньяга иңдерде. Аның кояш нуры кебек ялтыравыклы нуры бар иде. Мөшрикләр куллары белән тотканнан аның каралыгы катыланды, төсе үзгәрде», – дип әйтте.

3. Факыйһ үзенең иснәде белән Габбас бине Мәрдәстән риваять итте. Гарәфә кичәсендә Расүлуллаһ галәйһиссәлам өммәте өчен рәхмәт һәм мәгъфирәт белән бик күп дога кылды. Аллаһы Тәгалә: «Мин рәхмәт кылыр идем, ләкин кайберләре кайберләренә золым кылдылар. Шуның өчен аларны ярлыкамыйм, ярлыкый алмыйм», – дип җавап бирде. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Әй Раббым, залимнең золымы сәбәбеннән золым ителгән кешегә хәер савап бирергә көчең җитүчедер», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә Расүлуллаһка ул кичәдә җавап бирмәде. Мөздәлифә көненең таңы аткач, Расүлуллаһ яңадан дога кылды. Аллаһы Тәгалә Расүлүллаһка: «Мин өммәтеңнең гөнаһларын ярлыкадым», – дип җавап бирде. Расүлуллаһ галәйһиссәлам елмаеп көлеп җибәрде. Сәхабәләрнең кайберләре: «Һич көлми торган вакытыңда көлдең, әй, Расүлуллаһ», – дип әйттеләр. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Аллаһының дошманы Иблистән көлдем. Өммәтем хакында кылган догамны Аллаһы Тәгаләнең кабул

иткәнен белгәч: «Ни үкенеч, ни һәлакәт!» – дип кычкырып егылды. Башына туфрак сипте», – дип җавап кайтарды аларга.

عن أبي هريرة رضي اللَّهُ عنْه عن النبي صلّى اللَّهُ عليه وَسلّم انه أنه قال: امن حج اليت ولم يقرث ولم يفسق، رجع كيوم ولدته أهه.

4. Әбү Һөрайра Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять итте: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Кем дә кем хаҗ кылып, (шул ук вакытта) бозыклык кылмаса, өенә анасы тудырган көндәге кебек гөнаһсыз булып кайтыр», – дип әйтте».

5. Гомәр бине Хаттаб радыяллаһу ганһедән риваять ителде, ул болай дип әйтте: «Берәү бу йортка (Кәгъбәтуллага) килеп, шул йорттан башка теләге булмаса һәм ул йортны тәваф кылса, гөнаһларыннан анасы тудырган көндәге кебек арыныр».

وعن النبي صلّى اللَّهُ عليه وَسلّم أنه قال: ما رؤي الشيطاف يوما قط هو فيه أضعف ولا أحقر ولا اغيظ من يوم عرفه، وما ذلك إلا لما رأى من نزول الرحمة وتجاوز الله عن الذنوب العظام، ولم ير قبل ذلك مثله إلا ما رؤي من يوم بدر.

6. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Шәйтан Гарәфә көнендәгедәй һичбер көндә ачулырак, кечкенәрәк һәм зәгыйфьрәк күренмәде. Бу хәл исә шәйтанның рәхмәт иңүен, Аллаһы Тәгаләнең олуг гөнаһларны гафу кылганын күргәннән генәдер. Бәдер сугышы көненнән кала, Гарәфә көнендәй шәйтан бу рәвештә бүтән күренмәде».

7. Гомәр бине Габделгазиздән риваять ителде. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә вәхи кылганда, Кәгъбә һәм аның әҗере һәм фазыйләте бәян ителде. «Әй минем Раббым, хаҗ нәрсә ул?» – дип сорады. Аллаһы Тәгалә: «Бөтен йортлардан артык итеп сайлаган йортымдыр. Минем

хәлилем (дустым) харам иткән харамымдыр. Аңа җирнең һәрбер тарафыннан киләләр, кол үзенең хуҗасына «ләббәйк» дип әйткәндәй, шуның кебек үк тәлбия белән тәһлил әйтәләр». Муса галәйһиссәлам болай дип сорады: «Әй, Раббым, ул бәндәләреңнең савабы нәрсә булыр?» Аллаһы Тәгалә: «Ул бәндәләргә мәгъфирәтне тоташтырырмын, хәтта күршеләре һәм якыннары өчен аларны шәфәгатьче кылырмын», – дип әйтте. Муса галәйһиссәлам: «Әй, Раббым, алар арасында малы пакь түгелләр һәм күңелләре чын түгелләр бар», – дип әйтте. Аллаһы Тәгалә: «Дөреслектә, Мин аларның гөнаһларын күркәм гамәлләренә бүләк кылам», – дип җавап кайтарды.

8. Әбү Һарун Габидий Әбү Сәгыйд Әл-Ходрийдән риваять итә. Әбү Сәгыйд болай дип әйтте: «Гомәр бине Әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе белән хәлифәлегенең башында хаҗ кылдык. Ул Харам мәчетенә кереп, кара таш янында туктады һәм: «Син файда да, зарар да итми торган таш. Расүлуллаһның сине үпкәнен күрмәгән булсам, сине үпмәс идем», – дип әйтте. Гали: «Әй, мөэминнәрнең әмире, моның кебек сүзне әйтмә, чөнки ул таш Аллаһының рөхсәте белән зарар да, файда да кылыр. Әгәр мин Коръән укымасам һәм аның эчендәге хөкемнәрне белмәсәм иде, мин сиңа инкяр итмәс идем», – дип әйтте. Аңа Гомәр: «Әй Әбү Хәсән, Аллаһы Тәгаләнең китабында булган аятьнең тәфсире нәрсә?» – дип сорады. Гали радыяллаһу ганһе: «Аллаһы Тәгалә болай дип әйтте:

وَأَذِّن فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَىٰ كُلِّ ضَامِرٍ يَأْتِينَ مِن كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ ﴿٢٧﴾

«Шуны зекер ит, синең Раббың адәм балаларының аркаларыннан үзләренең нәселләрен алды һәм үз-үзләренең өстенә үзләрен үк таныкясады. «Мин сезнең Раббыгыз түгелме?» – дип әйткәч, «Әйе, безнең Раббыбыз – Син», – диделәр». Ул адәм нәселе бәндәчелек белән икрар кылгач, аларның икрарын тире өстенә язды. Соңыннан ошбу ташны чыгарды.

Ул ташка ошбу тирене йоттырды. Шулай исә, ул таш ошбу тире хозурына ышанган заттыр. Ул таш гаһеденә тугры булган кешегә Кыямәт көнендә таныклык итәр», – дип җавап кайтарды. Гомәр радыяллаһу ганһе: «Әй Әбү Хәсән, Аллаһы Тәгалә сезгә гыйлемне аз бирмәде», – дип әйтте.

9. Ибне Габбас радыяллаһу ганһедән риваять ителде. Күзе йомылганнан соң ул: «Җәяүләп хаҗ кылмаганыма үкенгәнем кебек һичнәрсәгә үкенгәнем юк, чөнки мин Аллаһы Тәгаләнең Коръәни Кәримдә болай дип әйткәне турында ишеттем:

وَأَذِّن فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَىٰ كُلِّ ضَامِرٍ يَأْتِينَ مِن كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ ﴿٢٧﴾

**«Әй, Ибраһим, кешеләрне хаҗга чакыр, җәяү һәм арык дөяләргә атланган хәлдә сиңа килерләр».**

«Хаҗ», 22:27

10. Әбү Ләйс Сәмәрканди әйтте: «Әгәр юл якын булса, җәяүләп хаҗ кылуда зарар юк, ул артыграк булыр. Әгәр юл ерак булса, атланып килү артыграк, чөнки җәяүле кеше үз-үзен мәшәкатьли, холкы явызлана. Әгәр шул сердән имин булса, ул вакытта җәяү бару артыграктыр».

11. Хәсән Әл-Басридән риваять ителде. Ул рахмәтуллаһи галәйһи: «Фәрештәләр хаҗ кылучыга очрарлар. Дөя иястәренә сәлам бирерләр; ишәк һәм качыр ияләре белән күрешерләр; җәяүлеләр белән кочаклашырлар», – дип әйтә.

وروى الضحاك، عن النبي صلّى اللّٰهُ عليه وَسلّم أنه قال: أيما مسلم خرج من بيته قاصدا في سبيل الله فوقصته دابته قبل القتال، أو لدغته هامة، أو مات باي حتف، مات وهو شهيد، وأيما مسلم خرج من بيته

حاجا إلى بيت الله الحرام، ثم نزل به الموت قبل بلوغه أوجب الله له الجنة.

12. Даххак Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән риваять итә. Ул болай дип әйтте: «Нинди генә мөселман үзенең йортыннан Аллаһы Тәгалә юлын ният итеп чыгып, аны хайван таптаса яки елан кебек нәрсә чакса; яки теләсә нинди сәбәп белән вафат булса, ул кеше шәһиттер. Нинди генә мөселман үз йортыннан Кәгъбәне хаҗ кылам дип чыгып, Кәгъбәгә ирешкәнчегә кадәр аңа үлем ирешсә, Аллаһы Тәгалә ул кешегә җәннәтне вәҗиб итәр».

وروى عن النبي صلّى اللَّهُ عليه وَسلّم أنه قال: «اللهم اغغر للحاج ولمن استغفر له الحاج».

13. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Әй Аллаһы, хаҗ кылучыны һәм аның догаларында мәгъфирәт белән искә алынган кешене ярлыка» – дип әйтте.

وروى عن عطاء عنعمر رضي اللَّهُ عنْه عن النبي صلّى اللَّهُ عليه وَسلّم أنه قال: صلاة في مسجدي تعدل الف صلاة غيره إلا المسجد الحرام.

14. Гата Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять итте. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Минем мәчетемдәге бер намаз башка мәчетләрдәге мең намазга бәрабәр булыр, әмма Харам мәчетендәге мең намазга бәрабәр булмас», – дип әйтте.

وفي خبر آخر: صلاة في مسجدي هذا أفضل من عشرة آلاف في غيره إلا المسجد الحرام، وصلاة في المسجد الحرام أفضل من مائة ألف صلاة في غيره، وصلاة في سبيل الله افضل من مائني ألف صلاة، ثم قال: ألا ادلكم على ما هو أفضل من ذلك، رجل قام في سواد الليل فأحس الوضوء، وصلى ركعتين يريد بهما ما عند الله.

Икенче бер хәбәрдә болай дип әйтелде: «Минем мәчетемдәге бер намаз башкалардагы ун мең намаздан артыгракдыр. Әмма Харам мәчетендәге ун мең намаздан артык булмас. Харам мәчетендәге бер намаз башкалардагы йөз мең намаздан артык. Аллаһы юлында бер намаз ике мең намаздан артыктыр». Соңыннан Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Мин сезне моннан да артыгракка димлимме? Бер кеше кара төндә торып, камил рәвештә тәһарәт алса һәм ике рәкәгать намаз укыса, шул ике рәкагәть намазны вәсилә итеп, Аллаһы Тәгаләнең каршындагы рәхмәтен теләсә, Харам мәчетендәге намаздан да артыграк булыр», – дип әйтә.

عن ابن عمر رضي اللَّهُ عنْه أنه قال: قال رسول الله صلّى اللَّهُ عليه وَسلّم: بني الإسلام على خس: شهادة ان لا إله إلا الله، وأن محمدا رسول الله وإقام الصلاة وإيتاء الزكاة وصوم رمضان، وحج البيت.

15. Йәзид бине Бәшәр бине Гомәрдән риваять итә. Расүлуллаһ галәйһиссәлам: «Ислам дине биш нәрсәгә нигезләнде: гыйбадәт кылырга лаек булган зат Аллаһы Тәгалә генә һәм Мөхәммәд галәйһиссәлам Аның Расүле, дип таныклык бирү, намаз уку, зәкят чыгару, Рамазан аенда ураза тоту һәм хаҗ кылу».

وروى عن سعيد بن المسيب رضي اللَّهُ عنْه عن النبي صلّى اللَّهُ عليه وَسلّم أنه قال:إن الله تعالى ليدخل ثلاثة نفر في الجنة الواحدة الجنة، والموصي بها، والمنفذ لها، و الحاج عنه، والعمرة كذلك.

16. Сәгыйд бине Мөсәййибтән риваять ителде. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә бер хаҗда өч кешене җәннәткә кертер: хаҗны васыять иткән кешене, хаҗ белән васыятьне җиренә җиткергән кешене, васыять итеп, вафат булучы өчен хаҗ кылучыны. Гомрә белән дә шулай ук», – дигән хәбәр бирде.

*«Тәнбиһүл гафилин» китабыннан (2 том, Казан, 2004 ел)*

# Хаҗ әдәпләре

**1) Хаҗга барганда**

- Хаҗ сәфәренә тотылган акчалар хәләл юл белән табылган булырга тиеш.
- Сәфәр вакытында башка мосафирларга яхшы мөнәсәбәттә булу.
- Юлдашларга һәм мосафирларга ярдәм күрсәтергә.
- Юлдашлар белән ризыкны уртаклашырга.
- Яхшы әхлаклы булу.
- Матур итеп сөйләшергә.
- Рөхсәт ителгән рәвештә шаяртырга.
- Юлдашларыңны күргәндә елмаерга.
- Кардәшең сөйләгәндә аны тыңларга.
- Кыен орчакларда кардәшләрең белән бәхәскә кермәскә.
- Вак хаталарны күрмәскә тырышу.
- Ярдәм алганнан соң, ярдәмчегә шундук рәхмәтләрне җиткерү.
- Кардәшләреңне үзеңнән өстен куярга, аларга ярдәм күрсәтү мөмкинлекләрен эзләү.

**2) Ихрамга кергәч**

- Госелләнергә.
- Ихрам чиста булырга тиеш.
- Исле майлар куллану.
- Ачыкканнарга ярдәм күрсәтү.
- Ихластан «ләббәйкә»не уку. Аны кычкырыбрак уку.
- Тәвафны зур ихтирам белән кылу.
- Сәгыяне Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алырга ниятләп кылу.
- Гарәфәттә хәзерге мизгелдә Ахырзаман җитүне күзәткән төсле торырга.
- Кәгъбәгә Аллаһының рәхимлеге буларак карау.

- Чәчләрне җәһәннәмнән котылгандай кыскарту.
- Корбанны гөнаһлар ярлыкануын өмет итеп чалу.
- Шәйтанга таш атканда, Аллаһыга буйсынуыңны тою.
- Саубуллашу тәвафын Сыйрат күперен узгандай үтәү.
- Хаҗ гамәлләрен тәмамлаганнан соң, Мәккә белән моңсу хәлдә саубуллашу һәм Кәгъбәне кабат күрергә өметләнү.

**3) Мәккәгә кергәндә**

- Харам җирләргә зур хөрмәт белән керү.
- Мәккәне (ярату, сагыну) газаплары белән күзәтү.
- Әл-Харам мәчетенә зур ихтирам белән карау.
- Кәгъбәгә карап торганда тәкбир һәм тәһлил сүзләрен кабатлау.
- Тәвафны еш кылу.
- Хаҗ белән бергә гомрә дә кылу.
- Бәйтуллаһка зур хөрмәт белән керү.
- Бәйтуллаһка кергәннән соң, һәрдаим тәүбә итеп тору.

**4) Мәдинәгә кергәндә**

- Шәригать кануннары иңдерелгән һәм гамәлгә кертелгән шәһәргә җитди һәм тыныч кыяфәттә керергә.
- Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең мәчетенә барырга, аның минбәрен карарга, аның монда намазлар кылуын, хөтбәләр укуын күз алдына китерергә.
- Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең каберенә килгәч, аның сиңа карап торуын, үзеңнең аның янында басып торуыңны күз алдына китерергә.
- Башта Мөхәммәд пәйгамбәребез галәйһиссәламгә, аннан Әбү Бәкер һәм Гомәр радыяллаһу ганһүмәләргә сәлам бирергә. Кабер яныннан киткәндә, аңа арка белән борылмыйча, артка атлап чыгарга.

*Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Газалиның*

*«Әдәпләр» китабыннан тәрҗемә*

# Корбан

# Корбан чалу кагыйдәләре

Корбан – үзенең тамырлары белән Ибраһим галәйһиссәламгә барып тоташа торган ислам дине йолаларының берсе. Ибраһим галәйһиссәламгә картаймыш көннәрендә ир бала бирелә. Ул аны бик күптәннән һәм зарыгып көткән була. Соңрак шушы бердәнбер баласын да корбан итеп чалынырга кушыла. Улына карата мәхәббәте бик көчле булуга карамастан, Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләнең боерыгыннан чыгарга һич уйламый. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَىٰ فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانظُرْ
مَاذَا تَرَىٰ ۚ قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ ۖ سَتَجِدُنِي إِن شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ
﴿١٠٢﴾ فَلَمَّا أَسْلَمَا وَتَلَّهُ لِلْجَبِينِ ﴿١٠٣﴾ وَنَادَيْنَاهُ أَن يَا إِبْرَاهِيمُ ﴿١٠٤﴾
قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا ۚ إِنَّا كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ ﴿١٠٥﴾ إِنَّ هَٰذَا لَهُوَ
الْبَلَاءُ الْمُبِينُ ﴿١٠٦﴾ وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ ﴿١٠٧﴾ وَتَرَكْنَا عَلَيْهِ فِي
الْآخِرِينَ ﴿١٠٨﴾ سَلَامٌ عَلَىٰ إِبْرَاهِيمَ ﴿١٠٩﴾ كَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ
﴿١١٠﴾ إِنَّهُ مِنْ عِبَادِنَا الْمُؤْمِنِينَ ﴿١١١﴾

**«Ул (үсеп буйга җитеп,) аның белән бергә (эшләрендә) тырышлык куюга (мөмкинлек биргән унөч яшьләргә) җиткәч (атасы аңа): «И улым! Һичшиксез, мин (берничә төн рәттән) төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара», – диде. Ул: «И әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне (һич уйлап тормыйча) үтә. Ин шә Аллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың», – диде.**

**Ул икәү (Аллаһы Тәгаләнең хөкеменә тулысынча) буйсынгач, ул аны яны белән (җиргә) яткырды. Без аңа дәштек: «И,**

**Ибраһим галәйһиссәлам! Син төшне акладың». (Шулвакыт Без аларга бик күп итеп савап бирдек.) Һичшиксез, (Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимүссәлам кебек) игелек кылучыларга Без шулай әҗерләрен бирәбез.**

**Һичшиксез, бу – бер сынау. Без аңа фидия итеп зур (кыйммәткә һәм гәүдәгә ия булган) бер корбанлык (сарык тәкәсе) бирдек. Соңгылар (нәселләр) арасында да аның турында (мактаулы сүзләр) калдырдык.**

**Ибраһим галәйһиссәламгә сәлам (һәм исәнлек) булсын! Һичшиксез, (аның кебек) игелек кылучыларга Без шулай әҗерләрен бирәбез, чөнки, һичшиксез, ул – Безнең (чын мәгънәсендә) инанган колларыбыздан».**

«Саффат / Сафта торучылар», 37:102-111

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм корбан чалу гадәтен Ибраһим галәйһиссәлам сөннәте дип атады, һәм Ислам динендә законлы урыны барлыгын искәртте. Шулай ук пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көнендә адәм балаларының кылырга мөмкин булган гамәлләреннән Аллаһы Тәгалә өчен корбан чалудан да якынрак һәм сөйкемлерәк гамәл юк. Корбан китерелгән хайван Кыямәт көнендә үзенең мөгезләре, тиресе һәм тояклары белән киләчәк. Корбанның каны җиргә төшкәнче Аллаһы Тәгалә ул корбанлыкны кабул итә. Шуңа күрә корбанны саф һәм ачык йөрәк белән китерегез», – дип әйткән.

Корбан – нисабка ия, мокыйм булган (ягъни сәфәрдә булмаган), үз акылында, балигълыкка ирешкән мөселман өчен вәҗиб гамәл.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: Мөмкинчелеге була торып та, гает көнне корбан чалмаган кеше бәйрәм көннәрендә безнең янга (гыйбадәт кылына торган урыннар янына) якын килмәсен».

Корбан чалуның вакыты – 10 нчы зөлхиҗҗәнең таңыннан башлап, 12 нче зөлхиҗҗәгә кадәр. Гает намазы укыла торган җирлекләрдә, корбанны намаз укыгач кына чалырга ярый. Ә инде намаз укылмый торган җирлекләр булса (кечкенә авыллар, чатыр шәһәрчекләр), андый җирдә корбанны таң атканнан башлап чалырга рөхсәт ителә. Корбан итеп кәҗәләрне, сарыкларны, сыерларны, үгезләрне һәм дөяләрне чалырга мөмкин. Сарык һәм кәҗәләр – бер кеше исәбеннән саналса, сыер, үгез, буйвол һәм дөяне җиде кеше исеменнән чалырга мөмкин. Сарык белән кәҗә бер еллык булырга тиешләр, әмма ярты еллык сарык тышкы кыяфәте белән бер еллык сарыкка охшаса, андый хайванны да корбан итеп чалырга рөхсәт ителә.

Үгез, сыер ике, ә дөя биш яшьлек булырга тиеш. Печтерелгән тәкәләр дә, буаз сарык һәм кәҗәләр дә корбан итеп чалына ала.

Корбанлыкка дигән хайваннар сау-сәламәт булырга һәм түбәндәге кимчелекләрдән азат булырга тиешләр:

1. Бер күзе яки ике күзе дә дөм сукыр булу;
2. Бик талчыккан хәлдә яки хәлсез булу;
3. Бер яки ике колагы да тулысынча кисеп атылган булу;
4. (Ризык ашый алмый торган хәлдә) күпчелек тешләре булмау;
5. Бер яки ике мөгезе төптән сынган булу;
6. Койрыкның яртысына яки аннан да күбрәгенә зыян килгән булу;
7. Ачык рәвештә нинди дә булса бер авыру белән авыру яки (ачлыктан) хәле беткән булу.

Әгәр хайванның колагының яки койрыгының өчтән бер өлешеннән кимрәге киселгән булса, ул корбан булып санала ала. Шулай ук, аксак була торып та, 4 аягына таяна торган хайванны да корбан итеп чалырга була.

## Корбанның сөннәтләре һәм әдәпләре

1. Корбан чалганчыга кадәр дә, чалган вакытта да хайванга бернинди дә авырлык китерергә, зыян салырга ярамый. Чалган вакытта да авырттырмыйча чалырга тырышырга кирәк.

2. Корбан чалырга теләгән кеше аны беренче көнендә ук чалып калырга тырышырга тиеш. Беренче көндә чалган корбан өчен икенче көнне чалган корбанга караганда әҗер-савап күбрәк бирелә. Шулай ук икенче көн өчен өченче көнгә караганда әҗер күбрәк бирелә.

3. Бәйрәм намазы көнне иртән бернәрсә дә ашамау сөннәт булып тора. Ул көнне авызга алыначак иң беренче ризык корбан ите булу – мөстәхәб гамәл.

4. Корбан чалу өчен мөмкинчелектән чыгып, иң камил хайванны сайларга кирәк. Иң матур һәм сәламәт хайван Кыямәт көнендә чалган кешесенә күбрәк әҗер-савап алып киләчәк.

5. Әгәр кеше үзе чала белсә, сөннәт буенча, корбанны үзе чалырга тиеш. Әгәр дә чала белмәсә, аның хайванын чалган вакытта шул җирдә булса да торырга тиешле.

6. Хатын-кыз үзенең корбан китерәсе хайванын үзе чала ала.

7. Бер хайван янында (ул күреп торганда) икенче хайванны чалырга ярамый.

8. Чалыр өчен яхшы кайралган үткен пычак кулланырга кирәк. Хайванга кайралмаган пычак белән авырлык һәм зыян китерергә ярамый.

9. Пычакны хайван каршында кайрарга ярамый.

10. Хайванны чалынасы урынга көч белән алып килергә ярамый, йомшаклык белән эш итәргә кирәк.

11. Хайванны кыйбла тарафына каратып, сул ягына яткырырга кирәк.

12. Чаласы кешегә пычакны уң кулы белән тотып, чалуны тиз башкарырга тиеш.

13. Чалган вакытта: «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр», – дип әйтергә кирәк.

14. Әгәр Аллаһы Тәгаләнең исеме махсус рәвештә әйтелмәсә, андый корбанның ите харам була.

15. Чалыр алдыннан түбәндәге доганы уку хәерле:

«Иннә саләәти вә нусуки вә мәхьяйә вә мәмәти лилләһи Раббил гааләмин, ләә шәрикә ләһ»

Мәгънәсе: «Дөреслектә, минем намазым, корбаным, яшәвем һәм үлемем галәмнәрнең Раббысы – Аллаһыгадыр. Аңа тиңдәшләр юк!»

16. Чалынган корбанның итен үзеңә ашау һәм калганнарны да сыйлау мөстәхәб булып тора. Әмма, корбан итен тулысы белән мохтаҗларга да таратырга мөмкин. Корбан итен 3 өлешкә бүлеп тарату иң кулай ысул: 1 нче өлешен үз гаиләңә, 2 нче өлешне дус-туганнарга, 3 нче өлешне мохтаҗларга, фәкыйрьләргә.

17. Корбанның тиресен һәм башка әгъзаларын үз карамагыңда да кулланып була, шулай ук аны садака буларак та таратырга ярый.

18. Корбан итен мөселманнарга да, мөселман булмаганнарга да таратырга мөмкин.

*ТҖ МДН Дәгъват бүлеге*

# Нәсыйхәт

# Зур гөнаһлар

## Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек китерү

Ширек – ул Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек китерү һәм Аллаһы Тәгалә белән беррәтнән ул нәрсәгә / кемгә гыйбадәт кылу. Икенче төрле әйткәндә – илаһлаштыру. Ширек турында Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَغْفِرُ أَن يُشْرَكَ بِهِ وَيَغْفِرُ مَا دُونَ ذَٰلِكَ لِمَن يَشَاءُ ۚ وَمَن يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدِ افْتَرَىٰ إِثْمًا عَظِيمًا ﴿٤٨﴾

**«Аллаһы Үзенә тиңдәшлек кылуны гафу итмәс, тиңдәшлек кылудан башка гөнаһларны Үзе теләгән кешедән гафу итәр».**

«Нисә / Хатыннар», 4:48

لَقَدْ كَفَرَ الَّذِينَ قَالُوا إِنَّ اللَّهَ هُوَ الْمَسِيحُ ابْنُ مَرْيَمَ ۖ وَقَالَ الْمَسِيحُ يَا بَنِي إِسْرَائِيلَ اعْبُدُوا اللَّهَ رَبِّي وَرَبَّكُمْ ۖ إِنَّهُ مَن يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدْ حَرَّمَ اللَّهُ عَلَيْهِ الْجَنَّةَ وَمَأْوَاهُ النَّارُ ۖ وَمَا لِلظَّالِمِينَ مِنْ أَنصَارٍ ﴿٧٢﴾

**«Бер кеше Аллаһыга берәр мәхлүкъны тиңдәш кылса, тәхкыйк, Аллаһы ул кешегә җәннәтне харам кылды һәм аның кайтачак урыны уттыр. Ахирәттә залимнәргә ярдәмче булмас».**

«Мәидә / Аш Яулыгы», 5: 72

وَإِذْ قَالَ لُقْمَانُ لِابْنِهِ وَهُوَ يَعِظُهُ يَا بُنَيَّ لَا تُشْرِكْ بِاللَّهِ ۖ إِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ ﴿١٣﴾

**«...Бернәрсәне дә Аллаһыга ширек кылма. Һичшиксез, ширек – бик зур золым...».**

«Локман», 31:13

Бүтән потларга гыйбадәт кылып, мөшрик халәтендә үлгән кеше җәһәннәм әһеле булачак. Ә бу дөньяны йөрәгендә иман белән үткән кеше, нинди генә гөнаһлар кылуына һәм алар өчен җәзалар алуына карамастан, ахыр чиктә җәннәткә керәчәк. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге сүзләрен тапшыралар: «Кылырга мөмкин булган иң зур гөнаһ турында беләсегез киләме? Ул – ширек!»[1]

Тагын бер хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз...», – дип әйтте һәм алар арасында ширекне дә искә алды.

Түбәндәге хәдисне Әбү Бәкер радыяллаһу ганһе тапшыра: «Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең сәхабәләреннән өч тапкыр: «Сезгә иң авыр гөнаһлар турында хәбәр биримме?» – дип сорый. Алар: «Әлбәттә, йә, Аллаһының Илчесе», – диделәр. Шунда ул: «Ул – ширек һәм ата-анага буйсынмау», – дип әйтте. Ул бу сүзләрен әйткән вакытта кырын ята иде, шуннан соң, бераз гына торып: «Һәм ялганнан сакланыгыз», – дип өстәп куйды. Ул бу сүзләрен кат-кат әйтә башлагач, алар[2]: «Ий, туктаса гына ярар иде», – дип әйтергә мәҗбүр булдылар.

Ширек төрләреннән – рия да бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин сезнең өчен яшертен ширектән куркам», – дип әйтте. Алар: «Йә, Расүлуллаһ, нәрсә ул яшертен ширек?» – дип сорадылар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Ул – рия», – дип әйтте.

---

1 Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан.

2 Сәхабәләр (ред.)

## Кеше үтерү

Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَمَن يَقْتُلْ مُؤْمِنًا مُّتَعَمِّدًا فَجَزَاؤُهُ جَهَنَّمُ خَالِدًا فِيهَا وَغَضِبَ اللَّهُ عَلَيْهِ وَلَعَنَهُ
وَأَعَدَّ لَهُ عَذَابًا عَظِيمًا ﴿٩٣﴾

**«Бер мөэмин хатасыз, хаслап бер мөэминне үтерсә, аның җәзасы – җәһәннәмдер, ул анда мәңге калыр. Аллаһы аңа ачуланды вә ләгънәт кылды һәм аңа олы газап әзерләде».**

«Нисә / Хатыннар», 4:93

وَالَّذِينَ لَا يَدْعُونَ مَعَ اللَّهِ إِلَـٰهًا آخَرَ وَلَا يَقْتُلُونَ النَّفْسَ الَّتِي حَرَّمَ اللَّهُ إِلَّا
بِالْحَقِّ وَلَا يَزْنُونَ ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ يَلْقَ أَثَامًا ﴿٦٨﴾ يُضَاعَفْ لَهُ الْعَذَابُ
يَوْمَ الْقِيَامَةِ وَيَخْلُدْ فِيهِ مُهَانًا ﴿٦٩﴾ إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا
فَأُولَـٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٧٠﴾

**«Вә алар Аллаһыдан башкага гыйбадәт кылмаслар һәм Ахирәт өчен Аллаһыдан башкадан ярдәм сорамаслар, Аллаһы үтерүне харам иткән кешене үтермәсләр, мәгәр үтерергә тиешле булса гына үтерерләр, вә зина да кылмаслар, әйтелгән шул ярамаган эшләрне берәү эшләсә, гөнаһының җәзасына ирешер. Кыямәт көнендә ана газап ике өлеш бирелер, вә хур ителгән хәлдә, анда мәңге калыр. Мәгәр берәү тәүбә итеп, иман китерсә һәм Коръән юлы белән изге гамәлләр кылса, әнә шундый кешеләрнең начарлыкларын яхшылыкка алмаштырыр, Аллаһы андыйларга ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы булды».**

«Фуркан / Аеручы», 25:68-70

وَإِذَا الْمَوْءُودَةُ سُئِلَتْ ﴿٨﴾ بِأَيِّ ذَنبٍ قُتِلَتْ ﴿٩﴾

**«Вә тере хәлдә күмелгән кыз балалар: «Ни сәбәпле үтерелдең?» – дип соралсалар. (Нинди гөнаһы бар иде, нигә үтердегез, дип соралсагыз? Җәһилият вакытында гарәпләр кыз балаларын тәрбияләргә авырсынып яки аларны ят кешегә кияүгә биреп җибәрү хурлык дип, тере хәлдә күмәләр иде)».**

«Тәквир / Чорналу», 81:8-9

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз: ширек кылу, сихерчелек, кеше үтерү, ятимнең малын ашау...», – дип әйткән.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Иң зур гөнаһ нинди?» – дип сорадылар. Ул: «Сине барлыкка китергән Аллаһыга тиңдәшлек китерү», – дип җавап кайтарды. Сәхабәләр: «Ә аннан соң?» – дип сорадылар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ризык җитмәс дип куркып, үзеңнең балаңны үтерү...», – дип җавап кайтарды.

Бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: Әгәр ике мөселман кылычларын кисештереп, берсе икенчесен үтерсә, алар икесе дә җәһәннәмгә эләгәләр», – дип әйтте. Сәхабәләр аннан: «Йә, Аллаһының Илчесе, үтерүченең хәле аңлашыла. Әмма ник үлгән кеше дә җәһәннәмгә эләгә соң?» – дип сорадылар. Ул: «Аның да үтерергә нияте булганы өчен», – дип җавап кайтара.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә тыйган кешене үтерүдә булышканчыга кадәр, кеше тынычлыкта яшәр», – дип әйткән. Бу хәдиснең икенче риваятендә болай дип әйтелә: «Аллаһы Тәгалә җәннәт ишекләреннән кертмичә калдырган бер генә дә кол да булмас, иллә мәгәр ул кеше Аллаһыга ширек китергән яки кеше үтерүдә бергә катнашкан кеше генә булмаса».

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Мин үлгәч, бер-берегезне үтерүче кяферләргә әйләнмәгез», – дип әйтә.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Тыелган канны түккәнчегә кадәр мөэмин тынычлыкта яшиячәк». «Кыямәт көнендә иң беренче мәсьәләләрдән булып кан коелу торачак», – дип әйткән.

Габдулла бине Гамредән риваять ителә, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Иң авыр гөнаһлар булып ширек кылу, кеше үтерү һәм ата-анага итагать итмәү тора», – дип әйткән.

Готбә бине Мәликтән тапшырыла, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәййһи вә сәлләм: «Аллаһы Тәгалә мөэминне үтергән кешедән читкә борылачак», – дип әйткән һәм шуны тагын 3 тапкыр кабатлаган.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Гаделсезлек белән кемне генә үтерсәләр дә, коелган кан өчен җаваплылыкның бер өлеше Адәм баласына (Кабил турында сүз бара) төшәчәк, чөнки үтерүгә юлны ул ачты».

Ибне Гомәр радыяллаһу ганһедән риваять кылына: Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам: «Канун яклаган кешене үтерүче җәннәтнең исен дә тоя алмас, гәрчә аның исе 40 ел юл озынлыгында ук тоела башлый», – дип әйткән.

Имамнар Бохари һәм Ән-Нәсаи Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән түбәндәге хәдисне китерәләр: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Игътибар! Аллаһы Тәгалә һәм Аның Илчесенең сагы астында булган кешенең гомеренә кул сузган кеше Аллаһыга да каршы төшкән була, һәм ул җәннәтнең исен дә тоя алмас, гәрчә аның исе 40 ел юл озынлыгында ук тоела башлый», – дип әйткән.

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән риваять ителә: Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Берәр мөселманны ярты сүз белән генә булса да үтерергә булышкан кеше Кыямәт көнендә Аллаһы

Тәгалә каршына маңгаенда «Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән мәхрүм» дигән язу белән басачак»[1], – дип әйткән.

Могавия радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребезнең түбәндәге сүзләрен риваять кыла: «Имансыз булып үлүдән һәм мөселман кешене үтерүдән кала, барлык гөнаһлар өчен ярлыкануны өмет итәргә мөмкин»[2], – дип әйткән.

## Сихерчелек

Сихерченең имансыз икәнендә бернинди дә шик юк. Коръәни Кәримдә болай дип әйтелә:

وَلَـٰكِنَّ الشَّيَاطِينَ كَفَرُوا يُعَلِّمُونَ النَّاسَ السِّحْرَ

**«Шәйтаннар сихерне гыйлем итеп һәм начар юлда кулланып, кешеләргә сихерне ... өйрәтеп, кяфер булдылар.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:102

Шәйтанның кешеләргә сихер өйрәтүенең бер генә максаты бар – аларны Аллаһы Тәгаләдән ваз кичтерү.

Аллаһы Тәгалә Һарут һәм Марут турында «Әл-Бәкара» сүрәсендә болай дип әйтә:

وَاتَّبَعُوا مَا تَتْلُو الشَّيَاطِينُ عَلَىٰ مُلْكِ سُلَيْمَانَ ۖ وَمَا كَفَرَ سُلَيْمَانُ وَلَـٰكِنَّ الشَّيَاطِينَ كَفَرُوا يُعَلِّمُونَ النَّاسَ السِّحْرَ وَمَا أُنزِلَ عَلَى الْمَلَكَيْنِ بِبَابِلَ هَارُوتَ وَمَارُوتَ ۚ وَمَا يُعَلِّمَانِ مِنْ أَحَدٍ حَتَّىٰ يَقُولَا إِنَّمَا نَحْنُ فِتْنَةٌ فَلَا تَكْفُرْ ۖ فَيَتَعَلَّمُونَ مِنْهُمَا مَا يُفَرِّقُونَ بِهِ بَيْنَ الْمَرْءِ وَزَوْجِهِ ۚ وَمَا هُم بِضَارِّينَ بِهِ مِنْ أَحَدٍ إِلَّا بِإِذْنِ اللَّـهِ ۚ وَيَتَعَلَّمُونَ مَا يَضُرُّهُمْ وَلَا يَنفَعُهُمْ

[1] Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

[2] Әбү Давыд хәдисләр җыентыгыннан.

**«Алар Сөләйманның падишаһлыгы (чорында) шәйтаннарның укып йөргән нәрсәләренә ияргәннәр. Тик Сөләйман кяфер түгел иде, шәйтаннар (бу сихерне гыйлем итеп һәм начар юлда кулланып), кешеләргә сихерне һәм Бабилдәге ике фәрештә Һарут белән Марутка иңдерелгән нәрсәне өйрәтеп, кяфер булдылар. Хәлбуки, ул икәү (үзләреннән бу гыйлемне өйрәнергә теләүчеләргә): «Без сезгә фетнә (һәм сынау) бит, син (бу сихерне өйрәнеп, хәләл булмаган нәрсәләргә ышанып) кяфер булма!» – дип әйтми торып, беркемне дә өйрәтмиләр иде. Алар (кешеләр) ир белән хатын арасын аера торган (сихер кебек) нәрсәләрне шул икесеннән өйрәнгәннәр иде, тик алар (сихер ясаучылар) Аллаһының рөхсәте булмыйча, аның белән һичкемгә дә зарар китерә алмаячаклар[1].**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:102

Бу юлдан баручыларны бүгенге көндә дә күрергә мөмкин. Алар уйлавынча, моның белән шөгыльләнү харам дәрәҗәсендә генә. Әмма алар моның ширек икәнен һич аңламыйлар. Алар алхимияне өйрәнеп, шуны

---

[1] Әһле сөннәт галимнәре фикеренчә, сихер – асылы булмаган буш хыял түгел, ә бүтән барлыклар кебек чынлап булган нәрсә. Аллаһы Тәгалә китабында аны телгә алган, аның өйрәнелә һәм өйрәтелә торган нәрсә икәнен белдергән, аның белән шөгыльләнү хәләл булганына ышану диннән чыгарып, кяфер итәчәген һәм ир белән хатынны бер-берсеннән аера алачагын бәян иткән. Шикле, батыйль булган әйбернең болай итеп Коръәндә тасвирлануы мөмкин түгел. Моннан тыш, Аллаһы Тәгаләнең теләве белән сынау хикмәтенә нигезләнгән очракта, сихерченең, ниндидер җисемнәрне бер урынга җыеп, яки үзеннән башка беркем белмәгән берникадәр сүзләр әйтеп, яки берникадәр көчләрне берләштереп, гадәттән тыш нәрсәләр булдыруы бер дә акылга ятышсыз күренеш түгел. Сахих хәдисләрдә дә сихернең барлыгы ачыктан-ачык әйтелгән.

Ләкин шуны белергә кирәк: Аллаһы Тәгаләдән башка бернинди яратучы, бар итүче дә юк. Тормышта без очраткан сихерләр Аллаһы Тәгаләнең теләгән коллары аркылы башкарган сынавы. Бер әйберне беркайчан да онытмаска кирәк ки, сихер – иң зур гөнаһларның берсе. Әмма сихер ясау, кылынган эшнең үз-үзенә тәэсир итүенә ышанмаган яки сихерне хәләл дип санамаган очракта, сихер ясаучыны да ясатучыны да кяфер дип санап булмый. Ләкин Коръәни Кәримне кан белән язу һәм чүплек кебек шакшы урыннарга ташлап яки башка динне мәсхәрәләү аша ясалган сихерләр, әлбәттә, аны башкаручыны кяфер итә. Сихер белән эш итүдән Аллаһы сакласын! (Хазин, «Фәләкъ» сүрәсе тәфсире).

кулланырга телиләр[1]. Кемдер сихерне никахларны бетерү өчен, кемдер берәр ир хатынын ярата башласын өчен куллана ала. Кемдер (сөйдергеч сихер кулланып) бер кешене икенче кешегә гашыйк итәргә тырыша. Болар барысы да ширек һәм адашу.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Җиде һәлакәткә китерә торган гөнаһтан сакланыгыз: ширек кылу, сихерчелек, кеше үтерү, ятимнең малын ашау...», – дип әйткән, ягъни 7 зур гөнаһ арасында сихерчелекне дә искә алган.

Кеше үзенең Раббысы Аллаһыдан куркырга һәм бу дөньясын да, теге дөньясын да җимерә торган юлдан бармаска тиеш.

Әбү Муса радыяллаһу ганһедән риваять кылына: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Өч төркем кеше җәннәткә кермәячәк: эчкече; туганлык җепләрен өзүче; сихерченең сүзләренә ышанучы кеше»[2], – дип әйткән.

Ибне Мәсгуд радыяллаһу ганһедән риваять кылына: Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Дөреслектә, әфсеннәр (әт-тивәлә), бөтиләр һәм сихерчелек – ул ширек», – дип әйткән.

Бу хәдистә «әт-тивәлә» дигән сүз очрый. Ул ир хатынын ярата башласын өчен ясала торган сихернең бер төре.

Кызганыч, әмма өммәтебезнең күпчелеге бу мәсьәләләрдә гыйлемсез. Шуңа күрә моны бераз гына аңлатып китәргә кирәктер, чөнки зур гөнаһлар өчен җәзасы да көчле була.

...Гөнаһлы гамәлләрнең һәлакәтлелек икәнен һәм аннан читләшкән; фарыз гамәлләр турында гыйлем алган һәм аны үтәгән кеше бәхетле була. Әмма андый кешеләр аз очрый. Ә андый гыйлемне алган кеше Аллаһы Тәгаләгә хәмед әйтергә, рәхмәтле булырга тиеш.

---

1 Алхимия – сихернең бер төре. Аның төп максаты – дөньяда әле булмаган берәр нәрсә уйлап табу.

2 Әбү Давыд һәм Ибне Мәҗе хәдисләр җыентыгыннан.

Әйе, кеше турында: «Ул нәрсәләр кылырга кирәклеге турында гыйлем алырга теләмәде, шуңа күрә үзе гаепле», – дип әйтергә мөмкин. Әмма бу хакыйкатькә бик үк туры килми: «Гади кешегә гыйлем алырга кирәклеге мәгълүм дә булмаска да мөмкин. Аллаһы Тәгалә кешегә бирәр төрле гыйлем бирмәсә, ул кеше өчен бу гамәлне кылу фарыз булмаячак. Әмма ул гыйлемне алу белән, кеше бу гамәлләрне кылырга тиеш була.

Рәхимле һәм Рәхмәтле Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

مَّنِ اهْتَدَىٰ فَإِنَّمَا يَهْتَدِي لِنَفْسِهِ ۖ وَمَن ضَلَّ فَإِنَّمَا يَضِلُّ عَلَيْهَا ۚ وَلَا تَزِرُ
وَازِرَةٌ وِزْرَ أُخْرَىٰ ۗ وَمَا كُنَّا مُعَذِّبِينَ حَتَّىٰ نَبْعَثَ رَسُولًا ﴿١٥﴾

**«Пәйгамбәр җибәреп, шәригать хөкемнәрен өйрәтмичә, һичбер кавемне газап кылыр булмадык».**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:15

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кайбер сәхабәләре Хәбәшистанга һиҗрәт кылганнар иде. Бу вакытта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кылырга яраган һәм ярамаган гамәлләр турында гыйлем иңә генә башлаган иде. Ә һиҗрәт кылган кешеләргә бу гыйлем берничә айдан соң гына ирешә. Шуңа күрә, аларга барып ирешкәнче, җитди сәбәп аркасында, алар кылган гөнаһлары өчен җавап тотмадылар. Бу барлык очракларда да кулланыла ала: кешегә дини канун килеп ирешкәнче, ул аның өчен җавап тотмаячак. Ә Аллаһы Тәгаләгә исә яхшырак мәгълүм.

*Имам Әз-Зәһәбинең «Әл-Кәбаир» китабыннан*

# Әдәпләр

## Имам әдәпләре

- Имам булып намазның фарызларын һәм сөннәтләрен яхшы белүче кеше генә тора ала.
- Намазны боза торган шартларны белергә.
- Үзең артыннан гыйлемле кешене бастырырга.
- Намаз алдыннан әдәпле генә, кул ишарәсе белән сафларны тигезләргә сорарга.
- Озын сүрәләр укымаска, чөнки бу җәмәгатькә кыенлык китерергә мөмкин.
- Тәсбихләрне озакка сузмаска.
- Әмма шул ук вакытта намазларны аларның дәрәҗәсен киметерлек итеп кыскартмаска.
- Намазны укыганда мәчеттәге авыру, хәлсез, өлкән кешеләрнең санын истә тотарга.
- Рөкүгъ һәм сәҗдә вакытында, җәмәгать намазны хошугълык белән башкарсын өчен, тәсбихләрне әкрен әйтергә. «Фәтихә» сүрәсен укыр алдыннан һәм укыгач, шулай ук өстәмә сүрә укылгач, берникадәр вакыт дәшми торырга (тынлык сакларга). Әгәр кемнеңдер намазга кушылырга ашыгуын ишетсәгез, рөкүгъ вакытында аны бераз көтеп торырга кирәк (әлбәттә, әгәр бу җәмәгатькә кыенлык китермәсә).Әгәр намазның вакыты чыгачак дигән курку булмаса, күршеләрнең намазга кереп җитүен бераз көтеп торырга. Беренче һәм икенче «сәлам» арасында, алар аерылып торсын өчен, бераз гына туктап торырга. Намаздан соң Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр турында уйланып, Аңа рәхмәтләрне җиткерү.

## Җомга намазы әдәпләре

- Намаз вакыты кергәнче, аңа әзерлек эшләрен тәмамларга.
- Вакыт керү белән үк, тәһарәтләнергә һәм иртәрәк мәчеткә китәргә.
- Госелләнергә.
- Чиста киемнәр кияргә.
- Тиешле күләмдә исле май кулланырга.
- Аз сөйләшергә.
- Һәрдаим Аллаһы Тәгаләне зекер итеп торырга.
- Имамга якынрак утырырга.
- Хотбәне сөйләшмичә генә тыңларга.
- Намаз укыганнан соң гыйлем алырга юнәлергә.
- Йөргәндә салмак кына атларга.
- Адымнар зур булмасын.
- Башны бераз алга ияргә.
- Игелек эшләүчеләргә мактаулар әйтергә.
- Мәчеткә күркәм йөз белән керергә.
- Кешеләрнең сәламнәренә җавап бирергә.
- Хатыйб минбәргә менгәннән соң намазлар укымаска.
- Хатыйб җәмәгатькә сәлам биргәндә, аның сәламенә җавап кайтарырга.
- Сөйләшмәскә.
- Хотбәне бар күңелне биреп тыңларга һәм нәсыйхәтләрне кабул итәргә.
- Хатыйб җәмәгатькә борылып хотбә сөйли башлаганнан соң, як-якка борылмаска.
- Хатыйб минбәрдән төшмичә һәм мөәзин камәтне төшереп бетермичә, намаз укырга тормаска.

## Ир-атның хатынына карата әдәпләре

- Хатынга яхшы мөнәсәбәттә булырга.
- Аның белән назлы итеп сөйләшергә.
- Аңа мәхәббәтеңне белдерергә.
- Икәүдән икәү генә калганда тыныч булырга.
- Кечкенә хаталарны күрмәскә тырышырга.
- Аның намусын һәм дәрәҗәсен сакларга.
- Хатын белән бәхәскә еш кермәскә.
- Аны тәэмин итәргә һәм саран булмаска.
- Аның гаиләсен ихтирам итәргә.
- Матур вәгъдәләр бирергә.
- Аны көнләргә.

## Хатынның иренә карата әдәпләре

- Ир алдында оялу хисен югалтмаска.
- Ир белән бәхәскә кермәскә.
- Аның теләкләрен үтәргә тырышырга.
- Ир сөйләгәндә дәшмәскә.
- Ир читтә булганда аның мал-мөлкәтен һәм дәрәҗәсен сакларга.
- Аның малын юк-барга сарыф итмәскә.
- Хушбуйлар сөртергә.
- Тышкы кыяфәтне тәртиптә тотарга.
- Чиста киемнәр кияргә.
- Канәгать булуын күрсәтергә.
- Мәрхәмәтле булырга.
- Бизәнү әйберләре тагып йөрергә.
- Ирнең гаиләсе һәм якыннарына карата ихтирамлы булырга.
- Эшләгән гамәлләре өчен иргә рәхмәтле булырга.

- Икәүдән икәү генә калганда аңа яратуыңны белдерергә.
- Ирен күргәндә, шат булуын күрсәтергә.

## Шәкертнең остазына карата әдәпләре

- Беренче чиратта, һәрвакыт остазны сәламләргә.
- Остаз янында аз сөйләшергә.
- Остаз утырган җиреннән торганда, торып басырга.
- «Фәлән галим бөтенләй башкача әйтә», – кебек сүзләрне беркайчан да әйтмәскә.
- Яныңда утырган сабакташка сораулар бирмәскә.
- Остаз белән сөйләшкән вакытта көлмәскә.
- Остазның фикерләренә каршы килгән фикерләргә ишарә итмәскә.
- Остаз утырган җиреннән торганда, аның киеменә тотынмаска.
- Дәрестән соң өйгә кайтканда остазга сораулар бирмәскә.
- Дәрес вакытында остаз арыса, дәресне дәвам иттерүне сорамаска.

## Коръән өйрәтүченең әдәпләре

- Тәкъва кыяфәт белән утырырга.
- Шәкертләрнең укуын тыңларга.
- Аңлар өчен, сөйләшмәскә.
- Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итәргә.
- Охшаш хәрефләрнең әйтелешенә игътибар итәргә.
- Коръән укыганда тукталыш урыннарын әйтергә.
- Укуны туктатканда, укуны дәвам иттерүнең тәртипләрен аңлатырга.
- Саннарны өйрәтергә.

- Тәҗвид һәм авазларның дөрес әйтелешен өйрәтергә.
- Хәтем чыгуның савабын аңлатырга һәм хәтем чykканнан соң эшләнергә тиешле гамәлләрнең тәртибен аңлатырга.
- Күптән түгел генә Коръән укый башлаучыларны аңлап, йомшак мөгамәләдә булырга.
- Шәкерт дәрескә килмәгәндә, һәрвакыт дәрес калдыруының сәбәбен сорарга.
- Бу шәкерт дәрескә килгәч, аны укырга өндәргә.
- Аз сөйләшергә.
- Шәкертләргә намазда укыла торган сүрә-аятьләрне яки алар имам булгач укырга кирәк булачак сүрәләрне ятлатырга.

## Коръәнне өйрәнүченең әдәпләре

- Остаз каршында тыйнак кына утырырга.
- Остаз сөйләгәннәрне аңлар өчен, бик игътибарлы булырга.
- Башны бераз аска иярге.
- Коръәнне укый башлар алдыннан остаздан рөхсәт сорарга.
- Шуннан соң «Әгузү-бисмилләһ»не әйтергә.
- Укуны тәмамлаганнан соң, дога кылырга.

## Кечкенә балаларны укытучы мөгаллимнәрнең әдәпләре

- Беренче чиратта тышкы кыяфәтне тәртипкә китерергә, чөнки балаларның бар игътибары шуңа юнәлтелгән була. Мөгаллим нәрсәне матур дип санаса, балалар да шуны матур санар. Мөгаллим нәрсәне әшәке дип тапса, балалар өчен дә шул әшәке булыр.
- Утырганда сөйләүдән туктарга кирәк, ягъни кирәк вакытта гына сөйләргә.

- Җитди кыяфәт сакларга.
- Тәрбия эшендәге мөһим мәсьәләләрне җитди һәм хөрмәт белән башкарырга.
- Укучыларга сукмаска һәм аларны җәзаламаска.
- Мәгънәсез әңгәмәләр кормаска, юкса, укучы үзенең хөрмәт итмәвен белдерергә мөмкин.
- Укучыларга бер-берсе белән сөйләшеп утырырга рөхсәт итмәскә.
- Укучылар янында беркем белән дә шаяртмаска.
- Бүләкләр кабул итмәскә.
- Укучылар арасында бәхәсләр тууны булдырмаска.
- Начар сүз, гайбәтнең зарары турында сөйләргә.
- Ялган һәм гайбәтнең түбәнлеге турында сөйләргә.
- Истинҗә, юыну рәвешләрен, тәһарәт алу һәм намаз уку тәртипләрен өйрәтергә.

*Имам Әбү Хәмид Мөхәммәд Газалиның*
*«Әдәпләр» китабыннан тәрҗемәләр*